Г. М. ДӘҮЛӘТШИН
Ф. Ш. ХУҖИН
И. Л. ИЗМАЙЛОВ

ТАТАРСТАН ТАРИХЫННАН ХИКӘЯЛӘР

5–6

Г. М. ДӘҮЛӘТШИН,
Ф. Ш. ХУҖИН,
И. Л. ИЗМАЙЛОВ

ТАТАРСТАН ТАРИХЫННАН ХИКӘЯЛӘР

УРТА МӘКТӘПНЕҢ

5-6

СЫЙНЫФЛАРЫ
ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК

Тарих фәннәре докторы С. Х. Алишев редакциясендә

Татарстан Республикасы Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан расланган

Казан «Мәгариф» 1993

ББК 63.3(2 Тат.)
Д94

Рәссамы Рушан Шәмсетдинов

Дәүләтшин Г. М., Хуҗин Ф. Ш., Измайлов И. Л.

Д94 Татарстан тарихыннан хикәяләр /Г. М. Дәүләтшин, Ф. Ш. Хуҗин, И. Л. Измайлов; С. Х. Алишев ред.— Казан: Мәгариф, 1993.— 271 бит; рәс. белән
ISBN 5—7761—0021—6

Д $\frac{4306020600—050}{П86(03)—93}$ БЗ—59—25—93/94

ББК 63.3(2 Тат.)

ISBN 5—7761—0021—6

© Дәүләтшин Г. М., Хуҗин Ф. Ш., Измайлов И. Л., 1993

1. ТАТАРСТАН МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ

Нәрсә ул Туган ил? Ул — синең әтиең, әниең, абыең, апаң, энең, сеңлең, әбиең, бабаң. Ул — синең туган, яшәгән йортың, ишегалдың, урамың, авылың, шәһәрең. Ул — син укый торган мәктәп, андагы дусларың, укытучы абыйапаларың. Ул — синең сулаган һаваң, басып йөргән җирең. Безнең барыбыз өчен дә газиз Туган илебез — Татарстан республикасы. Без яшәгән шәһәр, авыллар, без җиләк җыйган урман-болыннар, без балык тоткан күлләр, елгалар —

Татарстанның физик картасы.

барысы да кечерәйтелеп картага төшерелгән. Сезнең алда — Татарстан картасы. Нинди матур ул. Шагыйрьләр аны зәңгәр күбәләккә дә, томырылып чабып баручы толпар атка да охшаталар. Аның мәйданы 68 мең квадрат км. Зур да, кечкенә дә безнең Татарстан. Зур, чөнки дөньяда аннан кечкенә дистәләгән илләр бар. Кечкенә, чөнки зурлыгы белән аннан узып киткән илләр күп. Хәер, безнең халыкның байлыгы анда яшәгән җирнең зурлыгы белән генә бәяләнми. Татарстан уңдырышлы кара туфракка, урман-суга бай. Анда тигезлекләр кайчак сөзәк таулар белән алышына. Европаның Татарстан аша узган иң зур елгалары — Идел, Кама илебез картасында зәңгәр билбау кебек. Аларда зур-зур корабларда күп диңгезләргә барып җитеп була. Ә боргаланып-боргаланып, бу матур җирләрне тагын бер кат күреп калыйк әле дип, кире кайта-кайта агучы кечерәк елга, инешләрнең саны юк.

Сезнең кызу җәй көне җиләктән кайтканда, ял итәргә утырып, тау астыннан чылтырап чыккан салкын чишмә суына манып арыш ипие ашаганыгыз бармы икән?! Ашап карагыз әле. Дөньяда аннан да тәмле ризык булмас. Комбайнчы, тракторчы абыйларның, ындыр табагында ашлык җилгәрүче, ипи пешерүче апаларның тырышлыгы белән үстерелгән, безнең табыныбыз күрке булган икмәкнең шунда тәмен белерсез, кадерен тоярсыз. Бераз үсә төшкәч, җәйге ял вакытларында үзегездә дә аларга ярдәм итү теләге туар. Татарстанның уңдырышлы туфрагында бодай, арыш, арпа, борчак, тары, карабодай, чөгендер һәм башка бик күп иген, яшелчәләр күкрәп үсә.

Безнең Татарстаныбызның яз дисәң — чын язы, җәй дисәң — чын җәе, көз дисәң — чын көзе, кыш дисәң — чын кышы бар. Кыш җитсә, җәйне сагына башлыйбыз, җәй җитсә — кышны. Халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукай әйтмешли, һавабыз шундый:

Анда бик салкын вә бик эссе түгел,
урта һава,
Җил дә вактында исеп,
яңгыр да вактында ява.

Татарстан — ул шәһәрләр, фабрика, заводлар иле дә. Казан, Чаллы, Әлмәт, Чистай, Алабуга, Бөгелмә, Болгар, Зәй, Азнакай кебек 20 ләп шәһәре бар. Ә нурлы Казан — илебезнең башкаласы. Аңа инде 800 елдан артык. Анда илебезнең иң яхшы театрлары, музейлары, иң биек йортлары, иң зур стадионнары, уку йортлары урнашкан. Ул Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, М. Җәлил, С. Сәйдәшев, Б. Урманче, Л. Толстой, Ф. Шаляпин М. Горький, Н. Лобачевский, А. Бутлеров, М. Вахитов, М. Солтангалиев, С. Максуди һәм

башка бик күп дөньяга даннары таралган язучы, галим, композитор, рәссам, көрәшчеләрнең исемнәре белән бәйләнгән. Алар Казанда яшәгәннәр, укыганнар, иҗат иткәннәр, көрәшкәннәр.

Казан шәһәренең иң биек, иң текә елга ярында ак Кремль диварлары урын алган. Аның уртасында Сөембикә манарасы. Ул безнең җиребездә булып узган бинифаяшанлы вакыйгаларның шаһиты. Завод-фабрикаларда көнкүреш җиһазлары, сәгатьләр, полиэтилен, кино-фотопленка, кием-салым һәм башка бик күп әйберләр, машина, самолетлар җитештерелә. Алар дөньяның бик күп илләренә чыгарыла.

Республикабыз җире нефть, газ, ташкүмер, битум, торф, төзелеш материалларына бай. Илебезнең көнчыгыш районнарына барып чыксагыз, анда сез, зур кошлар кебек чайкалып, баш ия-ия, тирән катламнардан нефть суыртучы скважина насосларын күрерсез. Әмма җиребезнең байлыгы күп еллар буена вәхшиләрчә таланды, җиребез, һавабыз пычранды. Киләчәктә без үз җиребезнең хуҗалары булырга, мондый вәхшилеккә юл куярга тиеш түгелбез. Халык язучысы Г. Бәширов әйтмешли, «Туган ягым — яшел бишек» бит ул. Ә үзебез үскән бишекне мәсхәрәләргә ярыймыни?!

Республикабызның иң олы горурлыгы — Татарстан халкы. Ул 4 млн. га якынлашып килә. Аның яртысыннан артыгы шәһәрләрдә яши. Авыллар кими бара. Татарстан җире — татар халкының борынгы, тарихи туган иле. Безнең халык киң күңелле булган. Монда күп кенә башка халыклар үзләренең икенче туган илләрен тапканнар. Татар халкы гасырлар дәвамында рус, чуваш, украин, башкорт, мари, мордва, удмурт һ. б. халыклар белән туган җиребезне тагын да матурлау өчен хезмәт иткән. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «Тел, ләгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгәннәр.

Республикабызның, халкыбызның тагын бер зур байлыгы — ул аның мең елдан артык булган тарихы.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Татарстан кайсы республикалар, өлкәләр белән чиктәш? Аларны картадан табып күрсәтегез.
2. Сезнең туганнарыгыз кайсы шәһәр, авылларда яши?
3. Үзегезнең шәһәр, авыл, поселокларыгызны тасвирлап сөйләгез.

2. БЕЗ ТАРИХНЫ НИЧЕК ӨЙРӘНӘБЕЗ

Нәрсә соң ул тарих? Ул туган илебезнең, халкыбызның узган тормышын өйрәнә. Халкыбызның борынгы бабалары элек-электән без яшәгән Идел һәм Кама буйларын үз итеп, яратып гомер кичергәннәр. Шул заманнардан бирле меңнәрчә еллар узган. Һәр буын үзеннән соң шәһәрләр, авыллар төзеп, зур эшләр эшләп калдырган. Аннан соң киләчәк буыннар аларның эшләрен дәвам иткәннәр, тәҗрибә җыйганнар. Әмма тарих бик катлаулы юл үткән. Коточкыч сугышлар булуын, авыл-шәһәрләрнең көл-күмергә әйләнүен, күпләгән кешеләрнең җәбер-хәсрәтен дә тарих хәтерли.

Безнең халкыбыз тарихы аеруча гыйбрәтле. Борынгы бабаларыбыз элек-электән үз дәүләтенә, шәһәрләргә, дингә-иманга, югары үскән рухи мәдәнияткә ия булган. Дошманнар килеп, аларның дәүләтләрен, шәһәр, авылларын, күпләгән халкын юк иткәннәр. Әмма халкыбызның таланты, тырышлыгы белән дәүләт, шәһәрләр яңадан калыккан. Тормыш тагын алга киткән. Гасырлар узган. Ил өстенә тагын афәт килгән. Элеккесеннән дә явызрак, мәкерлерәк дошман илебезне яулап алган. Шулай да халкыбыз бетмәгән, бирешмәгән. Иле-көне бетсә дә халык булып калган. Мөхтәрәм шагыйрь Нури Арслановның бу хакта шундый шигъри юллары бар:

«Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без менә, без бар, эз бар җирдә —
Без батырган саен калыккан».

Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш — меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе ул. Тарих — хәтер ул. Ул азатлык өчен көрәштә башларын куйган фидаи җаннарны онытмаска өйрәтә. Тарихыбызда булган ялгышлыкларны кабатламаска, бердәм булырга сабак бирә. Сатлык җаннарга карата нәфрәт уята. Узган тарихларын онытып, тулаем бер халыклар юкка чыга. Кешеләр маңкорткa әйләнә. Кем соң алар маңкортлар? Танылган кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның бер әсәрендә шундый гыйбрәтле хикәят сөйләнә.

...Борын-борын заманда чүлледалалы эссе якларда, бер урыннан икенче урынга күчеп йөреп, мал асрау белән көн күргән күчмә кабиләләр яшәгән. Алар арасында гел сугышып, башка кабиләләрнең малларын, көтүлекләрен тартып алучы, кешеләрен кол итеп алып китүче бер кабилә дә булган ди. Үз кулларына төшкән әсирләргә алар ифрат дәрәҗәдә рәхим-шәфкатьсез булганнар, колларны коточкыч язмыш көткән. Аларның башына, чәчләрен кырып, су кер-

гәндә кия торган резин башлык сыман итеп яңа суйган дөянең тиресен кигереп куйганнар. Эссе кояш астында куырылып, тарайганнан-тарая барган тире әсирнең чәчсез башын тимер кыршау сыман кыса, тарттыра барган. Коллар авыртуга түзә алмыйча җан ачысы белән өзгәләнгәннәр. Аларның тавышы ишетелмәсен өчен, ерак чүлгә, эссе кояш астына илтеп, баганаларга бәйләп куйганнар. Тире башлык, тагын да куырылып катып, башына батып кергән, сөякне изгән. Җәза ахырына азлар гына исән калган. Алары да үзләренең кеше затыннан булуын аңламаган аңгыра маңкортка әйләнгәннәр. Бу коточкыч авыр җәзадан соң алар үзләренең тарихларын, телләрен, хәтта исемнәрен онытканнар, хәтерләрен җуйганнар. Алар ата-аналарын, әби-бабаларын, ыруларын, халкын, туган илләрен онытканнар. Алар белән теләсә нәрсә эшләп булган. Ул мәхлүк җан телсез хайваннан әллә ни аерылмаган. Ашау турында гына уйлаган. Маңкорт эт кебек үзенең хуҗасын гына таныган, ни кушса, шуны гына эшләгән. Хәтта, бер дә тартынмыйча, туган анасын да үтерә алган.

Сак булыгыз, кадерле дуслар, әнә шундый аңгыра маңкортларга әйләнә күрмик. Үз илебезнең, үз халкыбызның тарихын әйбәтләп өйрәник.

Борынгы заманнарда ук яшәгән кешеләрнең тормышын без ничек белә алабыз соң? Кызганычка каршы, иң борынгы чорлардан гына түгел, соңгырак дәверләрдән дә шул чорларда язылган тарихи китаплар безгә кадәр бик аз килеп җиткән. Аларның күбесе дәһшәтле елларда утта яндырылган. Дошман, шулай итеп, тулаем бер халыкның хәтерен җуйдырып, маңкорт итмәкче булган. Әмма халык тарихы эзсез югалмый ул. Менә хәзер һәр ел саен, сулар агып җирләр кипкәч, археологлар борынгы шәһәр урыннарына ашыгалар. Алар өчен туфрак-җир катламнары бик зур калын китап кебек. Сак кына аның бите артыннан битен чистартып, археологлар борынгы шәһәр хәрабәләрен ачалар, андагы табылдыкларга карап, ул чактагы кешеләр хакында фикер йөртәләр. Җәйге каникул вакытларында аларга мәктәп балалары да ярдәмгә килә. Болардан тыш халкыбызның авыз иҗатында, аеруча риваять, бәет һәм тарихи җырларда борынгы вакыйгалар тасвирланган. Халык, аны меңәр еллар буе телдән телгә сөйләп, үзеннән дә өстәп, буыннан буынга тапшырган. Ерак вакытлар тарихын өйрәнү өчен сакланып калган язма истәлекләр, документлар, төрле эш кәгазьләре һ. б. шундый хатирәле язмалар, китаплар зур әһәмияткә ия.

Кадерле балалар, сез яшәгән йортларда, күршеләрегездә, сезнең авылда сугыш һәм хезмәт ветераннары яшәмиме икән? Алар

дәһшәтле сугышның, авыр хезмәтнең ачысын да һәм авырлыгын да, җиңү шатлыгын да үз язмышларында татыганнар. Аларны үзегезнең тарих түгәрәкләренә чакырыгыз. Алар сөйләгәннәрне төгәл итеп язып калырга тырышыгыз. Язмаларыгызны музейларга тапшырыгыз.

Элек халкыбызда шундый бер әйбәт гадәт яшәп килгән. Яшьтән үк һәр бала үз нәсел-ыруының кимендә җиде буынын белергә тиеш булган. Зурлар җиде бабаның исемнәрен догаларында искә алганнар. Бабаларыбызда нәсел шәҗәрәләре телдә генә түгел, язма рәвештә дә гамәлдә булган. Алардагы буыннар кайчак егермедән дә артып киткән. Димәк, бу юл белән дә халык үз нәселенең берничә гасырлык тарихын белгән. Бармагыгызны бөгә-бөгә нәсел бабаларыгызны барлап карагыз әле — ничә буынга җиттегез? 2—3 тән узмадыгыз, шулай бит? Әмма үзегезне нәсел-нәсәбен белмәүче бер мескен итеп хис итәргә ашыкмагыз: әтиәниләрегездән, әби-бабаларыгыздан сораштырыгыз. Аларны гаиләгез альбомына язып куйсагыз, шәҗәрә сездән соңгы буыннарга да күчәр. Сыйныфыгызда, мәктәбегездә бергәләп ярыш оештырыгыз: кем күбрәк буын бабаларын һәм аларның тормышларын белә икән? Әйдәгез, халкыбыз, илебез тарихын өйрәнүне шуннан башлыйк әле. Борынгы тарихка сәяхәттә хәерле юл сезгә!



Шәҗәрә. *Марсель Әхмәтҗанов җыелмасыннан.*

Сораулар һәм биремнәр:

1. Тарих нәрсәне өйрәнә?
2. Кемнәр алар археологлар?
3. Атлантида турында сез нәрсә беләсез?
4. Әби-бабаларыгызның тормыш юлы хакында хикәят язып килегез.

БЕРЕНЧЕ
БҮЛЕК

ИДЕЛ-ЧУЛМАН БУЙЛАРЫНДА БОРЫНГЫ КЕШЕЛӘР. БОЛГАР БАБАЛАРЫБЫЗНЫҢ ЭЗЛӘРЕННӘН...

Хәзерге Татарстан җирендә, Идел һәм Чулман (Кама) буйларында күптөрле халыклар яши. Алар арасында татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар, башкортлар бар. Алар бер-берсеннән үзләренә генә хас гореф-гадәтләре, телләре һәм хәтта диннәре белән дә аерылып торалар. Кием-салымнарында, хатын-кызларның бизәнү әйберләрендә, төрле ашлар пешерүдә, тормыш-көнкүреш әйберләрен бизәүдә, халык авыз иҗатында (әкиятләр, җырлар, риваятьләр һ. б.) һәр халыкка хас үзенчәлекләр бар. Безнең татарлар телләре белән башкортларга, чувашларга, тагын да ераграк китсәк, азәрбайҗаннарга, казахларга, үзбәкләргә, каракалпакларга, кыргызларга, төрекмәннәргә һәм башка халыкларга бик якын. Аларны төрки халыклар дип йөртәләр. Төрки халыкларның борынгы бабалары әүвәл Үзәк Азия, ягъни хәзерге Монголия, Төньяк Кытай далаларында, Алтай таулары һәм Байкал күле тирәләрендә яшәгәннәр. Ничек килеп чыкканнар соң алар безнең якларга? Әйдәгез, хәзер шушы халыкларның борынгы тарихы белән танышыйк.

3. ТАТАРСТАН ҖИРЕНДӘ ИҢ БОРЫНГЫ КЕШЕЛӘР

Чал тарих... Кайчандыр ерак бабаларыбыз яшәгән урыннар һәм аларны казып тикшергәндә табылган таш балталар, ук һәм сөңге очлары, моннан меңнәрчә ел элек сүнгән учак калдыклары. Борынгы каберлекләр һәм хәзерге заман кешесенә бик тә сәер тоела торган күмү йолалары...

Кемне генә дулкынландырмас икән мондый табылдыклар! Тарихыбызның иң борынгы чорлары турында сөйләүче бердәнбер чыганаклар болар! Республикабыз территориясендә меңнәрчә археологик истәлекләр — әллә кайчан җимерелеп, җир белән тигезләнгән борынгы авыл һәм шәһәр урыннары, каберлекләр — табыла. Бүгенге көнгә аларның әле бик азы гына казып өйрәнелгән. Шулай да археологлар борынгы заман кешелә-

ренең тормышы, шөгыльләре, рухи дөньясы турында сәгатьләр буе сөйли алалар.

Уйлап караганыгыз бармы икән: безнең якларга иң беренче кешеләр кайчан килеп утырган? Каян килгәннәр алар? Нәрсә белән шөгыльләнгәннәр? Белмисезме? Тыңлагыз алайса: археологлар бу сорауларга җавап бирә алалар.

Иң борынгы кешеләрнең тормышы турында бернинди язмача мәгълүматлар сакланмаган, чөнки алар үзләре укый-яза белмәгәннәр. Язу бит бик соң, моннан 4—5 мең еллар элек кенә килеп чыккан. Аның каравы борынгы кешеләр яшәгән урыннар сакланып калган. Шул урыннарны табып, җентекләп тикшерергә, казырга гына кирәк. Археологлар, табылдыкларны өйрәнеп, кешеләрнең ничек яшәгәннәрен әйтеп бирәләр.

Иң борынгы кешеләр эш коралларын бары тик таштан гына ясаганнар. Алар әле тимерне һәм башка металларны белмәгәннәр, ә таш исә аяк астында гына аунап ята. Шуңа күрә бу чорны археологлар «таш дәвере» яисә «таш гасыры» дип йөртәләр.

Иң борынгы кешеләр безнең якларга моннан 40—100 мең еллар элек килеп утырганнар. Аларның эзләре Татарстанда бер урында — Тәтеш районының Бессоново авылыннан ерак түгел «Красная Глинка» дигән урында табып тикшерелгән. Ул дәвердә климат бик салкын булган, күп җирләрне бозлыклар каплап алган, шунлыктан, күрәсең, кешеләр дә бик аз булган. Алар мамонтлар, төньяк боланнары, йөнтәс мөгезборыннар аулап көн күргәннәр.

Еллар үтә. Әкренләп климат җылына, бозлыклар эреп бетә. Көньяктан җылы сөюче хайваннар, ә алар артыннан кешеләр дә Идел-Кама буйларына күпләп күчеп утыра башлыйлар. Алар яшәгән урыннар Кама Тамагы, Тәтеш һәм Спас районнарында Долгая Поляна, Сөкәй, Красновидово, Әҗмер авыллары янында табылган.

Борынгы кешеләрнең торулыклары (яшәү урыннары) бик начар сакланган. Күпме еллар үткән бит! Казу эшләре вакытында таштан ясалган эш кораллары — чапкычлар (иң борынгы балталар), кыргычлар, кискечләр (пычаклар) һәм сирәк булса да кыргый хайван сөякләре табыла. Яшәү урыннары хәзерге Минзәлә районының Дәвек авылы янында булган борынгы кешеләрнең учак калдыклары да сакланган.

Бу чор кешеләре бергәләп ауга йөргәннәр, төрле үләннәр, җиләк-җимешләр җыеп туенганнар. Кыргый хайван тиресеннән киемнәр тегеп кигәннәр. Агач-бүрәнәләрдән йортлар сала белмәсәләр дә, яхшы итеп җылытылган куышларда яшәгәннәр. Бер урында гына тормыйча, еш кына үзләре аулый торган хайван көтүләре артыннан бер урыннан икенче урынга күченеп йөргәннәр.





Татарстан җирендәге иң борынгы кешеләрнең эш кораллары.

Моннан 7—10 мең еллар элек таш гасыры кешеләре ук һәм җәя уйлап тапканнар. Ук-җәя белән коралланган кешеләр ауга төркем белән түгел, берәмләп тә йөри алганнар. Вак җәнлекләр һәм кошлар аулаганнар. Бу вакытта аучылык белән беррәттән балыкчылык та бик киң таралган. Балыкны ыргаклы сөңгеләр белән тотканнар. Таш кораллар ясау һаман камилләшкән. Вак һәм юка гына таш кисәкләреннән җыеп ясалган пычаклар, кыргычлар барлыкка килгән. Үткен очлы таш кисәкләрен тишкеч, өтерге, борау итеп кулланганнар. Бу кораллар беренче карашка гына бик гади һәм тупас тоелалар. Чынлыкта исә алар белән итне, хайван тиреләрен, агачны бик җиңел кисеп булган.

Кешеләр, ниһаять, йортлар да салырга өйрәнәләр. Апас районының Кабык Күпер авылы янындагы борынгы торулыкны казыганда археологлар шундый йортларның берсенә тап булалар. Агач-бүрәнәләрдән җиткерелгән зур гына шалашсыман йортта бер ыруг кешеләре яшәгән.

Таш гасырның соңгы чорында, моннан 5—6 мең еллар элек, борынгы кешеләрнең тормышында мөһим үзгәрешләр килеп чыккан. Таштан эш кораллары ясаганда алар юну, кисү, бораулап тишү кебек яңа алымнар куллана башлаганнар. Мондый кораллар белән агач эшкәртү, йортлар салу, суда йөзү өчен көймәләр ясау ансатлашкан. Ниһаять, алар балчыктан төрле савыт-саба ясарга өйрәнәләр. Әгәр элек итне, балыкны учак ялкынында яисә күмердә генә кыздырып, чиле-пешле килеш ашасалар, хәзер инде чүлмәкләрдә пешереп, төрле үләннәр кушып, шулпалап ашарга мөмкинлек туган.

...Шулай итеп, таш гасыр — кешелек җәмгыятенең балалык чоры — әкренләп ахырына якынлаша. Тарихыбызда иң озын һәм иң авыр чор була ул. Меңнәрчә елларга сузылган дәвердә нинди генә уңышларга ирешелмәсен, кешеләр әле бөтенләе белән табигать көчләренә бәйле булып калган. Аларны ерткыч җәнлекләр әзәрлекләгән. Ау уңышлы чыкмаганда ачтан интеккәннәр, төрле авырулардан кырылганнар. Шуңа күрә алар арасында картайганчы яшәгән кешеләр бик аз булган. Мәсәлән, өйрәнүләр раслаганча, таш гасырның башлангыч чорларында һәр 100 кешенең кырыклабы 14 яшькә тикле үлә торган булган, унбишләбе генә 20 яшькә тикле яшәгән. Уртача гомер озынлыгы 23—25 елдан артмаган.

Шулай да гап-гади агач күсәк, ук-җәя һәм таш балталар белән коралланган кеше кырыс табигать көчләре белән көрәштә ахыр чиктә җиңүче булып чыга. Бу җиңүнең төп шарты шунда ки, алар, нык тупланган төркем булып, берберсенә ярдәм итешеп яшәргә өйрәнгәннәр, бергәләшеп ауга йөргәннәр, тапканнарын уртак иткәннәр. Кан-кардәш төркемнәр — ыруглар — кешелек җәмгыятенең нигезен тәшкил иткән. Ыруглар кабиләләргә берләшкәннәр. Мондый җәмгыятьне тарихта борынгы ыруглык җәмгыяте дип атыйлар. Борынгы ыруглык җәмгыяте чорында киләчәк буыннар үсеше өчен ныклы нигез салынган.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Борынгы кешеләрнең тормышын галимнәр ничек өйрәнәләр?
2. Таш гасыры чорында эш кораллары ничек камилләшкән? Рәсемнәргә карап сөйләп бирегез.
3. Борынгы кешеләрнең шөгыльләре археологик материалларда ничек чагылыш таба? Рәсемнәргә карап, һәр таш коралның ни өчен кулланылуын әйтеп бирегез.
4. Үзебезгә таныш булмаган сүзләрне язып кую өчен махсус «Тарихи сүзлек» булдырыгыз. Бу сүзлеккә түбәндәге сүзләрне аңлатып язып куегыз: «таш гасыр», «археология», «археологик истәлекләр», «торулык» (стоянка), «борынгы ыруглык җәмгыяте», «ыруг», «кабилә» һ. б.

4. ТАШТАН — МЕТАЛЛГА, АУЧЫЛЫКТАН — ТЕРЛЕКЧЕЛЕККӘ.

Эш коралларын ясау өчен меңнәрчә, йөз меңнәрчә еллар буена таштан да кулай материал табылмаган. Дөресрәге, табигатьтә очрый торган башка материалдан файдалана белмәгәннәр. Әмма кешелек җәмгыяте һаман үсештә булган. Борынгы кеше беркайчан да табигать-

тән бүген алганы белән генә канәгатьләнеп калырга теләмәгән.

...Дөньяның кайсыдыр бер почмагында моннан бик күп еллар элек борынгы кеше беренче тапкыр кулына очраклы рәвештә генә табылган бакыр кисәге алган. Суккалап караган — таш кебек кителмәгән, яньчелгән генә, янып торган учакта тоткан — эрегән. Шулай итеп тагын бер ачыш ясалган: кешеләргә бакырның беренче үзлекләре мәгълүм булган. Табылган бакыр кисәкләрен чүкеп яисә махсус калыпларда эретеп, башта бизәнү әйберләре, аннан соң эш кораллары да ясый башлаганнар. Ташка караганда йомшаграк булса да, эреткәч, төрле формаларга керә алуы белән кешеләрнең игътибарын бик тиз җәлеп иткән ул. Аның башка уңайлыкларын да күргәннәр. Мәсәлән, бакыр пычакның йөзе тупасланса, үткенләргә мөмкин булган; сынса да эшкә яраган ул — яңадан эретеп, кирәк әйберләр кою өчен файдаланганнар.

Бакырдан ясалган эш кораллары белән эшләү таш коралларга караганда уңайлырак булган. Бервакыт археологлар шундый тәҗрибә үткәргәннәр: бер иш нарат агачларның берсен таштан, икенчесен бакырдан ясалган борынгы балталар белән чабып аударырга уйлаганнар. Бу эшне таш балта белән 15, бакыр балта белән 5 минутта башкарып чыкканнар. Ә бакыр борау белән калын тактаны 22 тапкыр тизрәк тишәргә мөмкин икән!

Бакырдан коелган эш коралларының таралу чоры — бакыр дәвере — моннан 3600—4000 еллар элек булган. Ул вакытларда хәзерге Татарстан җирләрендә **волосово кабиләләре** яшәгән. Бу кабилә кешеләренең торулыгы беренче тапкыр Ока елгасы буенда Муром шәһәреннән ерак түгел урнашкан Волосово авылы янында казып тикшерелгән. Шуңа күрә аларны шартлы рәвештә волосово кабиләләре дип атаганнар. Безнең республикада волосово кабиләләре белән бәйле 50 ләп торулык табылды.

Волосово кабиләләре таш дәвереннән металл дәверенә күчү чорында яшәгәннәр. Алар нигездә аучылык һәм балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр. Нәкъ менә шушы чорда игенчелек һәм хайван асраучылыкның беренче билгеләре дә барлыкка килгән. Археологик казу эшләре вакытында табылган таш китмәннәр, бөртек угычлар, эт һәм кәҗә сөякләре шул турыда сөйлиләр. Дөрес, игенчелек тә, терлекчелек тә тиз генә ныклап тамыр җәеп китә алмаган. Бакыр эшкәртү башлангыч хәленнән әлләни алга китмәгән. Шулай да, ни генә булмасын, алдагы буыннарның тотрыклы үсеше өчен бөтен шартлар өлгереп җиткән булган инде.

Моннан 3500—3600 еллар элек яшәгән борынгы кабиләләр, ниһаять, бронза кою серләренә дә өйрәнәләр. Бронза — нигездә шул ук бакыр ул, тик аны эреткәндә төр-

ле кушылмалар гына (мәсәлән, кургаш катнашмасы) өстәгәннәр. Каян алганнар соң шулкадәр бакырны? — дип сорарсыз сез. Хикмәтле бакыр базлары турында ишеткәнегез бармы сезнең? Республикабызның кайбер районнарында, бигрәк тә Ык, Минзәлә, Зәй елгалары буйларында, Сарман, Әлмәт, Шөгер, Бөгелмә, Азнакай якларындагы тауларда әле дә сакланып калганнар алар. Әбибабаларыгыздан сорап карагыз әле — беләләрдер алар. Бакыр рудасы (мәгъдән) чыгарганнар анда. Әле 18 нче йөзләрдә дә бу якларда әллә никадәр бакыр кою заводлары эшләп утырган. Бу ятмалар, һичшиксез, борынгы кешеләргә дә билгеле булган.

Бронза гасыры — борынгы ыруглык җәмгыятенең чәчәк ату дәвере ул. Волосоволылар токымыннан булган **Казан буе кабиләләре** шул дәвернең иң күренекле вәкилләреннән санала. Төп җирләре Казан тирәсендә Идел — Кама буйларында урнашкан. Чынлыкта ничек аталганнардыр алар, моны берәү дә белми хәзер.

Ни өчен тарихка кереп калганнар соң Казан буе кабиләләре? Чөнки алар бу төбәк халыклары арасында чын-чынлап беренче игенчеләр, хайван асраучылар һәм металл коючылар булалар. Кайчан гына волосоволыларның хуҗалык тормышында төп рольне уйнаган аучылык, балыкчылык бөтенләй арткы планга күчәләр.



Волосово һәм Казан буе кабиләләренең эш кораллары.

Казан буе кабиләләре яшәгән кайсы гына торулыкны казып карама, һәрберсендә йорт хайваннарының сөякләрен, игенчелек белән бәйле эш коралларын — бронза китмәннәр, ураклар, таштан ясалган бөртек угычлар табарга мөмкин. Хуҗалык баз-чокырларын ач-

канда хәтта сирәк-мирәк тары, арпа бөртекләре дә очрый! Күмерләнгән хәлдә яхшы саклаңалар икән алар.

Сүз дә юк, мондый үзгәрешләр таш гасыры белән чагыштырганда бик зур алга китеш була. Әйе, тормыш һаман алга барган, яшәү шартлары әкренләп җиңеләя төшкән. Кыргый хайваннар аулау яисә балык тоту ел әйләнәсендә гел уңышлы гына булып тормаган. Җир эшкәртеп, иген игә башлагач, азык-төлек запасын бермә-бер арттырырга мөмкинлек туган. Өстәвенә, җәйләүдә сыеры-сарыгы йөргән. Ашарга ите-сөте, кием өчен тиресе, йоны дигәндәй...

Бронза дәверендә килеп чыккан уңай үзгәрешләр халык санының артуына да китерә. Хәзерге көндә Казан буе кабиләләренең 400 дән артык торулыгы каберлекләре билгеле. Кайбер зуррак төбәкләрдә 500 гә якын кеше яшәгән.

Ә нинди телдә сөйләшкәннәр соң Казан буе кабиләләре? Борынгы фин-угор телләренең берсендә,— диләр галимнәр,— ягъни алар тугандаш мари, удмурт, коми халыкларының ерак бабалары булганнар.

Менә, шулай итеп, илебез тарихында тагын бер мөһим чор — бронза гасыры да — үтеп китә. Кешелек җәмгыяте үзенең үсешендә янәдән бер баскычка югары күтәрелә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен таш дәвереннән металл дәверенә күчүне кешелек тарихында уңай күренеш, алга китеш диләр?
2. Уйлап карагыз әле, ни өчен башта таш, аннан соң гына металл (бакыр, бронза) дәвере килә?
3. Волосово һәм Казан буе кабиләләренең хуҗалык үсешен чагыштырып сөйләгез. Моның өчен рәсемнәрдән файдаланыгыз.
4. «Тарихи сүзлек»не шушы параграфта очраган яңа сүзләр белән тулыландырыгыз, аларга аңлатма бирегез.

5. ТИМЕР ГАСЫРЫ. АНАНЬИНО КАБИЛӘЛӘРЕ

19 нчы йөзнең урталарында «Казан губернасы хәбәрләре» дигән газета ниндидер бер тарихи язмадан өзекләр бастырып чыгара. Анда Аксак Тимернең, Болгарны басып алгач, мөселманнарның изге каберләрен карарга дип, Алабуга янындагы атаклы «Шайтан каласы»на барып кайтуы турында язылган була. Күп тә үтми, Алабуга шәһәренең башлыгы И. В. Шишкин (күренекле рус рәссамы И. И. Шишкинның әтисе) Мәскәү профессоры археолог К. И. Невоструевтан хат ала. «Алабуга тирәсендә борынгы каберлекләр, курганнар, йә булмаса соңгырак чорларга караган шәһәр-

авыл урыннары юкмы икән,— дип яза ул,— булса, хәбәр итсәгез иде». Моңа тикле дә туган як тарихы белән һәрдаим кызыксынып килгән шәһәр башлыгы Мәскәүдән алынган хатка җавапны тиз таба. «Алабугадан ерак түгел генә Ананьино авылы янында ниндидер иске зират бар,— дип җавап яза ул.— Каберләр өстендә борынгы ташлар да сакланган» Бу тирәдә бронзадан, тимердән ясалган әллә нинди сәер әйберләр дә табыла икән. Аларның берничәсен И. В. Шишкин Мәскәүгә җибәрә.

Бу кызыклы табылдыкларны караганнан соң, К. И. Невоструев Ананьино каберлеген тизрәк казып тикшерергә кирәк дигән фикергә килә. Әмма борынгы каберлек урнашкан җирләрнең хуҗасы казу эшләрен бөтенләй икенче кешегә, П. В. Алабинга тапшыра.

1858 елның җәендә күрше-тирә авыллардан чакырып китерелгән йөзләгән крестьян дәррәү эшкә тотына. Бер көн эчендә алар 50 гә якын кабер ачалар, кеше сөякләре арасында бик күп бизәнү әйберләре, эш һәм сугыш кораллары, балчык чүлмәкләр, тагын әллә нәрсәләр табалар. Тик казу эшләре тәртипсез үткәрелә, каберлекнең планын да кәгазьгә төшереп, табылган әйберләрнең ни рәвешле ятуын юньләп барлап тормыйлар. Ә бит борынгы кешеләрнең көнкүреш йоласын өйрәнү өчен болар бик мөһим! Ярый әле, И. В. Шишкинның малае Иван җитешә алган кадәр аларның рәсемнәрен ясап калырга тырыша.

Менә шул рәвештә фән дөньясында бик кызыклы яңа археологик истәлек — Ананьино каберлеге пәйда була. Алда күп еллар буена галимнәрнең игътибар үзәгендә торачак әле ул. Ә хәзергә шунысы мәгълүм була — бу истәлек һич тә профессор К. И. Невоструевны кызыксындырган мөселманнарның изге каберлеге түгел. Бик күпкә борынгырак булып чыга ул.

Кемнәр күмелгән соң монда? Бу сорауга тиз генә җавап табылмый. Археологлар эшкә тотына. Алабуга тирәсендә, Идел-Кама һәм аларның кушылдыклары Агыйдел, Вятка, Ветлуга буйларында 60 тан артык борынгы авыл эзләре һәм 30 лап каберлек табыла. Казу эшләре киң җәелеп китә. Барысында да бертөрле табылдыклар, бер-берсенә охшаш күмү йолалары. Димәк, бер яисә берничә тугандаш кабилә кешеләре яшәгән монда. Аларга **ананьино кабиләләре** дигән исем бирәләр.

Тиздән шунысы ачыклана: ананьино кабиләләре безнең якларда, беренчеләрдән булып, тимер дәверен башлап җибәргәннәр икән. Тимер — җир йөзендә иң күп таралган металларның берсе. Ләкин табигатьтә чиста тимер юк, ул бары тик руда хәлендә генә очрый. Аны махсус мичләрдә бик югары температура (1530°) булдырганда гына рудадан аерып була. Бу —

2 Ч-279



Ананьино кешесенең кабере өстенә куелган таш.

Ананьино сугышчысы.

бик катлаулы эш. Шуңа күрә дә тимер дәвере бронза дәверенә караганда соңрак башлана. Бу моннан 2700 еллар элеккә туры килә. Ләкин тимер көндәлек тормышка бик җиңел генә кереп китми. Эш һәм сугыш коралларын һаман да күбрәк бронзадан ясау дәвам итә. Мең еллап вакыт үткәч кенә, тимер көнкүрештә үзенең тулы хокукын яулап ала.

Ананьино кешеләре башлыча терлек асраучылык белән шөгыльләнгәннәр һәм иген иккәннәр, шул ук вакытта балык та тотканнар, ауга да йөргәннәр. Алар күрше кабиләләр белән генә түгел, ә Урал, Себер, Урта Азия, Кавказ халыклары, хәтта борынгы Иран һәм Греция дәүләтләре белән дә сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырганнар.

Ананьино чорында төрле хәрби ныгытмалар, крепостьлар төзү башлана. Димәк, алар үзара еш кына сугышып та торганнар. Кабилә юлбашчылары, ыруг башлыклары җәмгыятьтә моңарчы

булмаган өстенлекләрдән файдалана башлаганнар. Кешеләр арасында милек булдыруда һәм табылган байлыкларны бүлүдә тигезлек беткән. Бу турыда археологик казылмалар бик ачык итеп сөйлиләр.

Шул җәһәттән ананьино кабиләләренең күмү йолалары турында бер-ике сүз әйтеп китик әле. Мәетне алар, артык тирән булмаган чокырлар казып, аяклары белән якындагы елгага каратып күмә торган булганнар. Бу дөньядан теге дөньяга, имеш, бары тик су аша гына күчәргә мөмкин. Кайбер каберләрдә икешәр, хәтта бишәр-алтышар һәм аннан да күбрәк мәетләр ята. Кайчакта аларны, агач-бүрәнәләрдән кечерәк кенә «мәетләр йорты» салып, шул йортларга урнаштырганнар. Үлгән кешеләрне киендереп, хатын-кызларны бизәнү әйберләре белән, ир-атларны үзләре исән чакта файдаланган сугыш кораллары белән күмгәннәр. Баш очына, чүлмәккә салып, төрле-төрле ризыклар куйганнар. Кабилә юлбашчылары һәм ыруг башлыклары күмелгән каберләрдән бигрәк тә бай табылдыклар чыга. Алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләре дә еш табыла. Бай кешеләрнең кабер өсләренә таш кую йоласы да шушы чорда барлыкка килгән. Ул ташларга сугышчы һәм сугыш кораллары сурәте төшерелгән.

Ананьино кабиләләре — элегрәк чорда, бронза дәверендә яшәгән Казан буе кабиләләренең дәвамчылары. Димәк, алар да хәзерге мари, удмурт һәм коми халыкларының борынгы бабалары. Шул ук вакытта ананьино кабиләләре арасында Себер һәм Алтай якларыннан күчеп килгән кешеләр дә булган. Болары исә борынгы төрки халыкларының Идел-Кама буйларына күчеп утырган бер төркемедер дип исәпләнелә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен безнең якларда тимер дәверендә яшәгән кабиләләрнең исемен «ананьино» дип атаганнар?
2. Ананьино кабиләләренең шөгыльләре нинди булган?
3. Ананьино кабиләләренең варислары кемнәр?

6. БОЛАННАР КЕШЕ БУЛГАН ЗАМАННАРДА

Бик озак дәвам иткән беренчел кешелек җәмгыяте. Беренче эш һәм сугыш кораллары, беренче өйләр, беренче көймә, кораблар, беренче кием-салым, беренче җырлар, әкиятләр, табышмаклар, беренче биюләр, беренче рәсемнәр — барысы да беренчел кешелек җәмгыятендә барлыкка килгәннәр. Шул беренчел... булмаса без бүген яши торган атом, ракеталар, космос заманы да булмас иде.

Борынгы кеше үзе дә сабый кебек булган ул чорда. Ул үзен әйләнә-тирә дөньяның аерылгысыз бер кисәге итеп тойган. Әйләнә-тирәдәге һәрнәрсә кеше кебек яши: болан да, аю да, үсеп утырган агач та, күктәге ай да, шаулап агучы елга да җанлы кешеләр кебек көлә, елый, сөйләшә, кайгыра белә дип уйлаган ул.

Сезнең батыр егет патша кызын коткарып алып киткәч, артыннан дию пәриенең куа чыгуы хакында әкият укыганыгыз бардыр инде. Егет белән кыз дию пәриеннән котылу өчен тылсым ярдәмендә алмагач белән сандугачка, бака белән күлгә, боланнарга әвереләләр. Дию аларны танымый үтеп китә. Ә моңа борынгы кеше әкият итеп карамаган. Ул үзен табигатьтә очрый торган теләсә нәрсәгә әверелә алам дип ышанган. Алай гына түгел, борынгы кеше агачлар, үләннәр, хайваннарны үзенең туганнары дип уйлаган. Алар арасында аның иң борынгы бабасы — ыруг башлангычы да — яшәгән. Ыруг кешеләре аның рухына табынганнар. Иң кыен вакытларда ул ярдәмгә килер дип аның күңелен күрә, аңа төрле ризыклар бирә, ягымлы сүзләр әйтә торган булганнар. Чыннан да, хайван баба ярдәмгә килгән.

Бик борынгы заманнарда булган ди бу. Безнең борынгы бабалар таулы, урманлы җирләрдән күченеп барганда, аларны күпсанлы явыз дошманнар чолгап алган. Үлем инде котылгысыз кебек күренгән. Әмма шул чакта аларның каршысында үтә зур, бик көчле ак бүре кыяфәтенә кереп, ыруг бабасы пәйдә булган. Ак бүре чолганышта калган кешеләргә үзе артыннан барырга кушкан. Ул аларны яшерен юл аша чолганыштан алып чыккан. Шулай итеп, иң борынгы бабаларыбызны үлемнән коткарып калган, имеш.

Хайваннар кеше, кешеләр хайван кыяфәтенә керә, боланнар кеше булып күренә алган вакытлар бу. Тагын мең еллар үткән. Бер үк төсле булып көннәр, айлар, еллар гына түгел, гасырлар үтеп киткән. Тарих әкрен генә алга барган. Кешеләр ут тергезә белә башлаганнар, ук-җәя уйлап тапканнар, беренче өйләр кора башлаганнар. Болар шул вакыт өчен бүген космоска очу, атом серләрен ачу кебек ачышлардан ким булмаган.

Башкортстанда Шүлгән-Таш (Капово) мәгарәсендәге сурәтләр.

Борынгы аучы очып баручы кошларга ук төбәгәндә зәңгәр күкнең матурлыгына да сокланып карый башлаган.

Безнең җирләрдә 40 мең ел элек беренчел сәнгать, ягъни кеше ясаган беренче сыннар, рәсем, биюләр, театр уйнау барлыкка килгән.

Борынгы кеше ясаган рәсемнәр күп очракта бертөрле, һәркайда гел эре җәнлек-хайван рәсемнәре. Башкача ничек булсын! Күмәк аучылык белән көн күргән кеше өчен бу хайваннар төп туклану, киенү, яшәү чыганагы булган. Шуның өчен дә ул ауда очраган хайваннарның рәсемен үзләренең изге табыну урыннары, гыйбадәтханә, тау куышлары стеналарына ясаган.

Шундый тау куышларының берсе Урал тавының көньягында, ямьле Агыйдел буена урнашкан. Ике катлы мәгарәнең стеналарына борынгы кеше канны, кояшны, утны аңлаткан кызыл буяу белән табигый зурлыкта мамонт, мөгезборын, кыргый ат рәсемнәрен ясаган.

Борынгы кеше өчен бу рәсемнәр, хайваннарның үзләре кебек, җанлы булып тоелган. Ул шушы рәсемнәр янында, аларның ныграк үрчүләрен теләп һәм аулар уңышлы булсын дип, аларның күңелен

күреп, төрле йолалар башкарган. Ауга чыгар алдыннан шушы рәсемнәр янында кешеләр, җәнлек маскалары киеп биегәннәр, җырлаганнар, таш уклар, сөңгеләр белән рәсемдәге хайваннарны «үтергәннәр». Шуннан соң гына борынгы аучы сунарның уңышлы үтәчәгенә ышанган. Шулай беренче театр, беренче бию, җыр, шигырь барлыкка килгән.

Тагын гасырлар үткән. Кеше рәсемнәрне кечерәйтеп ясарга да өйрәнгән. Шулай итеп, тау куышларын гына түгел, аның коралларын, савыт-саба, киемнәрен дә бизи башлаган. Әмма бу матур бизәкләр гади генә булмаган. Алардагы һәр сызык нәрсәнедер белдергән. Менә бу түгәрәк — кояш; дулкынлы сызык — елга, диңгез; бу киртләч сызык — тау; менә беренче ашлык башаклары. Болар хәрефле язуның иң борынгы «бабалары» булганнар.

Еш кына савыт-саба тоткаларын болан, поши, аю кыяфәтендә ясаганнар. Имеш, бу хайваннар савыт эчендәге әйберләрне явыз көчләрдән саклаганнар.

Борынгы кеше өчен рәсемнәр генә түгел, гади сүз дә табигатькә, тирә-юньгә, кеше тормышына тәэсир итәрлек кодрәтле көчкә ия булган. Әнә бит «Сак-Сок» турындагы хикәяттә әниләр сүзен тыңламаган балаларга каргыш бик тиз төшә. Әниләре каргагач, ике туган бер-бере белән мәңге очрашмас кошларга әверелә.

Борынгылыкта ата-баба сүзе зур кодрәткә ия булган. Юкка гына борынгылар: «Картлар сүзен ишеткәндә, бүрегеңне куеныңа куй», димәгәннәр. Ягъни аларны хөрмәт белән, баш киемеңне салып, тыңларга кирәк. Картлар, борынгылар сүзеннән мәкальләр, әйтемнәр барлыкка килгән.

Ыруг учагы янында иң мөхтәрәм кешеләр — аксакаллар озын-озын хикәятләр сөйләгәннәр. Табигатькә, утка тәэсир итәрлек тапкыр сүзләр әйткәннәр. Алардан без хәзер дә яратып укый торган әкиятләр, табышмаклар барлыкка килгән.

Әйе, борынгыларның үз мәктәпләре дә яшәгән. Дөрес, анда дәреслекләр, дәфтәрләр булмаган. Әмма ул мәктәпне һәркем тәмамлап чыгарга тиеш булган. Буй җиткергән егетләрне ыру яшәгән җирдән ерактагы куркыныч урман-тауларга алып китеп аучылыкка, дошманнарга каршы көрәшергә өйрәткәннәр. Табигатьнең тагын бик күп серләренә, ыру тәртипләренә төшендергәннәр. Шуннан соң гына аңарга аучы сөңгесе бирелгән, ыруның чын кешесенә әйләнгән. Алар бу мәктәпләрдә бик тырышып укыганнар. Башкача мөмкин дә булмаган. Чөнки бу тормыш мәктәбен начар үзләштергән кеше ерткыч хайваннарны аулаганда, дошманнарга каршы көрәштә ыруга бәла генә китергән.

Борынгы кеше үзен яхшы һәм

яман җаннар уратып алган дип тойган. Кеше үлгәч, аның җаны кош кебек очып китә, янәсе. Җанны күккә Тәңре хөкеменә алып китәргә әзерләнгән лачын-кош сурәтләре болгар кабер ташларында ясалган. Ә теге дөньяда ул яңадан тәнгә кайта дип ышанганнар. Шуның өчен үлгән кешене күмгәндә, аңа теге дөньяда да кирәк булыр дип, каберенә кораллар, киемнәр, ризыклар куйганнар.

Табигатьне, җаннарны изгеләштерү, Тәңрегә ышану динне барлыкка китергән.

Табигатьне Алла итеп күргән кеше аңа корткычлык эшли алмаган. Табигатькә карата борынгы кешедәге мөнәсәбәт хәзерге заман кешеләрендә дә сакланса, бүген күпме урманнар, хайваннар, елгакүлләр исән калыр иде.

Боланнар кеше булган вакытларда менә шулай яшәгәннәр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен беренчел кешелек җәмгыяте бик озак дәвам иткән?
2. Беренче рәсемнәр нинди булган?
3. Беренче экиятләр ничек барлыкка килгән?

7. ҺУННАР — ИҢ БОРЫНГЫ ТӨРКИ БАБАЛАРЫБЫЗ

Моннан 2—3 мең еллар элек хәзерге Монголия һәм Төньяк Кытай далаларында, Байкал күле буйларында һәм Алтай таулары тирәсендә төрки кабиләләр яшәгән. Кытай елъязмалары аларны сөннәр яисә һуннар дип йөрткәннәр.

— Һуннарның безгә ни катнашы бар соң? — дип сорарсыз сез.— Алар әнә нинди еракта яшәгәннәр ич. Безнең төп бабаларыбыз болгарлар түгелмени?

Сорауларыгыз урынлы. Әмма сабыр итик. Исемнәре болгарларларга кадәр берничә йөз ел элек мәгълүм булган һуннар белән таныштырып китүебез юкка гына түгел. Менә тыңлагыз.

Борынгы кытай елъязмачысы һуннар турында, алар бик көчле һәм күпсанлы халык, беркемгә дә буйсынырга теләмичә, аерым дәүләт булып яшиләр, дип язып калдырган. Аларның үз патшалары — каганнары — булган, халык белән идарә итүнең үз тәртипләре яшәгән. Кырыс табигать шартларында аларга шәһәр, авыллар кору, игенчелек белән шөгыльләнү мөмкин булмаган. Шуңа күрә һуннар мал асраучылык белән көн күргәннәр һәм күчмә тормыш иткәннәр. Ат һәм сарык асрау аларның төп шөгыле, байлыгы һәм яшәү чыганагы булган.

Һуннарның бер өлеше утрак тор-

мыш белән дә көн күргән. Археологлар Байкал күле буенда, Улан-Удэ шәһәреннән ерак түгел, Иволга поселогы янында аларның зур гына каласын казып тикшерделәр. Биредә дистәләрчә йорт урыннары, ашлык саклау базлары, тимер һәм төсле металлар кою өчен махсус ясалган мичләр, төрле һөнәр иярәренең эш кораллары табылды. Тимердән, бронзадан һәм сөяктән искиткеч зур осталык белән ясалган әйберләрне, дулкынсыман бизәкләр төшерелгән чыдам балчык савыт-сабаларны күреп, әле хәзер дә гаҗәпкә калырлык!

Әлбәттә, ел әйләнәсендә берничә йөз, хәтта мең чакрымнар үтеп, бертуктаусыз диярлек көтүлектән көтүлеккә күченеп көн күргән халык калаларда яшәмәгән. Аларның туган җирләре — иксез-чиксез далалар; торыр урыннары — тиз җыела торган киез тирмәләр; киемнәре — җылы тун, йомшак табанлы тире итекләр, мех бүрекләр; ашау-эчүләре ит, сөт, кымыз, эремчек булган.

Һуннарда хәрби эш бик югары дәрәҗәдә торган. Шул чорның иң камил сугыш кораллары, бигрәк тә ук һәм җәяләр, аларда гына була. Сызгыра торган уклар турында ишеткәнегез юкмы сезнең? Һуннар уйлап тапкан корал ул. Тимер ук очына сөяктән ясалган сыбызгы куеп атканнар. Көтмәгәндә, меңнәрчә җәядән уклар очыртканда, дошманның халәтен күз алдына китереп карагыз.



Һун җайдагы. *Борынгы рәсем.*

Моннан 2200 еллар элек, Модэ исемле каган (патша) вакытында, һуннар дәүләте бик нык көчәеп китә. Алар, үзләренең күршеләрен бер-бер артлы тар-мар итеп, Кытай дәүләте белән аяусыз көрәшкә күтәреләләр, күп кенә җирләрен тартып алалар. Модэ каган җитәкчелегендәге һун гаскәре кытайларның 320 меңлек зур армиясен камап ала һәм аны җиңелүгә дучар итә. Шушы вакытлардан соң Кытай дәүләте һуннарны үзе белән бер дәрәҗәдә көчле дип таный һәм озак еллар буена аларга салым түләп тора.

Кытай императоры һуннарны илдән куып чыгару һәм аларны бөтенләй юк итү теләге белән яна. Ике арада өзлексез сугышлар булып тора. Һуннарның һәм башка күчмә кабиләләрнең һөҗүмен туктатып тору өчен кытайлар илнең төньягында йөзләрчә чакрымга сузылган биек таш стена төзергә керешәләр. Ул заманнарда салынган Бөек Кытай стенасы әйбәт сакланган хәлдә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Ике күрше арасында өзлексез диярлек барган сугышлар һуннарны әкренләп көчсезләндерә.

Аларның үзләре арасында да бердәмлек бетә. Дәүләт берләшмәсе икегә таркала. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, ди бит халык. Шулай булып чыга да. Тиздән кытайлар һәм алар ягында торып сугышучы башка кабиләләр һуннарны тулысынча диярлек тар-мар итәләр. Бу вакыйга 1 гасырда, ягъни моннан 1900 еллар чамасы элек була.



Һуннар кулланган бронза казан.

Һуннарның бер өлеше, җиңелгәч, көнбатышка таба хәрәкәт итә башлый. Юлларында очраган әллә никадәр көчмә һәм ярымкүчмә кабиләләрнең кайсын җиңеп, кайсын үзләренә ияртеп, алар хәзерге Казахстан далалары буйлап Арал, Каспий диңгезе тирәләренә килеп чыгалар. Бу күченеш өч гасыр чамасы дәвам итә. Ниһаять, 375 елда алар, Иделне кичеп, тагын да көнбатышкарак юл тоталар һәм Көнчыгыш Европага үтеп керәләр. Мәшһүр полководец Аттила җитәкчелегендәге һуннар 5 нче гасырда хәзерге Италиягә, Франциягә һәм Испаниягә кадәр барып җитәләр, кайчандыр куәте белән бөтен дөньяда дан тоткан Рим империясен тар-мар итүдә катнашалар. Иксез-чиксез территорияне биләп алган Һун дәүләте бөтен Европаны дер селкетә.

Һуннар берләшмәсендә төрки телдә сөйләшә торган кабиләләр була. Ерак Алтай далаларыннан Кара диңгез буйларына күчеп утырганда, алар тыныч яшәп ятучы күп кенә халыкларны урыннарыннан кузгаталар. Алар арасында болгарлар һәм савирлар (суарлар) да була. Берәүләр, телиме-теләмиме, һуннарның хәрәкәтенә кушылалар, икенчеләре, туган якларын калдырып, яшәү өчен тынычрак урыннар эзләп китәләр.

Шушы вакытларда һуннарның һәм алар белән бергә хәрәкәт итүче кабиләләрнең кайбер төркемнәре Идел-Чулман буйларына да килеп чыкканнар. Археологлар бу җирләрдә һуннарга гына хас булган әйберләр табалар. Мәсәлән, Аксубай районының Татар Сөнчәлесе авылы янында табылган ике тоткалы, матур итеп бизәлгән зур бронза казаннар, һичшиксез, һуннарныкы булган.

Алабуга районының Турай авылы янында 4—5 нче гасырларга караган борынгы зират бар. Каберләре өстенә өелгән биек курганнар элегрәк әллә кайлардан ук күренеп торган. Каберлекне казыганда табылган әйберләр — алтын-көмеш белән бизәлгән тимер баш-

лык (шлем) һәм көбә күлмәк (кольчуга), алтынланган саплы кылыч һәм хәнҗәрләр, ук-сөңге очлары һәм балталар биредә бай сугышчылар күмелгәнлеге турында сөйлиләр. Алар һуннар белән көнчыгыштан күчеп килгән төрки кабилә кешеләре булган.

Менә, күрдегезме инде, милли тарихыбызның тирән тамырлары һуннар чорына ук барып җитә икән. Борынгы кытайлар һуннарны икенче төрле ничек атаганнар әле? Әйе, сөннәр дип. Роберт абыегыз Миңнуллинның бер шигырен искә төшерик:

— Әнкәй мине Сөннән алып кайткан,

Сөн суында юган иң элек...

Әйе, һун бабаларыбызның исеме әле һаман да булса онытылмаган икән!

Сораулар һәм биремнәр:

1. Һуннар кемнәр алар, шөгыльләре нинди булган?
2. Картадан һуннар яшәгән урыннарны табыгыз (Байкал күле, Монголия, Кытай, Алтай таулары, Арал, Каспий, Кара диңгез һ. б.).
3. Безнең тарихыбыз һуннар белән ничек бәйләнгән?

8. ТӨРКИ КАГАНЛЫГЫ. БӨЕК БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕ

(6—7 нче гасырлар)

6 нчы гасырда Көньяк Себер һәм Алтай далаларында яшәүче кабиләләрнең тарихи үсешендә моңа кадәр күрелмәгән яңа күтәрелеш башлана. Тимер эшкәртү бик нык алга китә, һөнәрчелек үсә. Шулай да хуҗалыкның нигезен элек-электән үк малчылык тәшкил иткән. Кайбер төбәкләрдә иген дә иккәннәр.

Хуҗалык үсеше белән борынгы ыруг-кабилә мөнәсәбәтләренең җимерелүе сыйнфый җәмгыять тууга сәбәп булган. Кешеләр арасында меңнәрчә еллар буе яшәп килгән тигезлек беткән. Байлыкның күп өлеше — зур-зур көтүлекләр, малтуар, коллар — элеккеге ыруг-кабилә башлыкларыннан килеп чыккан каган һәм аның туганнары, гаскәр башлыклары, бәкләр кулына күчә барган. Гади халык көтү көткән, байларга салым түләгән, бетмәс-төкәнмәс сугышларда катнашкан.

552 нче елда төрки телләрдә сөйләшүче дистәләрчә кабиләләрне берләштергән зур дәүләт — Төрки каганлыгы барлыкка килә. Бу дәүләткә нигез салучылар Бумын һәм аның кече туганы Истәми каган күрше халыклар белән сугышып торганнар, малларын, байлыкларын тартып алып, әсир төш-

кән кешеләрне үз гаскәрләренә кушканнар, кол иткәннәр. Хәтта Кытай императоры да, җиңелгәннән соң, каганлыкка ел саен 100 мең кисәк ефәк тукыма белән салым түләп торган.

Төрки каганлыгы төзелгәннән соң күп тә үтми, кайбер кабиләләр элегрәк һуннар үткән юллар буйлап көнбатышка таба хәрәкәт итә башлыйлар. Истәми каган үзенең улы Кара-Чурин белән Урта Азиядә эфталитларга һәм согдакларга каршы берничә тапкыр яу чаба, Иран һәм Византия дәүләтләре белән уңышлы сугышлар алып бара. Тиздән алар Арал һәм Каспий диңгезе буйларына килеп чыгалар, Идел елгасына кадәр булган җирләрне басып алалар.



Кубрат хан.
Рушан Шәмсетдинов рәсеме.

Таш сын — дала кешеләренең кабере өстенә куела торган борынгы һәйкәл.

Тагын да көнбатышкарак, Иделнең уң ягына, төрки гаскәрләр озак вакыт үтеп керә алмаганнар. Монда, Төньяк Кавказ һәм Азак (Азов) диңгезе буйларында, элегрәк һуннар белән килеп утырган халыклар — болгарлар, савирлар, аланнар яшәгән. Бу җирләрдә алар шактый нык төпләнеп утырган булалар. Кайбер тарихи язмаларда, болгарларның хәтта үз шәһәрләре дә бар, диелә. Әлбәттә, бу халыкларның берсе дә тиз генә Төрки каганлыгына буйсынырга

теләмәгән. Болгарлар һәм савирлар, мәсәлән, буйсынгач та әле төркиләргә каршы берничә тапкыр баш күтәрәләр, мөстәкыйльлеккә омтылалар. Шушы көрәш барышында 6 нчы гасырның ахырларына таба болгарларның куәтле союзы — дәүләт берләшмәсе барлыкка килә. 7 нче гасыр башларында, атаклы Кубрат хан вакытында бу мөстәкыйль дәүләт берләшмәсе **Бөек Болгар** исемен ала.

Бөек Болгар дәүләтенең төп җирләре Азак һәм Кара диңгез буйларында, Дон һәм Кубань елгалары арасында урнашкан булган. Башкала итеп Тамань ярымутравындагы Фанагория шәһәрен үстергәннәр. Бу дәүләттә болгарлардан башка да күп кенә төрки халыклар яшәгән. Аларның төп шөгыле күчмә терлекчелек булган. Һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре дә хуҗалык тормышында әһәмиятле урын тоткан.

Тик Бөек Болгар дәүләтенең гомере бик кыска була. 7 нче гасырның урталарында, Кубрат хан үлгәч, ул әкренләп таркалып бетә. Дәүләт биләмәләрен Кубратның уллары үзара бүлешеп бетерәләр. Аларның берсе, Аспарух исемлесе, үзенең буйсынуында торган бер төркем болгарларны ияртеп, көнбатышка, Дунай буена юнәлә. Биредә алар, славяннар яшәгән җирләрне яулап алып, үзләренең хакимлекләрен урнаштыралар һәм 681 елда Дунай Болгариясе дигән яңа дәүләт төзиләр.

Болгарларның күпчелеге, Кубратның икенче улы Батбай белән бергә, үзләренең төп җирләрендә торып кала. Тиздән алар хәзәрләр буйсынуына күчәргә мәҗбүр булалар.

* * *

Төрки каганлыгы чорында, ягъни 6—7 нче гасырларда, төрле халыкларның күчеш хәрәкәтләре гадәти күренеш булган. Идел-Чулман буйларында яшәүче кабиләләр арасында нинди үзгәрешләр булган соң? Бәлки халыклар күчешенең бу дулкыны безнең якларга кадәр килеп җитмәгәндер? Килеп җиткән икән шул! Менә бер мисал.

Төрки каганлыгы Каспий, Азак, Кара диңгез буе далаларында хакимлек итү өчен басып алу сугышлары алып барганда Идел белән Чулман кушылган төбәкләрдә ниндидер яңа кабиләләр пәйда була. Аларны имәнкискәлеләр дип йөртәләр (торган урыннары беренче тапкыр Лаеш районының Имән Кискә авылы янында казып тикшерелгәнгә күрә шулай атыйлар). Имәнкискәлеләрнең бөтен культурасы — йортлары, савыт-сабалары, бизәнү әйберләре, күмү йоласы һ. б.— моңарчы яшәгән җирле кабиләләрнекеннән бик нык аерылып тора. Мәсәлән, алар мәетләрне башта киендергән килеш яндырып, соңыннан учактагы көл-күмерне һәм сөяк калдыкларын бал-

чык чүлмәкләргә тутырып, кечкенә чокырларга күмә торган булганнар.

Имәнкискәлеләрне оста игенчеләр дип әйтә алабыз. Алар җирне, безнең якларда беренчеләрдән булып, ат җигелгән сукалар белән сөрергә өйрәнгәннәр. Терлек асрау да төп шөгыльләрдән саналган. Казу эшләре вакытында сирәк кенә булса да хәтта дөя сөякләре дә очраштыргалый. Урта Азия һәм Казахстан якларыннан китергәннәрдер, күрәсең, ул дөяләрне Ерак өлкәләр белән дә сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырылган булса кирәк. Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтик: имәнкискәлеләр, җирле кабиләләр арасында беренчеләрдән булып, сәүдә эшендә металл акчалар куллана башлыйлар. Беренче акчалар озынча бронза коелмалар формасында була.

Кемнәр алар, имәнкискәлеләр? Төрки халыкмы алар, әллә кайберәүләр уйлавынча, славяннармы? Бу сорауларга әле һаман да төгәл генә җавап юк. Тик шунысы гына билгеле: алар, һичшиксез, Төрки каганлыгының яулап алу сугышлары нәтиҗәсендә, туган җирләрен ташлап, безнең якларга сыену урыны эзләп килгән кабиләләр булса кирәк.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Төрки каганлыгы нинди территорияләрне биләп торган?
2. Бөек Болгар дәүләте турында сөйләгез. Кемнәр алар Кубрат хан, Аспарух һәм Батбай?
3. Төрки каганлыгы чорында безнең хәзерге Татарстан территориясендә нинди үзгәрешләр булган?
4. Төрки каганлыгы чоры безнең тарихыбыз белән ничек бәйләнгән?

9. ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫ ҺӘМ БОЛГАРЛАР

7 нче гасыр урталарында Кубрат хан төзегән Бөек Болгар дәүләтен таркатуда хәзәрләрнең дә роле булган. Бөек Болгар җимерелгәннән соң аның урынында Хәзәр каганлыгы калкып чыга. Кемнәр соң алар хәзәрләр һәм аларның тарихын белү безгә ни өчен кирәк? Хәзер шул сорауларга җавап табарга тырышыйк.

Хәзәрләрнең исеме тарихи язмаларда 6 нчы гасырда күренә башлый. «Хәзәрләр — барсиллар иленнән (Барсилиядән) чыккан бөек халык»,— дип әйтелә шундый язмаларның берсендә. Барсилия исә хәзерге Дагстан территориясендә, Каспий диңгезе буйларында урнашкан булган. Бу җирләрдә 4—5 нче йөзләрдә үк инде һуннар хәрәкәте вакытында килеп утырган савирлар, барсиллар, аланнар, хәзәрләр яшәгәннәр. Бу төрки кабиләләр еш кына үзара да, барысы бергә җыелып, күршеләренә каршы да сугышып торган-

нар. Төрки каганы Истәми аларны үзенә буйсындыра. Ләкин озакка түгел. Болгарлар кебек үк хәзәрләр дә үзләренең мөстәкыйльлеге өчен аяусыз көрәшәләр. Озак сугышлар нәтиҗәсендә Төрки каганлыгы көчсезләнгәч, алар үзләренең дәүләтен,— Хәзәр каганлыгын төзиләр. Ул Бөек Болгар дәүләтенә караганда да көчлерәк һәм гомерлерәк булып чыга.

Хәзәр каганлыгының беренче башкаласы Бәләнҗәр иңе унар метрга җиткән кирпеч һәм таш стеналар, ярымтүгәрәк манаралар белән әйләндереп алынган бик зур кала булган. Бераздан дәүләт чикләре киңәю сәбәпле башкаланы көньяккарак, Сәмәндәр шәһәренә күчерәләр. Тик монда да Хәзәр каганына озак утырырга туры килми.

Гаять тынычсыз заманалар була бу. Яшь Хәзәр дәүләте яңа җирләр өчен көрәштә Византия империясе һәм Гарәп хәлифәлегенең җитди көндәшенә әйләнә. Менә 737 елда да полководец Мәрван җитәкчелегендәге 120 мең кешелек гарәп гаскәре Хәзәр иленә бәреп керә һәм Сәмәндәрне камап ала.

Каган һәм аның идарәчеләре җиңелгән гаскәрләре белән, гарәпләрнең басымына чыдый алмыйча, төньякка, Дон һәм Түбән Идел буйларына качып китәләр. Бетмәс-тынмас сугышлардан тәмам туйган кабиләләр дә үзләренең каганы артыннан шушы якларга күчеп утырырга мәҗбүр булалар. Биредә алар заманында Кубрат ханның улы Батбай буйсынуында булган болгарларның җирләрен басып алалар. Болгарларның бер өлеше һәм алар белән бергә савир (суар), барсил (берсула) кабиләләре, тыныч урыннар эзләп, Идел буйлап югары күтәреләләр һәм 8 нче гасыр урталарында хәзерге Татарстан җиренә килеп чыгалар. Дон буйларында калган күпсанлы болгарлар исә Хәзәр каганлыгында яшәүләрен дәвам итәләр.

Озак елларга сузылган сугышлар нәтиҗәсендә һәлакәт чигенә килеп җиткән дәүләтне коткарып калу өчен Хәзәр каганы гарәпләр белән солых төзи. Бу солых нигезендә ул, гарәп хәлифәсе куйган таләпләргә риза булып, ислам диненә күчә. Илгә, ниһаять, тынычлык килә. Тиздән каганлык составына Кырым һәм Кара диңгез буйлары да кертелә. Зур дәүләт барлыкка килә. Аның башкаласы — бу юлы инде өченче тапкыр! — яңа урынга, Итил шәһәренә күчерелә.

Иделнең Хәзәр диңгезенә (Каспийга) коя торган җиреннән ерак түгел генә урнашкан Итил дөньяның иң зур һәм иң матур шәһәрләреннән саналган. Шәһәрнең уртасыннан ук ага торган Идел елгасының бер тармагы аны ике өлешкә бүлгән. Беренчесендә каган, бәкләр һәм башка югары катлау кешеләре яшәгән, шунда ук гаскәр тотканнар. Каган үзе өчен кирпечтән зур һәм мәһабәт сарай сал-



Хәзәр каганлыгы һәм болгарлар.
Рәсем-карта.

дырган. Сарай тирәсендә киез тирмәләр, эче-тышы балчык белән сыланган гади агач йортлар тезелеп киткән. Шәһәрнең бу өлеше дүрт капкалы биек дивар белән уратып алынган булган.

Елганың икенче ягында — сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр шәһәре. Анда мөселманнар бик күп, 10 мең кешедән артык, Җәмигъ мәчет һәм тагын утызлап мәхәллә мәчете бар, диелә тарихи язмаларда. Биредә шулай ук христианнар, яһүдләр, мәҗүсиләр дә яшәгән. Гомумән, хәзәрләрдә кем нинди дин тотарга теләгән, шуны тота алган. Дин иреге булган.

Хәзәр каганлыгы бик көчле, хуҗалыгы һәм мәдәнияте ягыннан алга киткән дәүләт булган. Таштан, кирпечтән матур сарайлар, ныгытма стеналары салганнар. Игенчелек, терлекчелек һәм һөнәрчелек өлкәсендә дә зур уңышларга ирешелгән. Шулай да хуҗалык тормышында иң әһәмиятле урынны сәүдә тоткан. Бу вакытта хәзәрләр, Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып, үз акчаларын сукканнар. Ерак илләргә

сәүдә кәрваннары җибәргәннәр, чит ил сәүдәгәрләрен кабул иткәннәр.

Әмма илдәге тыныч тормышны еш кына төрле кабиләләр һәм югары катлау кешеләре арасындагы ызгыш-талашлар бозып торган. 8 нче гасыр ахырында, Ободья исемле каган яһүд динен кабул иткәннән соң, мөселман динендәге кешеләр баш күтәргән. Дәүләтнең әле бер, әле икенче төбәгендә вакыт-вакыт кабынып торучы ызгыш-талашлар озак дәвам иткән һәм хәзәрләрнең көчсезләнүенә китергән. Бу хәлдән файдаланып, Хәзәр иленә яңа күчмә кабиләләр — бәҗәнәкләр бәреп кергән. Оешып килә торган борынгы Рус дәүләте дә хәзәрләргә каршы яу чаба башлаган.

Мондый шартларда каганлыктагы халыкларның күп өлешен тәшкил иткән болгарлар үзләренең Идел-Чулман буйларында тыныч кына яшәп ятучы туганнары янына күчеп китәргә карар кылалар. Бу күчеш 9 нчы гасыр ахырларында —10 нчы гасыр башларында була.

...Еллар артыннан еллар уза. Тарих сәхнәсендә әледән-әле телләре, диннәре һәм гореф-гадәтләре белән



Хәзәрләрнең төрле әйберләргә уеп ясаган рәсемнәре.

бер-берсеннән аерылып торган халыклар пәйда була. Бергәләп яшиләр. Сугышалар. Җиңәләр һәм җиңеләләр. Хәзәрләр белән дә шулай була. Кара диңгез буе далаларында, Түбән Идел һәм Дон буйларында 300 елдан артыграк хакимлек иткәннән соң, Хәзәр дәүләтен 965 елда рус кенәзе Святослав гаскәре җимереп ташлый. Чагыштырмача аз санлы хәзәрләр экренләп төрле якларга күчеп китәләр, таркалалар һәм башка халыклар белән кушылып бетәләр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Һуннар, Төрки каганлыгы, Бөек Болгар дәүләте һәм Хәзәр каганлыгы арасында нинди тарихи бәйләнешләр булган?
2. Хәзәрләрнең өченче башкаласы Итил шәһәрен тасвирлап сөйләгез.
3. Болгарларның Идел буйларына икенче күчеше нинди вакыйгалар белән бәйләнгән?

ИКЕНЧЕ
БҮЛЕК

БОЛГАР ҺӘМ КЫПЧАК ИЛЛӘРЕ



10. БОЛГАРЛАР ИДЕЛ ҺӘМ КАМА БУЕНДА

8 нче гасыр урталарында болгар кабиләләре без яшәгән төбәкләргә килеп җитәләр. Аларны монда нәрсә көтә соң? Бу җирләрдә элек-электән мари, мордва, удмурт, коми халыкларының борынгы бабалары яшәгән. Алардан тыш бу җирләргә борынгы заманнардан ук төрки кабиләләр килгәннәр. Алай гына түгел, болгарларның турыдан-туры бабаларының бер өлеше дә инде күптән монда яшәгән. Шулай итеп, 8 нче гасырда килгән болгарлар Идел һәм Кама буйларына таныш юллардан күчерелгәннәр.

Болгар кабиләләре килер алдыннан Урал таулары һәм Кама елгасы арасындагы бик зур төбәктә борынгы венгр-мадьяр кабиләләре берләшмәсе «Бөек Венгрия» булган. Аларның бер каберлеге Алексеевск районының Зур Тигәнәле авылы янында, Кама елгасының түбәнге өлешендә, археологлар тарафыннан казып тикшерелде.

Болгарлар белән бер үк вакытта Урал яклап Каманың югары агымыннан угор телле кабиләләр (хәзерге манси, ханты — венгрларның бабалары) үтеп керәләр. Болгарлар, алар белән килешеп, «Бөек Венгрия» кабиләләрен — венгр-мадьярларны Дон, Дунай буйларына таба куып җибәрәләр. Алар Дунай буенда Венгр корольлеге төзиләр. Венгр кабиләләренең бер өлеше безнең җирләрдә дә кала. Болгарлар һәм венгрлар күрше булып бергә яшәгән вакытта үзара аралашалар, мәдәни байлыкларын уртаклашалар. Арпа, тавык, балта кебек сүзләр бүген венгр телендә дә йөри. Ә кайбер сүзләр инде үзгәргән: борчак — венгрча: борсо, киндер — кендер, колмак — комло, батыр — батор.

Болгарлар башка күрше фин-угор халыклары (мари, мордва, удмурт, коми) белән дә дус яшиләр. Алар бу халыклардан күбрәк агач эшкәртү, урманчылык, умартачылык һөнәрләрен үзләштерәләр. Ә болгарлар үзләре бик күптәннән дәүләт һәм шәһәрләр төзү тәҗрибәсен бирәләр. Алар мәдәни яктан күпкә өстен булалар. Югарырак үскән болгар телен, йолаларын, мәдәниятен барлык кабиләләрдә дә кабул итә башлыйлар.

Болгарлар җәйләүдә. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

Болгарлар үзләре төрле кабиләләрдән тора. Бәрәнҗәрләр, эсегелләр, суарлар, барсиллар (берсуллалар). Барсиллар башка кабиләләрдән оешканрак булалар. Аларны көмеш болгарлар дип атыйлар.

Баштагы чорларда болгарларда күчмә көн итү йолалары яши. Болгар кабиләләре кышын салкыннан сакланырлык агач йортларда яшәсәләр дә, җәй көне җәйләүгә чыгып, тирмәләрдә яшәүне артык күрәләр. Шуңа күрә болгарларның Идел, Кама буйларында шәһәрләр салганчы яшәгән урыннарын табуы кыен. Әмма галимнәр аларның зур-зур каберлекләрен казып тикшерә алдылар. Аларның иң зурлары ике урында табылды. Берсе — Болгар шәһәреннән көньякта Танкеевка авылы кырыенда, икенчесе — Тәтеш районының Олы Тархан авылы янында.

Шул борынгы вакытларда ук болгарлар югары рухи мәдәниятка ия булалар. Аларның гасырлар аша безгә килеп җиткән риваятьләре, хикәяләре күп вакыйгалар турында сөйлиләр. Шуларның берсендә сүз аларның Идел, Кама буйларына килеп урнашулары хакында бара.

Нух пәйгамбәрнең өч улы булган. Гази, Төрек һәм Алып. Матур гына көн иткәндә алар, шайтан коткысына бирелеп, үзара сугыша

башлыйлар. Шуннан соң бу туганнар инде бергә яши алмыйлар. Алып батыр зат була. Ул эшкә тотынса, кечерәк тауларны ишә һәм бер кулы белән атларны яки сыерларны күтәрә ала. Алып йөргәндә чабатасына тулган балчыкны кагып төшерсә, түгәрәк калкулыклар барлыкка килә. Караңгы урманнар, сазлыклар аша үтеп, Алып бер зур елга буена килеп чыга һәм бу җирләрне ошатып шунда яшәп кала. Андагы үз телен аңлаучы кешеләр белән яши башлый. Алып, алар арасыннан сайлап алып, бер кызга өйләнә. Аларның ике уллары туа. Аларның берсенә Болгар, икенчесенә Буртас исеме кушалар. Алар үсеп җиткәч, икесе ике җирдә, үзләренең исемнәре белән атап, шәһәрләр төзиләр. Бу шәһәрләрнең халыклары тиз ишәя. Аларның даны еракларга тарала. Шулай итеп, Идел буенда болгар халкы оеша.

Безнең болгар бабаларыбыз мондый риваять, хикәят, әкият, мәкаль, табышмакларны күп белгәннәр. Кышкы озын кичләрдә әби-бабайлар аларны сабый балаларга сөйләгәннәр. Аларны дус, батыр, бердәм булырга өйрәткәннәр. Көндез әкият сөйләгән кешене Ак бүре ашар, дигәннәр. Көндез әкият сөйләп утырганны Ак бүре бер дә яратмаган. Чөнки көндез тырышып эшләргә, сабан сөрергә, урак урырга, ауга барырга, илне сакларга кирәк булган.

Борынгы бабаларыбызның тормышы җиңел булмаган. Алар үзләрен күзгә күренми торган яхшы һәм яман көчләр уратып алган дип ышанганнар. Алардан сакланырга, йә корбан биреп күңелләрен күрергә кирәк булган. Башта алар һәр күренеш белән аерым бер алла идарә итә дип уйлаганнар: тормыш алласы үзе бер, үлем алласы башка, төн алласы, көн алласы, җәй алласы, кыш алласы бар. Болгарлар җиргә җылылык, яктылык, тормыш бирүче кояшны хөрмәт иткәннәр, аңа табынганнар. Иртән, таңнан торып, аның беренче нурларына баш игәннәр. Кояш сурәте болгарларның бик күп көнкүреш әйберләренә, хәтта кабер ташларына да төшерелгән.

Болгар кабиләләре дәүләт төсендә бергә оешкан заманнарда күп аллалык бетә. Борынгы болгарлар Алланы Тәңре дип йөрткәннәр. Болгарлар уйлавынча, яшен яшенләү, күк күкрәү һавада сугышучы атлы җеннәр белән аларны куып йөргән Тәңре хәрәкәтеннен килеп чыга. Тәңре җеннәргә камчы белән сукканда яшен яшенләгән, күк күкрәгән.

Җир шарының, кояш, ай, йолдызларның барлыкка килүе хакында да болгарлар төрлечә фикер йөрткәннәр. Имеш, борынборын заманда бөтен дөнья судан гына торган. Анда бер ялгызак алтын үрдәк йөзеп йөргән. Көннәрдән бер көнне ул бер алтын йомырка салган — Җир барлыкка

килгән, икенчесен салган — Кояш балкыган, өченчесен салган — Ай яралган.

Икенче хикәяттә ул башкачарак сөйләнелә. Имеш, шул ук үрдәк бер көнне су төбеннән бер кабым балчык алып чыккан, шуннан коры җирләр, таулар-далалар барлыкка килгән.



Дөньяның барлыкка килүе хакында сөйләүче алтын алкалар.

Болгар бабаларыбызның ел әйләнәсендә күп кенә бәйрәмнәре булган. Алар бөтен ыруг, кабилә белән язны, яз хәбәрчесе кара каргалар килүен каршылап «карга боткасы» бәйрәме үткәргәннәр. Ел яздан башланган. Яңа ел бәйрәмен ул вакытта «Нәүрүз» дип йөрткәннәр. Җәй көннәрендә Сабантуйда төрле ярышлар уздырганнар. Ыруглар, кабиләләр бергә җыелып, гомум тормыш-көнкүреш эшләрен хәл иткәннәр, туганлашканнар, күңел ачканнар. Бу иң зур бәйрәм җыен дип аталган.

Менә шулай яшәгәннәр безнең борынгы бабаларыбыз.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Болгарлар килгәнче Идел, Кама буйларында нинди кабиләләр яши?
2. Гази, Төрек һәм Алып турында риваять кайсы яклары белән болгарлар тарихын хәтерләтә?
3. Болгар бәйрәмнәренең кайсыларын без бүген дә яратып бәйрәм итәбез?
4. Үзегез күргән Сабантуй бәйрәме турында хикәя язып килегез.

11. БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

9 нчы гасырда болгар кабиләләрендә ыруглык җәмгыятенә хас күмәк эшләү, күмәк яшәү мөнәсәбәтләре таркала башлый. Ярым күчмә тормыш белән яшәгән болгар кабиләләре ныклы утрак тормышка күчә баралар. Беренче авыллар, шәһәрләр барлыкка килә. Игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек үсә. Шулар нәтиҗәсендә барлыкка килгән байлык аерым кабилә башлыклары кулында туплана башлый. Кабиләләр юлбашчылык итү өчен көрәшәләр. Дошман килгәндә генә берләшәләр. Халкыбызның борынгы мәкалендә, күрәсең, шул чорларны хәтердә тотып болай дип әйтелә:

Кайсы ыру көчле — ханны шул куя;
Кайсы ыру үчле — канны шул коя.

Кавказ якларында, Кара диңгез буйларында Бөек Болгар дәүләте һәм зур-зур шәһәрләр төзү тәҗрибәсенә ия булган болгар кабиләләре арада көчлерәк булып чыга. Алар тирәсенә башка кабиләләр дә туплана, аларга буйсына. Ханны, патшаны да болгар кабиләләре куя. Шулай итеп, 9 нчы гасырның икенче яртысында Идел буенда беренче бабаларыбыз — болгарлар дәүләте барлыкка килә. Алар үзләре бу дәүләтне яратып Болгар иле, Болгар йорты яки тагын да кыскарак итеп Болгар дип кенә йөрткәннәр. «Болгар» сүзе илне дә, анда яшәгән халыкны да, илнең башкаласын да аңлаткан.

Болгар дәүләтенең башында патша (әмир) торган. Аның көчле батыр егетләрдән торган ук-җәя, сөнге, кылыч белән коралланган гаскәре булган. Чит кабиләләргә, алар ерак җирләргә яуга чыкканнар. Аннан алып кайткан байлыктан патшага да өлеш чыгарганнар. Дошманнар килсә, бергәләп каршы торганнар.

Төп, баш патшага (әмиргә) вак патшалар (бәкләр) буйсынган. Алар Болгар иленең аерым өлкәләре белән идарә иткәннәр. Вак патшаларга кабилә башлыклары (рәисләр) баш иеп торган. Аларның барысына гади, ирекле халык, һәм сәүдәгәрләр буйсынган. Игенче үзе өчен уңыш үстергән. Патшаның анда өлеше булмаган. Әмма илдәге халыклар патша өчен йорт башыннан кыйммәтле берәр кеш тиресе җыйганнар. Кем дә кем туй үткәрсә яки кунак чакырса, бу мәҗлестән дә патшага өлеш чыккан. Күрше мөселман булмаган халыклар кеше башыннан һәм биләгән җиренә карап ясак түләгән. Хәрби ныгытмалар төзегән.

Болгар иле баштагы чорларда Хәзәр каганлыгына бәйлелектә яши. Болгар илен буйсындырып тоту өчен каган патша улын тоткынлыкка алып китә. Явыз каганга бу гына җитми. Ул, болгар патшасы кызының матурлыгын ишетеп, аны хатынлыкка сорый. Болгар патшасы икенче диндәге (яһүд дине) карт кешегә кызын бирергә теләми. Шуннан соң каган, Болгар иленә гаскәр белән килеп, көч белән патша кызын алып китә. Кайгысына түзә алмыйча, патша кызы чит җирдә үлә. Оятсыз каган патшаның инде икенче кече кызын таләп итә. Болгар патшасы Алмыш бу хурлыкны буйсынудан котылу юлларын эзли. Каган таләп иткәнче кызларын үзенә буйсынган яхшы кешеләргә кияүгә бирергә ашыга. Патша яһүд динендәге хәзәрләргә каршы тору максаты белән ислам дине үзәге булган Багдад хәлифәлегеннән шәһәр-кальга салу өчен акча, төзүчеләр сорый. Озакламый, бер сугышта болгарлар



Идел Болгарстаны һәм аның төп шәһәрләре. *Карта.*

хәзәрләрне җиңәләр һәм тәмам азатлыкка ирешәләр.

Бу вакыйгалар халкыбыз хәтерендә нык уелып калган. Риваятьләрдә борынгы Хәзәр каганлыгын Аждаһа иле дип атаганнар. Сезнең шундый әкиятләр укыганыгыз бардыр. Зур суда аждаһа яши. Ел да ул үзенә корбанга бер патша кызын сорый...

Болгар иле ныгыган саен аның биләмәләре дә арта бара. Ул бик зурая. Аның чикләре көньякта Самара тугаена, Жигули тауларына, көнбатышта — Сура, төньякта — Мишә, Казан елгаларына, көнчыгышта — Агыйдел елгасын үтеп Урал тауларына кадәр барып җитә. Көньяк-көнбатышта ул Ока елгасына кадәр сузылган. Пермь өлкәсендә дә болгарлар яшәгән җирләр күп. Хәзәр каганлыгы тармар ителгәч, бөтен Идел юлы болгарлар карамагына күчә. Элек Хәзәр диңгезе дип аталган Каспий Болгар диңгезе дип йөртелә башлый. Димәк, хәзерге картага карасак, элекке Болгар иле биләмәләренә хәзерге Татарстан, Чувашия Мари-эль, Удмуртия республикалары, Башкортостанның көнбатыш, Мордовиянең көнчыгыш төбәкләре, Самара, Ульяновск, Пенза, Саратов, Волгоград, Астрахань, Түбән Новгород, Пермь өлкәләренең шактый зур төбәкләре кергән. Аның төп өлеше безнең Татарстан республикасына туры килә.

Болгар иленә күрше төбәкләрдә дә күпчелеге болгарларга кардәш булган төрки кабиләләр яшәгән. Аларны көнчыгыштан көнбатышка таба ямәкләр (кыпчаклар), гузлар һәм бәҗәнәкләр, мадьярлар һәм башкортлар, буртаслар, фин телле кабиләләр уратып алган. Сура, Идел, Ока елгалары арасында мордвалар яшәгән. Иделнең сул ягында Нократ (Вятка) елгасына кадәр борынгы мари кабиләләре гомер кичергәннәр. Аннан да төньяк-көнчыгыштарак удмурт кабиләләренең җире башланган. Болгардан ерак төньяк җирләрне «Вису», «Югра» илләре, Чулман җирләре дип атаганнар.

Шулай итеп, Көнчыгыш Европаның беренче дәүләтләреннән берсе Болгар иле барлыкка килә. Озак та үтми, аның даны еракларга тарала.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен болгарлар бер дәүләт булып берләшәләр?
2. Болгар дәүләтенең барлыкка килүенең әһәмияте нәрсәдә?
3. «Тарихи сүзлеккә» «әмир», «бәк», «Багдад хәлифәлеге» дигән сүзләрне аңлатып языгыз.
4. Картадан Болгар иленең чикләрен билгеләгез.

12. СУГЫШНЫ ТУКТАТКАН КҮН ИТЕКЛӘР

Болгар иленең хуҗалыгы үз чоры өчен зур үсеш дәрәҗәсенә ирешә. Кара туфраклы уңдырышлы басуларда күкрәп ашлык үскән. 10 нчы гасыр сәяхәтчесе Ибн Рустә: «Болгарлар игенчелек белән шөгыльләнүче халык, һәм алар һәртөрле бөртекле ашлык: бодай, арпа, тары һәм башкаларны игәләр»,— дип язып калдырган. Игенне уңайлы итеп эшләнгән урак, чалгы белән җыеп алганнар. Ашлыкны башаклы килеш амбарларда, ә тиз арада куллану өчен дым үтмәслек итеп эшләнгән түгәрәк баз сыман чокырларда яисә зур чүлмәкләрдә саклаганнар. Һәр өйдә кул тегермәне булган. Мондый ярма ясагыч кечкенә тегермәннәр безнең авылларда хәзер дә очрый әле. Зур тегермән ташлары атлар көче белән әйләндерелгән. Бөртек ике ташлы тегермәндә әйбәт тартылган, таш кыриеннан җылы он агып торган.

Болгар иленә сәяхәт итүче Ибн Фадлан: «Аларның ризыгы — тары белән ат ите, ләкин бодай белән арпа да бик күп»,— дип яза.

Ашлык нык уңган. Ул чит илләргә сату өчен дә җиткән. Күршедәге Борынгы Рус җирендә ашлык уңмаган еллар еш булган. Рус елъязмачылары мондый елларда болгарларның ярдәмгә килүләре хакында язалар. Алар ашлык алып киләләр, русларны ачлыктан коткарып калалар.



Кораллы сугышчылар. *Т. Абдуллин рәсеме.*

Мул үләнле болыннарда, көтүлекләрдә маллар утлап йөргән. Алар ат, сыер, сарык, кәҗә кебек хайваннар асраганнар. Болгарларның мал-туары да башка тирә-юнь халыкларыныкыннан эре булулары белән аерылып торган. Алар беркайчан да дуңгыз асрамаганнар. Ерак көньяк илләреннән монда дөяләр белән кәрваннар килгән.

Терлекчелек һөнәрчеләр өчен, аерым алганда тире, сөяк эшкәртүчеләр, киез басучылар өчен чимал биргән. Болгар осталары хайван сөякләреннән нәрсә генә эшләмәгәннәр. Алар тараклар, тырнап язу өчен каләмнәр, сәдәф-төймәләр, каптыргычлар, йөзекләр, эш, ау һәм сугыш кораллары, шашка, шахмат сыннары һәм тагын бик күп нәрсәләр ясаганнар.

Болгар җирләре үтеп чыга алмаслык кара урманнарга, балыклы елга-күлләргә бай булган. Бу аучылык, балыкчылык һәм умартачылык өчен зур мөмкинлекләр тудырган. Кеш, сусар, кама, көндыз, тиен, ак, кара, кызыл төлке һәм куян тиреләрен Урта Азиядә, Гарәбстанда, Иранда болгар сәүдәгәрләреннән бик теләп сатып алганнар. Кыйммәтле тиреле җәнлекләрне аулаганда тиреләрен бозмас өчен махсус сөяк уклар кулланганнар.

Испаниядән 12 нче гасырда Болгар иленә килгән сәяхәтче Әл-Гарнати мондагы елгалардагы балыклар-



Чәчәк рәвешле яктырткыч.

ның эрелегенә, төрлелегенә, итләренең тәмлелегенә таң калып яза.

Урмандагы агач куышларыннан, үзләре ясаган умарталардан җыйган бал болгарлар өчен тәмле ризык кына түгел, шифалы дәва да булган. «Аларның урманнарындагы корт ояларында бал бик күп, алар аның кайда икәнен яхшы беләләр һәм бал җыярга йөриләр»,— дип яза болгарларда кунак булган Ибн Фадлан. Югарыда телгә алынган сәяхәтче Әл-Гарнати: «Болгар кешеләре салкынга түземле халык, чөнки аларның ризык һәм эчемлекләренең күп өлеше балдан хасил, бал аларда очсыз»,— дип өсти.

Болгар шәһәрләре остаханәләрендә һәрчак эш гөрләп торган. Һөнәрчеләр бистәләре шәһәрләрдә зур-зур мәйданнарны биләгәннәр. Алар эшләрне бүленешеп эшләгәннәр. Нинди металл белән һәм нинди әйбер ясауларына карап аерылганнар. Алтынчылар, көмешчеләр, бакырчылар, йөзекчеләр, коралчылар, төрәнчеләр һ. б. булган. Мондый бүленеш әйберләрне сыйфатлы итеп ясау мөмкинлеге биргән.

Нинди һөнәрләр Болгар илендә аеруча үскән соң?

Күп нәрсәне эшләү өчен тимер кирәк булган. Алар аның рудасын (мәгъдәнен) Урал тауларыннан алып кайтканнар. Тимерле мәгъдән якын-тирәдәге сазлыклы, күлле урыннарда да булган. Өстә ятканлыктан аларны җиңел тапканнар. Тимерчелек бик әһәмиятле һөнәр булганга күрә, аның зур-зур остаханәләре ил башкаласының нәкъ үзәгендә, патша сараеннан ерак түгел җирдә урнашканнар. Калын стеналы савытлар-

Болгар савыт-сабалары.

да тимерне эретеп сугыш кораллары эшләү өчен корыч койганнар. Болгар тимерчеләре эшләгән балта, урак, чалгы, кылыч, сөңге, ук, чукмар кебек кораллар югары сыйфатлы булган.

Бакыр һәм аның катнашмаларыннан төрле савыт-саба: тәлинкә, касә, җиз таслар, комганнар ясаганнар. Бакыр әйберләргә матур рәсемнәр, бизәкләр төшергәннәр.

Алтынчылар, көмешчеләр кыйммәтле ташлар катнаштырып бик матур бизәнү әйберләре эшләгәннәр. Алар ясаган рәсем-сурәтләрдә, сыннарда бабаларыбызның инанулары, риваятьләре, дөньяга карашлары чагылган. Чибәрлекләре ерак фарсы, гарәп шигырьләрендә тасвирланган болгар кызлары зәвык белән бизәнә дә белгәннәр. Иң нәфис эшләнгән бизәнү әйберләрен көнчыгыш (шәрык) илләрендә «болгари» дип йөрткәннәр. Ул Болгарныкы, Болгар илендә эшләнгән дигәнне аңлаткан.

Болгарлар үзле кызыл балчыктан әвәләп, яндырып нәрсә генә эшләмәгәннәр. Су һәм кайнар һава үткәргечләр, шәмдәлләр, кәндилләр, уенчыклар һәм, билгеле инде, төрледән-төрле савыт-сабалар: иген ашлыгы яки май, эчемлек саклау өчен Борынгы Греция амфораларына охшаган зур-зур савытлар, муенлы һәм яссы чүлмәкләр, чынаяклар, җамаяклар, тустаганнар, тәлинкәләр...

Бу савытлар төсе һәм рәвешләре белән зифа буйлы, бер бите ай, бер бите кояш итеп сурәтләнгән болгар кызларына охшаган. Моннан тыш чүлмәкчеләр аларга хатын-кызларның бизәнү әйберләренә охшашлы бизәкләр дә төшергәннәр.

Чүлмәк ясау үзе бер могҗиза булган. Әйләнеп торучы түгәрәк тактага салынган үзле балчыктан оста кулы тию белән хәйран калырлык әйберләр пәйда булган. Могҗиза күрергә дип, анда балачага җыелган. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, алар да балчыктан төрле уенчыклар, кеше, хайван сыннары, сыбызгылар, «тәтиләр» ясаганнар.

Болгар чүлмәкчеләренең даны еракларга таралган. Русларның үз чүлмәкчеләре булса да, алар болгар осталарының балчык савыт-сабаларын өстен күргәннәр. Шуңа күрә археологлар аларны күп кенә борынгы рус шәһәрләрен казып тикшергәндә табалар.

Болгар күнчеләренең, тире эшкәртүчеләренең әйберләрен тирәюньдә генә түгел, бөтен Европа, Азиядә дә теләп сатып алганнар. Осталык белән нәфис эшкәртелгән хуш исле, кызыл сафьян тиреләрне барча җирдә «болгари», ягъни Болгарныкы дип йөрткәннәр. Күннән, тиредән итек, читек, каеш, ерак юлларга чыкканда су, эчемлек салу өчен турсык, биштәр, дошман угыннан саклану өчен көбә күлмәк теккәннәр. Илнең башкаласы Болгар-Биләрдә генә дә тире эшкәртә торган 700 ләп остаханә булган.

985 елда бер вакыйга була. Руслар Болгар иленә яу белән киләләр. Сугыш барышында болгарлар җиңелә башлый. Күп кенә болгар сугышчылары әсирлеккә төшә. Әмма сугышның язмышын үзгәртерлек шундый хәл була. Руслар болгар сугышчыларының һәрберсендә яхшы күннән тегелгән итекләр күреп таң калалар. Аларның аякларында чабата гына була. Гаскәр башлыгы шунда сугышны туктатырга, болгар әсирләрен иреккә җибәрергә әмер бирә. «Бөтен гаскәренә күн итек киендергән халыктан ясак түләтеп булмас, әйдәгез, үзебезгә тиң чабаталыларны эзлик»,— ди ул. Шуннан соң үзара сугышмаска дип солых төзиләр.

Чыннан да, болгар итекләре болгарларны җиңелүдән коткара, аларның һөнәрчелек данын тагын да арттыра.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Болгарларда нинди һөнәрчелекләр аеруча алга киткән булган?
2. «985 елда болгар-рус сугышында күн итекләр җиңә», дигән җөмләне сез ничек аңлыйсыз?
3. Сез нинди һөнәрләр беләсез? Болгарлар белгәнме ул һөнәрне? Бу турыда инша язып килегез.

13. БИЛӘР — ОЛУГ ШӘҺӘР

Республикабызның Алексеевск районы Биләр авылы янында, халкыбыз телендә «ямьле Чирмешән буйлары» дип йөртелә торган искиткеч бай табигатьле төбәкләрнең берсендә, болгар бабаларыбыздан калган бик зур шәһәр хәрабәләре ята.

Балчыктан өелгән биек үрләр, тирән чокырлар — хәрби ныгытма эзләре — яшел чирәм белән капланган. Тигез басу өстендә чүлмәк китекләре, хайван сөякләре аунап ята, әллә нинди сәер табылдыклар очрый. Күптән җимерелеп беткән йорт һәм каралты-кура урыннарында кирпеч ватыклары, балчык катыш көл-күмер өемнәре. Күренеп тора, кайчандыр тормыш гөрләп торган биредә. Бу шәһәрнең даны бөтен дөньяга таралган булган. Борынгы рус елъязмаларында гарәп сәяхәтчеләре калдырган истәлекләрдә, халкыбызның риваять-легендаларында Биләр турында кызыклы хәбәрләр сакланып калган. Олуг шәһәр дип йөрткәннәр аны заманында!

Ниндирәк булган соң ул Олуг шәһәр? Бу сорауга җавап табу өчен археологлар эшкә керешә. Әмма ләкин мәйданы мең гектарга якын булган шәһәрне ничек тиз генә казып бетерәсең ди? Озак баш ватканнан соң, алар, борынгы шәһәр серләрен ачу өчен... самолетка утырып, күккә күтәрелеп карарга булалар. Әйе, нәкъ менә югарыдан уч төбендәге кебек ачык күренә икән ул борынгы кала! Нинди дулкынландыргыч күренеш! Әнә, ничәмә-ничә чакрымнарга сузылып киткән шәһәр ныгытмалары. Тикмәгә генә дөньяның иң зур шәһәрләре рәтендә йөрмәгән икән ул Биләр! Мәйданы ягыннан аңа тиң шәһәрләр Европада бөтенләй булмаган әле. Борынгы Русның Киев, Чернигов, Владимирлары, Европаның Париж, Лондоннары, Азиянең Дәмәшкъ, Иерусалим шәһәрләре Биләрдән күпкә кечерәк булганнар. 15—16 нчы гасырларда да әле 20—30 мең кеше яшәгән шәһәрләр бик зур дип саналган. Ә Биләрдә 12—13 нче гасырларда ук инде 70—100 меңләп кеше яшәгән.

Әнә эчке шәһәр. Ике катлы куәтле ныгытмалар белән уратып алынган. Үзәктә — зур гына кирпеч бина калдыклары. Патша сарае булгандыр, күрәсең. Менә монысы тышкы шәһәр һәм аның өч рәт ныгытмалары. Кайчандыр агачтан һәм таш-кирпечтән салынган йортларның хәрабәләре, урам эзләре, зират урыннары...

Самолет бер югары күтәрелә, бер түбән төшә. Аңа урнаштырылган махсус приборлар бар күргәнне җентекләп фотога төшереп баралар. Менә шулай, археолог көрәге әле җиргә тигәнче дигәндәй, галимнәр, самолеттан төшерелгән сурәтләргә карап та, Биләр ту-



Биләрдәге иң борынгы Җәмигъ мәчет.

рында күп кенә яңа нәрсәләр белә алдылар. Археологлар эшкә тотынгач, тагын ачыш артыннан ачышлар китте.

...Эчке шәһәр. Төп казу эшләре шунда алып барыла. Бу аңлашыла да. Биредә Болгар патшасы һәм аның якын туганнары, дәүләт белән идарә итүдә катнашучы кешеләр, дин башлыклары, бай сәүдәгәрләр һәм аларның хезмәтчеләре яшәгән. Шуңа күрә таштан, кирпечтән салынган матур биналар күп булган монда.

Менә Татарстан җирендә иң борынгы мәчетнең хәрабәләре. Патша сараена якын гына урнашкан бу таш мәчетнең биек манарасы әле 18 нче гасырда да ерактан ук күренеп торган. Аннан соң ул җимерелеп төшкән, ташларын җирле крестьяннар ташып бетергән. Археологлар бу изге хәрабәләрне яңадан казып «яңартты»лар. Заманында ике өлештән торган мәһабәт зур мәчет булган икән ул. Аны үзәк, төп мәчет булганга Җәмигъ мәчет дип атаганнар. Аның борынгырак өлеше 10 нчы гасыр башларында агачтан салынган. Бераздан, шуңа кушып, таштан тагын бер бина торгызганнар. Гомуми мәйданы 2300 квадрат метрлы бик зур мәчет барлыкка килгән. Аның бер як стенасы тыштан матур итеп ярымколонналар белән бизәлгән. Таш мәчетнең иркен, киң залы рәт-рәт колонналар белән биш өлешкә бүленгән.

Мәчет янәшәсендә ике катлы гөмбәз түбәле кирпеч өй җиткереп куйганнар. Монда нindидер бай кеше, ә бәлки, мәчетнең дин әһеледер, үзенең гаиләсе белән яшәгән. Йортның ике катында дүртәр бүлмә булган. Алар барысы да бер мичтән торбалар аша кайнар һава белән җылытылган. Йортның ишегалдында амбар-келәтләр, төрле хуҗалык корылмалары тезелеп киткән.

Җәмигъ мәчетнең икенче ягында югары катлау кешеләре күмелгән зират бар. Үлгән кешеләрне мө-



Борынгы Болгар-Биләрне археологлар менә шулайрак күз алдына китерәләр.

селман йоласы белән башларын көньяк-көнбатышка, изге Мәккә ягына каратып җирләгәннәр. Болгар патшаларының гәүдәсе агач табутлар эчендә кирпеч төрбәләрдә (мавзолейларда) ята.

Тышкы шәһәрдә күбесенчә һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр яшәгән. Аларның өйләре бүрәнәләрдән салынган. Элегрәк киез тирмәләрдә дә торганнар. Шәһәрнең бу районында һөнәрчеләрнең остаханәләре урнашкан. Биләр елгасы буенда чүлмәкчеләр торган. Биредә чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелде. Металл коючылар, тимерчеләр, сугыш кораллары һәм бизәнү әйберләре ясаучылар, тире иләүчеләр, пыялачылар, ташчылар һәм башка төр һөнәр ияләре җитештергән әйберләр казу эшләре вакытында күпләп табыла.

Ерак илләрдән килгән сәүдәгәрләргә яшәү өчен эчке шәһәргә керә торган капка янында (ул вакытларда аны «Алтын капка» дип йөрткәннәр булса кирәк) махсус урын бүлеп бирелгән. Ул кәрвансарай дип аталган. Чит сәүдәгәрләр эчке шәһәргә бары тик көндезләрен генә кереп йөри алганнар. Кояш батканда аларны куып

чыгарып (шымчы булып йөрмәсеннәр, янәсе), чокыр аркылы салынган күперләрне күтәртеп, шәһәр капкаларын бикләп куйганнар. Кәрван-сарайда аларның кунакханәләре булган. Кирпечтән зур гына мунча да салганнар. Аны җылыту өчен ишегалды ягыннан ягыла торган миче булган. Кайнар һава идән астыннан каналлар буйлап йөргән. Күрәсезме, ничек оста итеп төзи белгәннәр болгар бабаларыбыз!

Өч гасырдан артыграк чәчәк атып яшәгәннән соң, 1236 елның көзендә, шәһри Биләр монгол илбасарлары тарафыннан җимертелә һәм бүтән торгызылмый. Хәзер биредә рус авылы урнашкан.

Шәһәрнең ул вакытлардагы чын исеме — Болгар. Гади халык аны күбрәк Биләр дип йөрткән. Биләр сүзе «байлар, бөекләр шәһәре» дигән төшенчәне (би — затлы кеше, бай кеше мәгънәсендә) аңлаткан. Руслар аны дөрестән дә Олуг шәһәр (Великий город) дип атаганнар.

Болгар-Биләр шәһәре — безнең беренче башкалабыз. Аның тарихы безнең өчен бик якын һәм кадерле. Галимнәр аны җентекләп өйрәнергә тырышалар. Әкренләп археологлар да борынгы шәһәрнең серләренә төшенә баралар. Ачылмаган серләр дә күп әле. Биредә ел саен җәй көне археологик экспедиция эшли. Казу эшләрендә мәктәп укучылары да катнашалар. Табылган әйберләр музейда саклана.

Булганыгыз бармы сезнең Биләрдә? Барып карап кайтыгыз изге урыннарны, күңелегездә гомергә онытылмаслык матур хатирәләр калыр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Биләр шәһәре кайда урнашкан? Ни өчен аның тарихы безнең өчен бик кадерле?
2. Борынгы шәһәрне сез ничек итеп күз алдына китерәсез? Рәсемнәргә карап сөйләгез.
3. Эчке шәһәрдә һәм тышкы шәһәрдә кемнәр яшәгән?
4. Шәһәрнең чын исеме ничек? Биләр сүзе нәрсәне аңлата?

14. МӘШҺҮР БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Болгар иленә килгән сәяхәтчеләр мондагы зур һәм матур шәһәрләрнең күплегенә хәйран кала торган булганнар. Болгар дәүләтенең төрле төбәкләренә таралып утырган шәһәрлекләрнең саны 180 гә җитә. Дөрес, аларның барысын да чын шәһәр калдыклары дип әйтеп булмый. Алар арасында мәйданы 2—3 гектардан артмаган хәрби ныгытмалар — крепостьлар (кальгалар), бай җир биләүче фео-

даллар яшәгән замоклар да күп. Чын шәһәр — ул территориясе көчле ныгытмалар белән әйләндереп алынган, ә халкы күбесенчә һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнә торган эре торак урыны. Аларның мәйданы берничә дистә, кайбер чакта хәтта йөзәр гектарга җиткән. Шәһәр үзәгендә (калада) гадәттә дәүләт идарәсе, югары катлау кешеләре, бай сәүдәгәрләр яшәгән. Шунда ук шаулап торган базарлар, якын-тирәдә мәчет-мәдрәсәләр урнашкан. Һөнәрчелек остаханәләре исә, үзләре бер бистә булып, шәһәр читендәрәк тупланганнар.

Болгар шәһәрләре моннан 1000 ел элегрәк, 10—11 нче гасырларда барлыкка киләләр. Аларның үсү һәм чәчәк ату чоры 12 нче гасырга һәм 13 нче гасыр башларына туры килә. Хәзер инде күбесенең чын исемнәрен дә белмибез. Кайбер тарихи язмаларда һәм халкыбыз хәтерендә генә саклан калган шәһәр исемнәре дә бар. Онытмагыз аларны: Болгар, Биләр, Суар, Ашлы, Җүкәтау, Кашан, Тубылгытау.

Суар — Болгар илендә иң эре шәһәрләрнең берсе. 10 нчы гасырда ул хәтта Болгар (Биләр) шәһәре белән дә ярышып яшәгән. Суар әмире Болгар патшасына җиңел генә буйсынырга теләмәгән. Суар әмирләре Талип ибн Әхмәт һәм Мөэмин ибн Әхмәт, үз биләмәләренең мөстәкыйльлеген күрсәтергә теләп, көмеш акчалар да сукканнар. 10 нчы йөздә Әл-Бәлхи исемле гарәп галиме болай дип язып калдырган: «Болгардан (Биләрдән) ерак түгел икенче бер шәһәр — Суар урнашкан. Биредә дә Җәмигъ мәчет бар. Мөселман диненә өндәүче, ике шәһәрнең дә халкы 10 меңгә җитә, дип әйтте. Йортлары агачтан салынган һәм аларда кышын торалар, җәен исә киез тирмәләргә таралалар».

Суар хәрабәләре республикабызның Спас районы Кузнечиха авылыннан 4 чакрым еракта Утка елгасы буенда урнашкан. Шәһәрлекнең бер почмагына сыенып утырган кечкенә генә Татарский Городок исемле авылны җирле халык әле дә Шәмсуар дип атый. «Матурлыгы кояшка тиң, кояш кебек нурлы Суар» дигәнне аңлата ул.

Суарның куәтле шәһәр ныгытмалары 100 гектар чамасы җирне биләгән. Кайбер урыннарда бу ныгытмалар икешәр рәтле итеп салынган. Алардан хәзер 5 чакрымга сузылган биек җир үрләре һәм тирән чокырлар гына сакланып калган. Ул вакытларда исә тышкы үрләр өстендә очлы башларын югары каратып һәм бер-берсенә терәп утыртылган имән баганалардан стена торган. Дошман гаскәре, бу стеналарны ватып-җимереп, эчке үтә калса, шәһәрне бөтен яктан уратып алган сулы тирән чокырга килеп чыккан. Аның төбеннән очлы казыклар тырпаеп торган. Эчке үрләр өстенә имән бү-

4 Ч-279

рәнәләрдән бурап эшләнгән ике катлы стеналар һәм билгеле бер ара калдырып күтәртелгән биек манаралар — башнялар төзелгән. Бу манаралардан шәһәр сакчылары якынлашып килүче дошман өстенә ук һәм сөңге яудырганнар, чүлмәкләргә салып, яндыргыч матдәләр атканнар...

Шәһәрнең үзәгендә матурлыгы белән еректан ук игътибарны җәлеп итәрлек ике катлы йорт калкып тора. Ул кызыл кирпечтән салынган. Түбәсе, нәкъ шәрык илләрендәгечә, гөмбәзләп эшләнгән. Киң ишегалды кирпеч койма белән әйләндереп алынган. Өйнең зур ишеге ике яклап ярымколонналар белән бизәлгән. Тәрәзәләрдә саргылт-яшел төстәге түгәрәк пыялалар. Кыш көне бина бер генә мичтән ягып җылытылган. Эссе һава йөри торган махсус каналлар, Биләр мунчасындагы кебек үк, идән астына урнаштырылганнар.

Бу йортта, һичшиксез, бай феодалның гаиләсе торган. Казу эшләре вакытында биредә чит илләрдән кайтарылган кыйммәтле савыт-саба һәм бизәнү әйберләре табылды. Мондый әйберләр, билгеле, гади кешеләрдә булмаган.

Шәһәрнең башка районнарында бер катлы гади агач йортларда һәнәрчеләр яшәгәннәр. Сәүдәгәрләр шәһәр үзәгенә якын урнашкан базар тирәсендә тупланып яшәргә тырышканнар.

Суар шәһәре, Биләр кебек үк, монгол яулары вакытында вәхшиләрчә җимертелеп, җир йөзеннән мәңгегә юкка чыга. Ә исеме беркайчан да онытылмаячак!

Ашлы (Ошель) да болгарларның иң атаклы шәһәрләреннән саналган. Аның калдыклары Иделнең уң ягында Тәтеш районының Богдашкино авылы янында саклана. Шәһәр балчык үрләр һәм агач стеналар белән ныгытылган ике өлештән торган. Аның гомуми мәйданы 77 гектар чамасы. Археологик казу эшләре әле күптән түгел генә башланды, шуңа күрә борынгы шәһәрне күз алдына китерү хәзергә кыен. Ашлыны 1220 елда рус гаскәрләре басып алалар һәм яндыралар. Моны ишетеп Ашлыга Олуг шәһәрдән (Болгар-Биләрдән) зур гына болгар гаскәре килә, тик ярдәм итәргә соң була инде.

Җүкәтау шәһәре чал дулкыннарын тибрәтеп салмак кына агып ята торган ямьле Чулман-Кама буенда урнашкан. Аның хәрабәләре Чистайдан 3—4 чакрым көнбатыштарак, Крутая Гора авылы янында ук. Җүкәтауның өч рәт үрләр — чокырлар белән ныгытылган үзәк өлеше (каласы) биек тау башында, Киле елгасының Камага кушылган урынында. Текә тау бите һәм кыр ягындагы көчле ныгытмалар шәһәрне дошманнардан саклаган. Калада бай феодаллар һәм аларның ялчы-йомышчылары яшәгән. Алар өчен махсус мәчет салдырып куйганнар.

Калага каршы якта, Киле суы аша чыккач, иркен тигез мәйданда Җүкәтауның һөнәрчелек бистәсе урнашкан. Хәзер дә биредә метал коючылар һәм чүлмәкчеләр эшләгән урыннар ачык күренеп тора.

Җүкәтау Түбән Кама төбәгендә яшәгән болгарларның үзәк шәһәре булган. 13—14 нче гасырларда, монгол яуларыннан соң, ул мөстәкыйль кенәзлекнең башкаласына әйләнә.

Тубылгытау — исемнәре татар халык риваятьләрендә сакланган болгар шәһәрләре арасында иң кечкенәсе. Ул Шушма елгасы буенда, хәзерге Яңа Чишмә районының Югары Никиткино авылы янында, яшәгән булган. Күптән түгел бу авылның исемен борынгы болгар шәһәре хөрмәтенә Тубылгытау дип үзгәрттеләр.

Шәһәрлек өч яктан Шушма елгасы ярына тоташа торган текә тау-чокырлар, ә бер ягыннан агач һәм балчык ныгытмалар белән әйләндереп алынган. Аның мәйданы 2 гектардан артмый. Күрәсең, ул зур шәһәр түгел, ә хәрби ныгытма — кальга булгандыр. Тубылгытауның тарихына бәйләнешле мәгълүматлар язма документларда сакланмаган. Археологлар да аны ныклап өйрәнмәгән әле.

Кашан да, Суар һәм Ашлы кебек үк, болгарларның иң эре шәһәрләре рәтенә кергән. Ул хәзерге Лаеш районының Шуран һәм Балык Бистәсе районының Сорочьи Горы авыллары арасында, Чулман суының уңъяк ярында урнашкан. Мәйданы 100 гектардан артып китә. Элекке шәһәр урынында сугыш кораллары, алтынкөмештән һәм асылташлардан ясалган бизәнү әйберләре, үлчәүгерләре һәм акчалар, савыт-саба ватыклары һәм башка әйберләр табыла.

Кашан шул төбәктәге болгарларның сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге булган. «Шәһри Кашан җиһанның бер гүзәл почмагыдыр,— диелә халкыбыз чыгарган бер борынгы җырда.— Аның олысы-кечесе — һөнәр остасы, берсе — корыччы, икенчесе — алтын-көмешче».

* * *

10—13 нче гасырларда Болгар дәүләтендә тагын бик күп эревак шәһәрләр булган. Спас районының Балымер, Әлки районының Иске Нократ, Иске Камка, Алексеев районының Войкино, Ромодан, Тәтеш районының Хулаш авыллары янында һәм башка күп кенә урыннарда болгар шәһәрлекләре бар. Белешеп карагыз әле, бәлки, сез яши торган авыл һәм шәһәр тирәләрендә дә болгар истәлекләре бардыр? Булса, андый урыннарга экскурсияләр оештырыгыз һәм аларны җимерелүдән коткарып калу чараларын күрегез.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Суар шәһәре турынданиләр сөйли аласыз?
2. Ашлы, Кашан, Җүкәтау һәм Тубылгытау шәһәрләрен кыскача гына тасвирлап сөйләгез.
3. Әти-әниләрегездән һәм әби-бабаларыгыздан сорап карагыз әле, алар борынгы болгар шәһәрләре турында ниләр беләләр икән?
4. Мөмкин булса, каникул вакытында болгар истәлекләренә һәм музейларга экскурсияләр оештыруны планлаштырыгыз.

15. СӘҮДӘ ЭШЕ ҺӘМ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАШКА ИЛЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

Болгар иле кораблар йөзәрлек Идел һәм Кама елгалары кушылган, Азия белән Европаны тоташтыручы бик әһәмиятле сәүдә юллары кисешкән җирдә урнашкан. Монда көнчыгыш белән көнбатыш, көньяк белән төньяк тоташкан. Дөньяның күп илләреннән килгән сәүдәгәрләр Болгарда очрашкан. Болгар базарларына дөнья малы агылган. Шулай итеп, Болгар иле бик күп ерак илләр белән үзара файдалы элемтәдә торган.

Кырмыска шикәр тәмен ничек тойса, безнең бабаларыбыз да сәүдә тәмен шулай белгәннәр. Илнең төп базарын, зурлап, Ага-Базар дигәннәр. Хәзерге Болгар шәһәреннән ерак түгел, Идел буенда урнашкан булган. Ул дөньяның төрле ягыннан килгән сәүдәгәрләрнең үз телләрендә товарларын мактау, башкаларның малларын арзанракка сатулашу тавышларыннан гөрләп торган. Монда ерак Һиндстаннан, Кытайдан, Ираннан, Урта Азия төбәкләреннән килгән сәүдәгәрләр алтын, көмеш, ефәк, киҗе-мамык тукымалар, матур бизәкле көмеш һәм чүлмәк савыт-сабалар, бизәнү әйберләре, хушбуйлар, китаплар, язу кәгазе, җиләк-җимеш, аш тәмләткечләр сатканнар. Җәеп салгач, күз явын алырлык Византия, Әрмәнстан келәмнәре базарга үзенчә бер ымсындыргыч төс керткән. Дөньяда иң яхшы саналган Дәмәшкъ, Иран, Франк кылычлары, хәнҗәрләре зыңлап торган. Рус иленнән кайбер төр мехлар, кораллар, коллар; Балтик буеннан, Европадан гәрәбә, кораллар; Каспий далаларыннан тоз һәм терлек ризыклары; төньяк урманнарыннан төрле җәнлек һәм мехлар китерелгән.

Ага-Базар урнашкан Идел ярына товар белән тулы сәүдә кораблары, көньяктан дөя кәрваннары килеп туктаган. Үз чиратында алар Болгар иленнән үз җирләрендә булмаган, аеруча затлы күн, тире, мех, терлек, эре балык, бал, балавыз, күн аяк киеме, ашлык, корал, урман чикләвеге; каен агачы төяп киткәннәр. Мондый сәүдә

Ага-Базар кибете. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

Болгар акчалары.

Болгар иленә зур табыш китергән. Патша Болгар иленә килгән һәм аның аша узган һәр корабтагы, кәрвандагы малның уннан бер өлешен казна файдасына алган. Атка атланып, үзенең якыннары, сакчылары белән, Болгар иле патшасы да базарда йөрергә яраткан. Барысы да, баш киемнәрен салып, аны сәламләгән.

Чит ил сәүдәгәрләрен ныграк тартыр өчен базар янына кәрвансарайлар салынган. Сәүдәгәрләр шунда яшәгәннәр, ял иткәннәр. Аларның иминлеген тәэмин итеп, илләр арасында сәүдә килешүләре төзелгән.

Сату-алу акчага барган. Башта Болгар илендә Иран, гарәп акчалары кулланууда йөргән. Ә 10 нчы гасыр башыннан болгарлар үзләре акча суга башлаганнар. Акча барлыкка килгәнче аның урынына тиен тиреләре йөргән: бер тиен тиресе, ике тиен тиресе, өч тиен тиресе... Безнең вак акчаны тиен белән санавыбыз шул вакытлардан бирле килә булса кирәк.

Төньяк халыклары белән сәүдәне болгарлар үз кулларында нык тотканнар. Чөнки аннан аларга зур табыш килгән. Төньяк кешеләрен илгә салкын алып киләсез, уҗымнарыбызны өшетәсез дигән булып Болгар базарларына кертмәгәннәр. Көнчыгыш сәүдәгәрләренә дә төньякның салкыны турында куркыныч уйдырмалар сөйләп, аларны ул җирләргә үткәрмәгәннәр. Шулай итеп, Болгар төньяк халыклары һәм көнчыгыш сәүдәгәрләре арасында арадашчылык ролен үтәгән. Аларның товарларын үз кулларына алып, болгар сәүдәгәрләре үзләренә файдалы итеп сатканнар.

Болгар сәүдәгәрләре бик ерак илләргә барып алыш-биреш иткәннәр. Борынгы шигырь юлларында бу хакта менә нәрсәләр әйтелә:

Базаркяннар бу көн Һиндта,
Ярин Хорасан, я Кәшмирдә,
Сәйяхлар көни-кичләрдә
Кунаклар дик олуг илдә.

Сәүдәгәрләр бүген Һиндстанда,
Я Хорасан, я Кәшмирдә.
Бөек илнең кунаклары кебек
Көн-төн сәяхәт итүдә.

Ерак Һиндстанны сез беләсез инде. Болгар сәүдәгәрләрен хәтерләтеп, бу илнең башкаласы Дәһлинең бер капкасы бүген дә «Болгар» исемен йөртә. Хорасан шәһәр генә түгел, зур өлкә булган. Ул Урта Азия, Иран, Әфганстан илләренең шактый өлешен биләгән. Кәшмир Һиндстанда, Пакистанда булган. Болгар илен анда «Бөек ил» дип йөрткәннәр. Европа илләрендә дә аны «Бөек Болгар иле» дип атаганнар.

Бөек илнең сәүдәгәрләре рус шәһәрләренә барып йөргәннәр. Балтик буена, Польша, Финляндия, Даниягә, Норвегия, Швециягә, Багдад һәм Константинополь базарларына барып чыкканнар. Сәүдә Болгар иленең көчен арттырган, аның отыры баюына, көчәюенә китергән.

Болгарлар башка илләр белән төрле бәйләнешләрдә булганнар. Алар борынгы венгрлар белән янәшә һәм бергә яшәүләрен күп еллар онытмаганнар. Венгрлар, Дунай буйларына күченеп, Венгрия корольлеген оештыргач та, бер төркем болгарлар шунда китеп урнашканнар. Алар венгр корольлегендә финанс эшләрен башкарганнар. Хәзерге Венгриянең башкаласы — Будапешт. Ул Дунай елгасының ике як ярына урнашкан. Уң ягындагы өлеше Буда, сул ягындагысы Пешт дип атала. Сул ягына килеп утырган Болгар кешеләре Пешт өлешенә нигез салганнар.

Болгар белән күрше Борынгы Рус арасындагы бәйләнешләр ике ил өчен дә аеруча әһәмиятле булган. Бу ике дәүләт бер үк дәвердә барлыкка килә. Ике мөстәкыйль ил татулык, хезмәттәшлек белән яшәргә тели. 985 елда ук ике ил арасында килешү төзиләр. Болгарлар бу килешү язуына: «Кайчан да кайчан колмак су төбенә батар, таш су өстендә йөзеп йөрер, бу вәгъдә шунда бозылыр», дип теркәп куялар. Билгеле инде, колмак җиңел — беркайчан да суга батмый, таш авыр — бер вакытта да суда йөзә алмый. Димәк, бу килешү мәңгелеккә төзелгән була. Килешүне тагын да ныгыту өчен Болгар илчелеге, үзләренең иманы итеп кабул иткән динне — исламны — тәкъдим итеп, Киев Русена бара. Соңрак, христиан динен кабул иткәч, руслар, Болгар иленә килеп, үз чиратында христиан диненә күчәргә өндәп йөриләр. Әмма бер якның да тәкъдиме үтми. Киев Русе — христиан, Болгар иле ислам дәүләте булып кала. Ләкин бу хәл ике арадагы мөнәсәбәтләргә әллә ни зарар китерми. Болгар сәүдәгәрләре Русьта, рус сәүдәгәрләре Болгарстанда тоткарлыксыз сәүдә итәләр. Һәр ике илдә күрше дәүләтнең сәүдә бистәләре, остаханәләре яши. Болгар — рус мөнәсәбәтләрендә үзара егет өйләндерү, кыз бирешү дә сирәк күренеш түгел. Мәсәлән, рус кенәзе Андрей Боголюбскийның хатыны болгар кызы икәнлеге билгеле.

Болгар — рус бәйләнешләрендә

һәрчак төзек булган Болгар — Киев юлы зур әһәмияткә ия була. Анда 20 тукталыш урыны ясалган. Һәркайсында кунып чыгарга, ял итәргә мөмкин булган.

Әмма мәңгелеккә дип төзелгән дуслык килешүе 12 нче гасырдан бозыла башлый. Рус гаскәрләре әледән-әле Болгар иленә бәреп керәләр, шәһәр, авылларны яндыралар, талыйлар, күп кешеләрне әсир итеп алып китәләр. Төп максат болгарлар кулында булган Идел су юлын тартып алу була. 1089 елны болгар сәүдәгәрләрен аеруча нык талыйлар, кыйныйлар. 1164, 1183 елгы рус яулары үтә зур дәһшәтләр тудыра. Бу елларны рус илбасарлары болгарлар җиренә бик эчкәре үтеп керәләр. 1164 елда Идел буенда Ибраһим шәһәрен яндыралар, 1183 елда алар илнең үзәгенә — башкалага кадәр үк барып җитәләр. Билгеле, болгарлар үз азатлыклары өчен батырларча көрәшәләр. Алар, җавап йөзеннән, 1107 елда Суздальгә, 1152 елда Ярославльгә яу белән баралар.

Шулай да болгарлар белән руслар арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре өзелеп бетми. Бәйсез, мөстәкыйль дәүләт була ул чакларда Болгар һәм Рус илләре.

Иң тыгыз, күпкырлы мөнәсәбәтләр Урта Азия, Кавказ, алар аша ерак гарәп, фарсы, Кытай, Һиндстан илләре белән бара. Кайберләренең диннәре дә бер — ислам дине була. Ул якларда шулай ук болгарларга тугандаш төрки халыклар да күп яши.

Болгарлар аеруча Урта Азиянең Бохара, Харәзем, Хорасан өлкәләре белән тыгыз бәйләнештә торалар. Хәтта элгәрге чорда андагы саманилар дәүләтенә үзенә күрә бер бәйлелектә булалар. Бу төбәкләр аркылы болгарлар Багдадка, Иранга, Мисырга, Сириягә, Төньяк Африкага барып җитәләр. Алар Кавказдагы Әрмәнстан белән дә тыгыз мөнәсәбәттә булалар. Аннан Болгар иленә тукымалар, келәмнәр китерелә. 1222—1223 елларда Әрмәнстан монголлар тарафыннан тар-мар ителгәч, күп кенә әрмәннәр Болгарлар җирендә сыену урыны табалар. Шәһри Болгардан ерак түгел аларның авыллары була.

Шулай итеп, Болгар иле ул вакытта дөньяның байтак илләре белән күпкырлы элемтәдә яши. Бу илләрдәге казанышлар Болгар иленә дә үтеп керә, аның хуҗалыгын баета, мәдәниятен алга җибәрә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен Болгар иле дөньякүләм сәүдә үзәгенә әверелә?
2. Болгарлар кайсы илләр белән сәүдә иткәннәр, ул илләрдән нәрсә китерелгән?
3. Болгар иле чит илләргә нәрсә саткан?
4. Болгарлар белгән илләрне, җирләрне картадан күрсәтегез.

16. БОЛГАР ИЛЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ

Дөньяда күп диннәр бар. Борын-борын заманнан һәр кабилә- ыру, халык кодрәтле илаһи көчләргә ышанганнар. Кешеләр ышанусыз, имансыз яши алмаганнар. Иманнары, ышанычлары бетсә, кешеләр явызланганнар, үзара сугыш башлаганнар. Илләр, халыклар өстенә афәт килгән. Һәр диндә башта аллалар күп булган. Дәүләтләр барлыкка килеп, илдә патша гына идарә итә башлагач, бердәнбер, әмма бик зур илаһи көчкә ия булган аллалы диннәр барлыкка килгән. Яһүд, христиан һәм ислам диннәре шундыйлар. Ислам дине VII гасырда, моннан 1400 еллар элек, Гарәбстан ярымутравында гарәп кабиләләрендә барлыкка килә. Алладан кала иң олуг пәйгамбәрнең исеме Мөхәммәт булган. Ислам дине җан һәм тән чисталыгына, ярлы һәм зәгыйфьләргә ярдәм итәргә чакырган. Ислам динен тотучы һәр кешенең бертигез булуын әйткән. Боларның барысы да ислам диненең иң төп һәм изге китабы Коръәндә язылган. Ислам диненең бу сыйфатлары аны тиз арада бик күп халыкларның үзләренә иман итеп кабул итүенә китергән. 8—9 нчы гасырларда Кавказда, Урта Азиядә, Хорасанда ислам дине киң тарала һәм дәүләт диненә әверелә. Болгар бабаларыбыз, бу җирләр белән тыгыз элемтәдә торып, 825 елларда ук Айдар хан вакытында ислам динен кабул иткәннәр. Бу хакта кызык риваятьләр дә безгә кадәр килеп җиткән. Менә шуларның берсен болгар тарихчысы Якуб Ногман улы үзенең «Болгар тарихы» исемле китабында язып калдырган.

Болгарларның патшасы, хатыны белән икәүләп, бик каты авырып киткән. Күп табибларны, сихерчеләрне чакырып караганнар. Нәрсәләр белән генә дәвалап карасалар да, берсенең бер файдасы тимәгән. Савыгуга өметләре тәмам өзелгән икән патша белән аның хатынының. Көннәрдән бер көнне Болгар иленә Бохара шәһәреннән ислам динен яхшы белүче, кешеләрне дәвалаучы табиб килгән. Ул, Болгар илендә төрле могҗизалар күрсәтеп, күп кешеләрне яман авырулардан терелтеп, ислам диненә керергә өндәп йөри икән. Вәзирләре бу хакта патшага әйткәннәр. Патша бу Бохара табибын тиз генә тотып китерергә боерган. Бу изге адәм патша белән аның хатынының хәл-әхвәлен белгәч: «Әгәренки сез минем динемне кабул итсәгез, мин сезне дәва кылырмын»,— дигән. Патша белән хатыны аның динен кабул итәргә риза булганнар. Бу кеше аларны дәвалаган, патша гаиләсе үлемнән котылып тәмам сәламәтләнгән һәм ислам динен кабул иткән. Ил халкы да, алар белән бергә, үзләренә иман итеп ислам динен алган ди.

Ул вакытта ислам динендәге ил-

ләрнең үзәге Багдад шәһәре була. Анда ислам диненең иң зур әһеле Хәлифә яши. Ислам динен кабул иткәч, болгарларга аның хәерфатихасын алырга кирәк булган. Бу көчле дәүләт белән элемтәгә керү дөньяда Болгар иленең абруен тагын да күтәргән, әлбәттә. Шундый абруйлы Хәлифәнең ышанычын алгач, Болгар иленең дошманнары куркып калганнар.

Бу чорда Болгар илендә Алмыш патша (895—925 еллар) идарә иткән (үзенә мөселманча Җәгъфәр Габдулла улы дип исем куштырган). Илнең бәйсезлеге, болгар кабиләләренең берләшүе, илне баету өчен ул зур көч куйган. Алмыш патша Багдадка зур бүләкләр белән илчелек җибәрә. Болгарлар патшасы үзенең хатында ислам диненә өйрәтүчеләрне тоту, шәһәр һәм мәчетләр салу өчен акча һәм төзүчеләр сорый. Ислам үзәгеннән ерак төньякта диннең таралуына Багдадта сөенеп караганнар. Багдадның дингә өйрәтүчеләрдән, галимнәрдән, төзүчеләрдән, һөнәрчеләрдән торган зур илчелек төркеме 921 елның 21 июнендә Болгар иленә юнәлә. Күргән-белгәннәрне язып баручы һәм дин белгечләренең башлыгы итеп Әхмәт ибн Фадлан билгеләнә. Ул бик күзәтүчән, тапкыр кеше була. Юлда һәм Болгар илендә күргәннәрен бик җентекләп язып бара. Аның язмалары безнең көнгә кадәр килеп җиткән. Болгар иле һәм болгарлар хакында бу китаптан



Багдад илчеләрен кабул итү. *Б. Урманче рәсеме.*

без бик күп нәрсәләр укый алабыз.

Юллар бик авыр, куркыныч була. 922 елның ямьле 12 маенда, якшәмбе көн, Багдад илчелеге Болгар иленә килеп җитә. Патша сараена кадәр ике көнлек юл калгач, Алмыш патша үзенең күп сандагы якыннары, сакчылары белән илчелекне каршы алырга чыга. Иң кадерле кунакларны каршы алган кебек, ул очрашкач, атыннан төшеп, баш ия. Кунаклар өстенә алтын, көмеш тәңкәләр чәчә. Зур мәҗлес җыела. Аягүрә

басып, Хәлифәнең Болгар патшасына язган хатын тыңлыйлар. Үзәк мәчеттә Хәлифәгә һәм Болгар патшасы исәнлегенә багышлап намаз укыйлар.

Ислам дине тиз арада бөтен Болгар иленә тарала. Әмма болгарлар үзләренең борынгы әби-бабалары динен — Тәңрегә табынуны да онытмыйлар. Тәңре ислам алласының бер исеменә әверелә.

Болгар иленең рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе зур бер тарихи баскыч була. Ул болгар кабиләләренең берләшеп бер халык булып оешуына ярдәм итә. Алмыш патша үзен алланың җирдәге илчесе дип белдерә. Үзенә буйсынмаган кабиләләргә: «Алла гыйззе вәҗәл миңа ислам динен һәм мөселманнар дәүләтен бүләк итте, мин, аның колы, карышканга кылыч белән барырмын»,— дип яный.

Ислам дине Болгар иленең дәүләт булып ныгуында да сәүдә, һөнәрчелек үсешендә дә әһәмиятле роль уйный. Болгар иле ул чорда дөньяда иң алга киткән ислам илләре белән тыгыз бәйләнешләр урнаштыра. Бу илләрдәге мәдәни, фәнни казанышларның да Болгар дәүләтенә үтеп керүенә җирлек була.

1989 елда Идел буе, Урал төбәге мөселманнары Болгар иленә Багдад илчесе килүнең мөселман календаре белән 1100 елы тулуны бәйрәм иттеләр. Алар, Болгар шәһәре хәрабәләренә барып, намаз укыдылар, рәхмәтләр әйтеп, болгар бабаларыбызны искә алдылар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ислам дине кайда һәм кайчан барлыкка килгән?
2. Болгар илендә ул кайчан кабул ителгән?
3. Багдад илчелеге турында сөйләгез.
4. Болгарларның ислам дине кабул итүләренең әһәмияте нинди?

17. БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ МӘДӘНИЯТЕ

Болгарлар бик тыгыз элемтәдә торган Көнчыгыш мөселман дәүләтләре ул вакытта (8—13 нче гасырларда) мәдәни яктан бик нык үскән илләр булалар. Анда фән, әдәбият һәм сәнгать чәчәк ата. Шунда яшәгән астроном Әл-Бируни, атаклы медик-табиб Әбу Гали Сина, философ Әл-Фараби, математик Әл-Харәзми бик зур галимнәр булалар. Алар кешелек җәмгыятенә кыйммәтле мирас калдыралар. Мәсәлән, без бүген үз телебездә мәктәпләрдә укый торган тарих, география, алгебра кебек күп кенә фәннәрнең исемнәре дә, без яза торган саннар (цифрлар) да шул вакытлардан ук Шә-

Чүлмәк тоткасында рун язуы.



Беренче каләмнәр.

рык илләреннән кереп калган.

Ислам диненең дә шушы алга киткән илләрдән керүе Болгар илендә фән, мәгърифәт, әдәбиятның яңа күтәрелешенә китерә. Болгарлар борын-борыннан яза белгәннәр. Башта алар, борынгы башка төрки халыклар кебек үк, тамгаларга охшаган рун хәрефләре белән язганнар. Кәгазъ әле булмаган, алар балавызланган такталарга, эшкәртелгән каен тузларына яза торган булганнар. Хәзер дә мәгънәсез сүз сөйли торган кешегә «Тузга язмаганны сөйләмә» дигән әйтем шул заманнардан ук килә булса кирәк. Аларга сөяктән матур итеп эшләнгән очлы каләмнәр белән язганнар.

Ислам дине белән бергә, Болгар иленә гарәп язуы да килеп керә. Урта Азиядән кәгазь дә алып кайта башлыйлар. Шуннан соң каурый яки камыш каләмнәр белән карага манчып язу һөнәре үсә. Болгар илендә ислам дине никадәр ныграк таралса, укый-яза белүче кешеләр шул кадәр күбәя. Чөнки ислам динен кабул иткән кеше Коръән һәм башка дини китаплар да укый белергә тиеш була. Гади халыкның да шактые укыйязарга өйрәнгән. Һөнәрчеләр эшләгән әйберләренә еш кына үз исемнәрен язып куялар. 1146 елда йозакчы оста Әбу Бәкер йозакка ия буласы кешегә менә нинди матур теләкләр язып калдырган.

«Бу — Әбу Бәкер эше.

Тотрыклы дан һәм уңышлар, һәм күпкырлы бәхет, һәм олуглык, һәм иркен тормыш булсын бу йозак иясенә!»

Әбу Бәкер йозагы. (Биләрдә табылган).



Болгар китабының металл тышлыгы.

Шундый изге теләкләр тели алган кеше, әлбәттә, үзе дә бик киң күңелле, әйбәт кеше булгандыр!

Болгар һөнәрчесе, үзе эшләгән йозакның читтәге ислам илләрендә дә сатылуына өмет итеп, бу сүзләрне гарәп телендә язган. Гарәп, фарсы телләрен сәүдәгәрләр дә белгән. Мөселман дөньясының теләсә кайсы почмагында бу телләрне белү кирәк булган. Тел белүне куәтләп, безнең бабаларыбыз: «Җиде йортның (илнең) телен бел, җиде төрле белем бел», дигәннәр.

10 нчы гасыр башларында ул шәһәрләрдә генә түгел, авылларында да башлангыч мәктәпләр булган. Анда укырга, язарга, иман тотарга өйрәнгәннәр. Һәр мәчет каршында мәдрәсәләр ачылган. Анда илгә кирәкле белгечләр әзерләнгән. Тагын да югарырак белем алу өчен, болгар укымышлылары Урта Азиянең фән, гыйлем үзәкләренә киткәннәр. Андагы мәшһүр галимнәрдән белем алганнар. Кайбер болгар галимнәре шунда ук үзләре дә укытканнар. Шундыйлардан Хуҗа Әхмәт Болгари хәзерге Әфганстан һәм өлешчә Иран, Урта Азия, Һиндстанны эченә алган газнәлеләр дәүләтенең иң бөек солтаны (патшасы) Мәхмүд Газнәвинең (998—1030 еллар) остазы булган.

Болгар илендә математика, астрономия, химия, медицина, тарих, география кебек фәннәр үскән. Болгар галимнәре үзләреннән 700 чакрым төньякта астрономик күзәтүләр алып барганнар. Приборлар ярдәмендә дөнья якларын төгәл билгели белгәннәр.

Болгар архитекторлары матур биналар төзегәндә төрле матема-

Мәдрәсәдә Йосыф кыйссасы дәресе. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

тик хисаплаулар, сызымнар эшләгәннәр. Моның өчен алар берберсен эченә алган кечкенә турыпочмаклы сызымнардан файдаланганнар. Андагы математик, геометрик бәйләнешләрне төзеләсе бина үлчәмнәренә күчереп, аны төгәл, матур, мәһабәт итәргә теләгәннәр.

Болгарларда медицина да алга китә. Аеруча болгар табибларының дарулар турындагы хезмәтләре еракларга билгеле була. Борһанетдин Ибраһим Йосыф улы Болгари гади дарулар турында, ә Таҗетдин Юныс улы Болгари агулану очракларында дәвалану турында китаплар язалар. Ә болгар табибы Хуҗа Әхмәд Болгари бөтен ислам дөньясында шөһрәт казана. Ул, Болгар иленнән китеп, Әфганстанда Газнә шәһәрендә табиблык итә. Аның тылсымлы шифасы белән күпләр аякка баса. Шагыйрьләр аны мактап шигырьләр язалар, исеме риваятьләргә күчә. Хәтта бүгенге көннәрдә дә мөселманнар дөньяның төрле почмакларыннан болгар табибының каберенә һәм кабер янындагы чишмәгә шифа алу өмете белән киләләр. 1971 елда аның кабере өстенә ак мәрмәрдән мавзолей корылган.



Математик хисаплау җайланмасы.

Болгар илендә язучылар, шагыйрьләр дә күп булган. Алар матур-матур хикәятләр, кыйссалар язып калдырганнар. Шулар арасында шагыйрь Кол Галинең хезмәте аеруча мәшһүр. Ул 1212—1233 елларда «Кыйссаи Йосыф» исемле китап язган. Ул безнең көнгә кадәр кулдан-кулга күчеп килгән. Анда Йосыф белән Зөләйханың мәхәббәте хакында, явызлыкка каршы көрәш, хаклыкның тантана итүе, ата-бабага ихтирам, илеңне ярату турында мавыктыргыч итеп язылган. Йосыф, зур авырлыклар кичереп, олы дәрәҗәгә ирешә.

Шулай итеп, Болгар иле үзе дә ислам дөньясының әһәмиятле бер гыйльми, мәдәни, мәгърифәт үзәгенә әверелә. Андагы мәдрәсәләргә ерак иллә рдән дә килеп укый башлыйлар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Болгар илендә мәдәниятнең алга китүендә ислам диненең әһәмияте нинди?
2. Болгарлар нинди язулар кулланганнар?
3. Алар нинди мәктәпләрдә белем алганнар?
4. Болгар илендә нинди фәннәр алга киткән?

18. МОНГОЛ ЯУЛАРЫ ҺӘМ БОЛГАР ИЛЕ

1236 елның көзендә Болгар дәүләте моңарчы һичкайчан күрелмәгән язмышка дучар була. Монгол яулары Болгар җирләрен басып алалар, шәһәрләрен һәм авылларын талыйлар, халкын кыралар. Тормыш сулышы бер мәлгә бөтенләй тукталып калгандай була.

Монголлар күчмә халык булалар. Төрки каганлыгы чорында ук инде, ягъни 6—8 нче йөзләрдә, Үзәк Азия далаларында монгол телендә сөйләшүче күпсанлы кабиләләр (дунху, жужань, сәнби, кидань һ. б.) яши. Шулар арасында кытай елъязмачылары та-та, татань (татар) исемле сугышчан кабиләләрне дә еш телгә алалар. Кытайлар үзләреннән төньякта яшәгән барлык кабиләләрне дә гомуми исем белән татарлар дип атап йөрткәннәр.

Монголларның төп байлыклары һәм яшәү чыганагы мал-туар булган. Иген икмәгәннәр. Үзләренең көтү-көтү атлары, сарыклары, кәҗәләре һәм дөяләре артыннан ел буе бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәннәр. Тиз сүтеп җыела торган киез тирмәләрдә яшәгәннәр. Аларның бөтен тормышлары диярлек ат өстендә үткән. Шул заман кешеләре, монголларның балалары тәпи йөри башлаганчы ук атка атланып йөрергә өйрәнәләр, дип әйтә торган булганнар.

Бер-берсе өстеннән хакимлек итү өчен монгол кабиләләре арасында еш кына сугышлар булып тора. 12 нче гасыр азагында һәм 13 нче гасыр башында озакка сузылган кабиләара көрәштә атаклы Есүгәй баһадирның яшь һәм көчле улы Темучин җиңеп чыга.

Темучинга 4—5 яшьләр чамасы булганда, аның әтисен татар кабиләсеннән булган дошманнары үтерә. Бу вакыйга Темучинның йөрәгендә мәңге төзәлмәслек җәрәхәт булып кала. Үсә төшкәч, ул татарларны үзенең кан дошманы дип игълан итә, алардан үч алырга чакыра. Бервакыт Темучин татарлар белән кытайлар арасында килеп чыккан сугышта катнаша. Бу сугышта татарлар җиңеләләр. Темучин аларның барысын да, хатын-кызларына һәм балаларына тикле, юк итәргә боера. Коточкыч үтереш-суеш башлана. Коллыкка төшкән татарларны Темучин гаскәренә кушалар һәм алар монголлашып бетәләр, ләкин исемнәре таралып кала.

Шуннан соң Темучин таркау монгол кабиләләренең калганнарын да үзенә буйсындыра һәм бердәм Монгол дәүләте төзү эшенә керешә. 1206 елда монгол кабиләләренең юлбашчылары (нойоннар) җыелган корылтайда аны Чыңгыз хан (Олуг хан) дип игълан итәләр.

Талантлы дәүләт эшлеклесе, оста дипломат, шул ук вакытта ифрат комсыз һәм шәфкатьсез гас-

кәр башлыгы Чыңгыз хан тиздән басып алу һәм талау сугышларына ныклап әзерләнә башлый. Ул үзенең 10 меңлек шәхси гвардиясен булдыра. Бөтен гаскәрен төмәннәргә (бер төмәндә 10 мең кеше), төмәннәрне — меңнәргә, меңнәрне — йөзләргә һәм йөзләрне унар кешелек төркемнәргә бүлеп чыга. Гаскәр башына — хан, төмәннәр һәм меңлекләр башына югары катлау кешеләреннән торган хәрби җитәкчеләр куела. Сугышчылар арасында каты һәм рәхимсез тәртип урнаштырыла. Сугыш кырыннан ун кеше качса, йөз кешене җәзалап үтергәннәр. Әсиргә төшкән бер кеше өчен ун кеше шундый ук җәзага хөкем ителгән. Шәһәрләрне һәм хәрби ныгытмаларны штурмлаганда алар тараннар, таш аттыру җайланмалары, камау манаралары кулланганнар. Агач ныгытмаларга һәм йорт өсләренә яндыргыч сыекчалар тутырылган савытлар, сумала һәм дегет сеңдерелгән сүс урап уклар атканнар.

Чыңгыз хан.
Борынгы кытай рәсеме.

Кайда гына булмасын, Чыңгыз хан үзенә буйсынган кабиләләрне гаскәрнең алдыннан барырга һәм беренче булып һөҗүмгә ташланырга мәҗбүр иткән. Ул кабиләләрне мыскыллап татарлар дип йөрткәннәр. Шул заманның бер тарихчысы болай дип яза: «Чыңгыз һәркайда сугышка иң алдан татарларны җибәрә, шуңа күрә аларның исеме монголныкына караганда да ныграк таралган була, чөнки бөтен җирдә: «Әнә, татарлар килә!» — дип кычкырганнар. Алай гына да түгел, монголларга соңыннанрак буйсынган барлык кабиләләр, халыклар да, нинди телдә сөйләшүләренә карамастан, Чыңгыз хан әмере буенча татар дип аталырга тиеш булганнар.

Монгол гаскәрләре XIII гасыр башында күп кенә илләрне, шул исәптән Кытайны, Харәзем, Бохара, Сәмәрканд, Мерв, Иран, Грузия, Әрмәнстан һәм Азәрбайҗанны, рәхимсез җимереп үтәләр. 1223 елда Чыңгыз ханның курку белмәс гаскәр башлыклары Җәбә һәм Субудәй җитәкчелегендәге сугышчылары Көнчыгыш Европа да-



Болгарларның монголлар белән бәрелеше. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

лаларына килеп чыгалар һәм Калка елгасы буенда руслар белән кыпчакларның берләшкән гаскәрләрен тар-мар итәләр.

Шул ук елның көзендә безнең бабаларыбыз болгарлар монголлар белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашалар. Идел буенда, хәзерге Самара шәһәре тирәсендә була бу хәл. Болгарлар, Жигули таулары тирәсендә алдан ук ныгытып куелган уңайлы урыннарга яшеренеп, монголларны көтеп алалар. Тегеләр якынайгач, бик нык курыкканга сабышып, кинәт чигенә башлыйлар. Монголлар алар артыннан куа киләләр, ә болгарларның калган өлеше, яшеренгән урыннарыннан чыгып, аларга көтмәгәндә арттан ташлана. Дошман кама-

лышта кала. Шул заман тарихчысы болай дип яза: «Алар уртада калганнан соң, төрле яктан өсләренә кылыч ябырылды. Бик күбесе кырылып бетте, азлары гына качып котыла алды. Алары 4 меңләп булгандыр диләр». Качып котылган монголлар көчхәл белән Чыңгыз хан урдасына кайтып җитәләр һәм аңа монголларның беренче тапкыр җиңелүе турында хәбәр җиткерәләр.

1229 елда монголлар Болгарга яңадан яуга чыгу турында карар итәләр. Түбән Идел буйларында алар кыпчак җирләрен, Саксин шәһәрен басып алалар. Болгарларның сакчы отрядлары дошманны Җаек (Урал) елгасы буенда каршы алалар. Бәрелеш каты була. Тик

бу юлы болгарлар җиңеләләр. Шулай да монголлар әлегә урта Иделгә, Болгар иленә үк күтәрелергә батырчылык итмиләр.

1232 елда монголлар Болгар илен яңадан басып алырга ниятлиләр. Алар хәтта Биләргә кадәр килеп җитәләр. Көчле ныгытылган Олуг шәһәрне күреп, монголлар каушап калалар һәм, аз санлы гаскәр белән аны кулга төшерә алмаячакларын аңлап, кире кайтып китәләр.

1235 елда Монголиянең башкаласы Каракорымда зур корылтай җыела. Биредә әлегә кадәр буйсынмаган Болгар һәм Рус илләрен яулап алу турында карарга киләләр. Монголлар хәлиткеч сугышка әзерләнәләр. Гаскәр башлыгы итеп Чыңгыз ханның оныгы Батый хан билгеләнә. Бер елдан соң, 1236 елның язында, 300 мең кешелек монгол армиясе көнбатышка таба кузгала. Аның алдынгы отрядлары җәй башларында Болгар иленең чик буйларына килеп җитәләр. Көзгә тикле, төп көчләрнең килеп җиткәнен көткән арада, алар болгар шәһәрләренә шымчылар җибәрәләр, ныгытмаларын өйрәнәләр, зур булмаган сугышлар алып баралар.

Болгарлар да тик ятмыйлар: гаскәр туплыйлар, ныгытмаларын төзекләндерәләр, сугыш кораллары әзерлиләр. Бу вакытта Олуг шәһәрдә 50 меңләп гаскәр тупланган була. Шулай да күп санлы һәм бик күп сугышларда чыныккан монголларга каршы торырлык көч булмый ул.

1236 елның көзе. Халкыбызга үлем, коллык һәм әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәтләр алып килгән канлы вакыйгалар белән тарихка кереп калган көз. Шул вакыйгаларның шаһите болай дип язып калдырган: «Болгар җирендә угланнар (монгол ханының уллары) бергә кушылдылар; гаскәрнең күплегеннән җир өсте гүләп, ыңгырашып торды, шау-шудан кыргый киекләр һәм ерткыч җанварлар кая качып котылырга белмәделәр. Башта монголлар, көч кулланып, штурмлап, Болгар (Биләр) шәһәрен алдылар. Бу шәһәр халкының күплеге, үтеп булмаслык итеп ныклап урнашуы белән бөтен дөньяга мәгълүм иде. Башкаларга сабак булсын өчен, шәһәр халкының бер өлешен үтерделәр, бер өлешен әсирлеккә алдылар». Шуңа охшашлы хәбәрләрне рус елъязмачысы да теркәп куйган: «Көнчыгыш илләреннән Болгар җиренә денсез татарлар (монголлар) килделәр һәм данлыклы Олуг шәһәрне (Биләрне) яулап алдылар, карт-корыдан башлап имчәк балаларына кадәр барча кешене турадылар, бик күп байлык кулга төшерделәр, шәһәрне яндырдылар һәм бөтен илне әсир иттеләр».

Олуг шәһәр хәрабәләрен казыганда археологлар күп тапкырлар монгол яуларының хәзергәчә сакланып калган эзләренә тап бул-

дылар. Шәһәрлекнең теләсә кайсы урынында көрәк төртергә өлгермисең, көл-күмер катламына, кеше сөякләренә, ук-җәя, сөңге һәм башка сугыш коралларының калдыкларына килеп төртеләсең. 1236 елгы көчле янгын белән бәйле шушы катламда монгол сугышчыларыннан калган дистәләрчә ук очы табылды. Шәһәр зиратларының берсендә 26 кеше күмелгән туганнар каберлеге казып тикшерелгән иде. Икенче бер каберлектә күмелгән кешенең баш сөягенә тимер ук очы кадалып калган. Эчке шәһәрдә табылган бер чокырда 5 бала һәм 7 олы кеше скелетлары табылды. Берсенең башы юк, ә икенчесенең аягы, өченчесенең тагын ниндидер әгъзасы җитми. Сөякләр тәртипсез рәвештә таралып яталар. Бер баш сөяге астыннан тимер сөңге очы, икенчесеннән сугыш балтасы килеп чыкты. Чокырның икенче почмагында ат скелеты ята. Сугыш аты булгандыр, күрәсең. Муен тирәсендә кылыч эзләре бар, баш сөяге ниндидер әйбер белән сугып тишелгән...

Монголлар Болгар иленең шул чордагы башкаласы Биләрне генә түгел, тагын бик күп шәһәрләрне һәм авылларны талыйлар, яндыралар. Биләр, Суар һәм тагын дистәләгән болгар калалары бөтенләй яшәүдән туктыйлар. Илгә кара кайгы-хәсрәт килә. Болгар дәүләте үзенең мөстәкыйльлеген югалта.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Монголлар һәм татарлар кемнәр алар? Европада татар исеме ничек тарала?
2. Кыскача гына болгарлар белән монголлар арасында 1223, 1229 һәм 1232 елларда булган бәрелешләр турында сөйләгез.
3. Безнең тарихыбызда 1236 елны ничек бәяләргә була?

19. УНИКЕ ЙОЛДЫЗ БУЛЫП...

Илбасарларга каршы халкыбыз көрәше бабаларыбыз хәтерендә тирән уелып калган. Бу батырлык риваятьләргә, дастаннарга, тарихи җырларга кереп киткән.

Аксубай районы, Яңа Үзи авылы янындагы урман эчендә Хуҗалар тавы дигән урын бар. Шул тауда борынгы заманнарда Мәрҗән исемле болгар шәһәре булган, ди. Анда Тырышмал Хуҗа исемле кеше хакимлек иткән. Тырышмал Хуҗаның берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе акыллы 12 кызы булган. Алар арасында Мәрҗән шәһәренең батыры Иштирәк баһадирның сөйгәне Нәркәс сылу да бар икән.

Бер вакыт Болгар илен яу баскан. Ул илнең башкаласы — Биләргә үк килеп җиткән һәм шәһәрне камап алган. Биләрне як-

ларга башка болгар шәһәрләреннән дә батырлар килгән. Иштирәк баһадир да үзенең дуслары белән дошманга каршы чыккан. Сугыш бик каты булган, бик күп батырлар башларын салганнар. Иштирәк баһадир белән өч батыр сугыша-сугыша Биләр янындагы Хуҗалар тавына менгән. Батырлар туган илләре өчен соңгы тамчы каннарына кадәр көрәшергә ант иткәннәр һәм, дошманнар өстенә ыргылып, тигезсез сугышта һәлак булганнар. Аларны шул тау башына җирләгәннәр.

Көрәшкә хатын-кызлар да кушылган. Алар арасында Тырышмал Хуҗаның 12 кызы да катнашкан. Әмма ләкин төп көчләр җиңелгән. Шуннан соң 12 кыз атларын Мәрҗәнгә таба борганнар. Яу барыбер алар артыннан калмаган, урман, алмагачлар эчендә утырган гүзәл Мәрҗәнгә хәтле килеп җиткән һәм шәһәрне көл иткән.

Ә Тырышмал Хуҗаны, аның 12 кызын тотып алып, Хуҗалар тавы янына китергәннәр. Монда дошман күзәтчелеге астында алар, яланаяк килеш көне-төне туфрак ташып, яңа бер тау өйгәннәр. Биек тау өелеп беткәч, дошманнар Хуҗаны һәм аның кызларын шул тау башына терелэй җиргә күммәкче булганнар. Шулчак кызлар унике йолдыз булып, күккә күтәрелгәннәр, ә Тырышмал Хуҗа үзе, таудан сикереп, елга суына әйләнеп, күздән югалган. Халык хәзер дә елга башы булган чишмәне изге санап, аңа табына, ә кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атап йөртә.

Икенче бер риваятьтә Болгар патшасы кызының батырлыгы хикәяләнә.

Ил өстенә дошман килә. Болгар шәһәрен алганда, Габдулла патша үзенең гаиләсе һәм якыннары белән шәһәрдәге бер таш манара эченә кереп биклән. Явыз Аксак Тимер, бу корылманы бүрәнәләр белән уратып алып, ут төртергә куша. Янгында патшаның кече кызыннан башка барысы да үлеп бетә. Бу патша кызы бөтен Болгар илендә иң чибәр һәм иң акыллы кыз була. Ул ак киемнән манара түбәсенә үк чыгып баса. Аксак Тимер аның көчле ялкыннан да курыкмыйча, батырларча басып торуына һәм искиткеч гүзәл булуына таң калып, шунда ук утны сүндерергә куша. Янгын тынгач, илбасар, бөтен кешегә ишетелерлек итеп, кызга эндәшә: «Син минем иң баш хатыным, йортның бизәге булырсың»,— ди. Әмма патша кызы, илбасарның хатыны булганчы, түбәнгә ташланып үлүне артыграк күрүне әйтә. Бу җаваптан котырынган Аксак Тимер, кызның әсирлектәге ике ир-ат туганын китертеп, күз алдында җәзалап үтерергә боера. Богауланган абыйларын күргәч, патша кызының йөзе агара. Әгәр туганнарыма иң шәп чаптар атларыгызны биреп, күз-

алдымда иреккә җибәрсәң генә хатының булырга ризалык белдерәм, ди ул илбасарга. Аксак Тимер кызның матурлыгыннан акылын җуеп, ничек булса да тизрәк аның ризалыгын алырга теләп, иң яхшы атларын бирә. Патша уллары, кыю сеңелләренә соңгы саубуллашу карашларын ташлап, атларына сикереп менәләр дә күздән югалалар. Ә болгар патшасының кызы башы белән аска, сүрелеп баручы янгынга ташлана.

Ике туган, Болгар иленең төньяк төбәкләренә барып җитеп, Казан шәһәренә нигез сала. Ә батырларча һәлак булган патша кызын халык бүген дә онытмый. Ул ташланып үлгән манара төбенә килеп, аның истәлегенә дога кыла.

Менә шулай, дуслар, дошманнарга каршы көрәштә ир-егетләр генә түгел, гүзәл кызлар да батырларча һәлак була. Менә шулай ирек яратучы, көчле рухлы була безнең халкыбыз.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Нәрсә ул риваять? Аларда тарих ничек тасвирлана?
2. Сез яшәгән шәһәр, авыл белән бәйләнешле, дошманнарга каршы көрәш турында риваятьләр юкмы? Әби, бабайларыгыздан сорашып белешегез. Булса — язып алып килегез.
3. Болгар кызларының батырлыгы нәрсәдә? Риваятьләрне әниләрегезгә, сеңелләрегезгә, дусларыгызга, эти-эниләрегезгә сөйләгез.

20. АЛТЫН УРДА — КЫПЧАК-БОЛГАР ИЛЕ

Идел болгарларын буйсындырганнан соң, Батый хан җитәкчелегендәге монгол гаскәрләре рус җирләренә басып керәләр. Кайчандыр бердәм һәм көчле дәүләтләр исәбендә йөргән Киев Русе 12—13 нче гасырларда дистәләгән мөстәкыйль кенәзлекләргә таркалып беткән була. Кенәзләр үзара дошманлашып яшәгәннәр, бер-берсе белән еш сугышып торганнар. Шунлыктан монголлар ул кенәзлекләрне аерым-аерым тар-мар итеп бетергәннәр. 1237 елда, беренчеләрдән булып, Рязань кенәзлеге җиңелә. Аннан соң бер-бер артлы Коломна, Мәскәү, Владимир, Суздаль, Кострома, Ярославль, Углич һәм башка шәһәрләр алына. 1240 елда Батый гаскәрләре Киевне озак кына камап торалар да бик көчле штурм белән басып алуга ирешәләр. Болгарларның Олуг шәһәрен (Биләрне) ничек талаган булсалар, Киевне дә шундый ук язмышка дучар итәләр.

Рус җирләрен бөлгенлеккә төшергәннән соң, монголлар Көнбатыш Европа халыкларын — полякларны, чехларны, венгрларны ба-

сып алмакчы булалар. Әмма бу хыялларын тормышка ашыра алмыйлар, чөнки болгарларга һәм русларга каршы биш елдан артык дәвам иткән берөзлексез сугышлар нәтиҗәсендә алар инде көчсезләнгән булалар. Шулай итеп, Идел болгарларының һәм русларның монголларга каршы каһарманнарча көрәше Европаны тар-мар ителүдән саклап кала, дип әйтә алабыз.

Басып алынган җирләрдә монголларның бик зур һәм көчле дәүләте үсеп чыга. Ул дәүләтне гадәттә Алтын Урда дип атыйлар. Чынлыкта исә «Алтын Урда» исеме 16 нчы гасырда гына, бу дәүләт инде яшәүдән туктап, шактый вакытлар узгач, барлыкка килгән. Заманында аны Җучи олысы (биләмәсе) дип йөрткәннәр. Җучи — ул Чыңгыз ханның олы улы. Чыңгыз хан үзе исән чакта ук яулап алынган җирләрнең бер өлешен — Балһаш күле һәм Арал диңгезе тирәсендәге, Иртыш белән Җаек елгалары арасындагы далаларны — олы улына бүлеп бирә. Көнчыгыш Европадагы моңарчы буйсындырылмаган җирләрне дә Җучига вәгъдә итеп калдыра. Бу җирләрне соңрак Җучиның улы Батый яулап ала һәм мөстәкыйль дәүләт төзи.

Җучи олысының чикләре, шулай итеп, көнчыгышта Иртыш елгасыннан башлап, көнбатышта Днестр, Дунай буйларына кадәр, төньякта рус, болгар, мордва, мари, удмурт җирләреннән алып, көньякта Арал, Каспий, Азов һәм Кара диңгез буйларына кадәр сузылган. Рус кенәзлекләре Җучи олысына кермәгән, алар ханга ел саен ясак кына түләп торганнар.

Җучи олысында күп төрле халыклар яшәгән. Алар күбесенчә терлек асрау белән шөгыльләнгәннәр. Утрак тормышта яшәүчеләре дә булган. Монголлар үзләре сан ягыннан азчылыкны тәшкил иткәннәр. Аларның бер өлеше тиздән туган якларына, гаиләләре янына кайтып киткән, икенчеләре исә, җирле кабиләләр белән кушылып, төркиләшеп беткәннәр.

Буйсындырылган халыклар арасында күпчелекне кыпчаклар тәшкил иткән. Замандашлары Җучи олысын, дөресрәге, Иделнең түбән өлешен һәм Идел аръягындагы көнбатыш өлкәләрен «Дәште Кыпчак» (Кыпчак даласы) дип йөрткәннәр. Соңрак нәкъ менә шушы җирләр Алтын Урда исеме белән аталган. Болгарлар да бит, кыпчаклар кебек үк, монголларга кадәр Урта Иделдә генә түгел, Түбән Иделдә дә (хәзерге Әстерхан, Волгоград, Саратов өлкәләре), Кырымда, Төньяк Кавказда, Урал буйларында һәм Себер якларында, ягъни булачак Алтын Урда территориясендә яшәгәннәр. Менә шуңа күрә дә Алтын Урданы икенче төрле итеп Кыпчак-Болгар иле дип атарга тулы нигез бар. Ләкин болгарлар утрак тормышлы буларак шәһәрләрдә яшә-

Алтын Урда һәм аның шәһәрләре.

гәннәр. Алтын Урданың төп халкын күчмә кабиләләр тәшкил иткән.

Тик ни генә булмасын, бу дәүләт монгол ханнары тарафыннан оештырыла. Монголлар исә Европада татарлар дип йөртелгәнлектән, Җучи олысының халкын да татарлар дип атаганнар. «Татар» атамасы тора-бара (моның өчен берничә гасыр вакыт үтә) болгарларга да күчә. Чынлыкта исә хәзерге Кырым татарлары, Әстерхан татарлары, Себер татарлары һәм Пермь татарлары, үзләренең туганнары — Идел татарлары кебек үк, чыгышлары белән һич тә монгол татарларына түгел, ә болгар-кыпчакларга бурычлы. Монголиядән килгән илбасарлар белән аларның бернинди уртаклыгы юк.

Алтын Урданың башкаласы Батый хан әмере белән махсус салдырылган Сарай шәһәре була. Аның хәрабәләре Әстерхан өлкәсендә саклана. Үз вакытында дөньяның иң зур һәм матур шәһәрләре рәтендә йөргән ул. Халкы 75 меңгә җиткән. Ибн Баттута исемле гарәп сәяхәтчесе язганча, Сарайны атка атланып әйләнеп чыгу өчен генә дә бер көн вакыт

кирәк булган. Шәһәр дистәләгән мәчетләре, шау-шулы базарлары белән дан тоткан. Биредә еш кына Ирак, Мисыр, Сирия, Һиндстан һәм башка дәүләтләрдән килгән бай сәүдәгәрләрне очратырга мөмкин булган. Алар кәрван-сарайларда яшәгәннәр. Сәүдә эше илнең икътисади тормышында иң күренекле урынны тоткан. Хакимлек итүче хан исеменнән көмеш һәм бакыр акчалар сугылган. Археологик казу эшләре вакытында алар күпләп табылалар.

Алтын Урда дәүләтендә Сарайдан башка шәһәрләр дә күп булган. Алар арасында Хаҗитархан (хәзерге Әстерхан), Укек (хәрабәләре хәзерге Саратов-Сарытау янында), Мохша (Пенза өлкәсендә), Маҗар (Ставрополь краенда), Аккирмән (хәзерге Белгород-Днестровский шәһәре, Кара диңгез буенда) аеруча билгеле. Бу шәһәрләрдә сәүдәгәрләрдән тыш меңнәрчә оста һөнәрчеләр яшәгән. Аларның күпчелеген Харәземнән, Идел Болгарстаныннан һәм рус кенәзлекләреннән китерелгән әсирләр тәшкил иткән. Алтын Урданың искиткеч югары үскән матди һәм рухи мәдәниятен тудыручылар монголлар түгел, ә буйсындырылган халык вәкилләре булган.

Идел Болгарстаны, монголлар тарафыннан яулап алынганнан соң, Алтын Урда составына керә. Болгарларның элеккеге җирләрендә Болгар һәм Җүкәтау кенәзлекләре барлыкка килә. Халыкның бер өлеше Кама аръягына, хәзерге Казан тирәләренә күчеп китә. Биредә мөстәкыйль Казан кенәзлеге оеша башлый.

Монголлар изүе астында булуга карамастан, Болгар иле 13 нче гасыр ахырында яңадан ныгый, күтәрелә башлый. Болгар, Җүкәтау, Кашан шәһәрләре күтәрелеш чорын кичерә. Алар эре сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләренә әвереләләр.

Шул ук вакытта дистәләгән шәһәрләр һәм авыллар хәрабә хәлендә калалар. Шунлыктан Болгар иленең монголлар хакимияте астында булу чорын һич кенә дә уңай яктан бәяләп булмый.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Монгол-татарлар ни өчен Европа илләрен яулап ала алмыйлар?
2. Җучи олысы һәм Алтын Урда нинди җирләрне биләп торган? Ни өчен Алтын Урданы икенче төрле Кыпчак-Болгар иле дип атарга була?
3. Алтын Урданың нинди шәһәрләрен беләсез? Аларның исемнәрен «Тарихи сүзлек»кә язып куегыз.
4. Алтын Урта чорында Идел Болгарстанында нинди үзгәрешләр булган?

21. ОЛУГ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ

Тын гына агып ятучы киң Иделнең сул ягында, текә яр буенда, Кама суы килеп кушыла торган җирдән 30 чакрымлап түбән төшкәч, ерактан ук ап-ак таш хәрабәләр күренеп тора. Шәһри Болгарның тарихи истәлекләре ул. Кыш үтеп, көннәр бераз җылытып җибәрүгә, илебезнең төрле төбәкләреннән бирегә төркем-төркем булып экскурсантлар агыла. Яшьләре дә, картлары да Шәһри Болгарны күрергә ашкына. Нindирәк шәһәр булган соң бу урында? Ничәмә-ничә йөз еллар үтүгә карамастан, ничек алай һаман халык күңелендә ул?

Болгар — 9 нчы-10 нчы гасыр чикләрендә барлыкка килгән борынгы шәһәр. Монгол яуларына кадәр үк ул Болгар илендә генә түгел, бөтен Көнчыгыш Европада әре сәүдә үзәге буларак таныла. Шул вакытлардагы дәүләтнең башкаласы Болгардан (Биләрдән) аермалы буларак, аны Тышкы Болгар дип йөрткәннәр булса кирәк. Гарәп сәяхәтчеләре аның турында, Тышкы Болгар кечкенә шәһәр һәм бары тик сәүдә үзәге буларак кына данлыклы, дип язганнар.

Монгол яуларыннан соң, Кече Чирмешән буендагы башкала Болгар-Биләр җимертелгәч, болгарларның яңа башкаласы элеккеге Тышкы Болгарга күчә. Тиздән ул Олуг Болгар дигән исем ала. Шәһәрнең чын мәгънәсендә гөрләп чәчәк ату торы 14 нче гасырга туры килә. Монголларга кадәрге чорда ул, шәһәр яны бистәләрен дә кертеп, 35—40 гектар мәйданны биләп торган. 14 нче гасыр башында исә Болгарның көчле ныгытмалар белән уратып алган мәйданы инде 380 гектарга җиткән.

Элек Болгар башлыча нык үскән сәүдә үзәге буларак танылган булса, хәзер инде ул һөнәрчелек үзәгенә дә әверелә. Шәһәрдә яңадан-яңа һөнәрчелек бистәләре калкып чыга. Бередә бигрәк тә чүлмәкчелек һөнәре алга китә. Кызыл балчыктан яхшы сыйфатлы савыт-сабалар, аеручa кувшиннар, аш савытлары, бала-чага уенчыклары һәм су торбалары ясаганнар. Болгар һөнәрчеләре арасында металл коючылар, тимерчеләр һәм бакырчылар югары осталыкка ирешкәннәр. Алар авыл халкы өчен күпләп сабан, төрән, урак, чалгы, шулай ук сугыш кораллары, йозак, кайчы, пычак һәм башка күп төрле әйберләр ясаганнар. Бронзадан һәм бакырдан матур итеп эшләнгән комганнар, казаннар, бизәнү әйберләре археологик казулар вакытында еш табылалар. Болгар осталары пыяладан, кыйммәтле металлардан һәм асылташлардан бик нәфис итеп муенсалар, алкалар, беләзекләр, йөзекләр, ә сөяктән пычак саплары, тараклар эшләгәннәр.

Шәһри Болгарның сәүдә үзәге



Олуг Болгар капкасы. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

буларак даны-шөһрәте тагын да арткан. Ул Европа һәм Азия илләре арасындагы су һәм кәрван юлларын үз кулларында тоткан. Рус кенәзлекләре, Урта Азия, Кавказ, Кытай, Һиндстан, Византия, Гарәбстан һәм башка илләр белән сату иткән. Чит ил сәүдәгәрләре дә алыш-биреш итү өчен Болгарга бик теләп йөргәннәр. Аларның бер өлеше озак вакытлар буе Болгарда яшәгән. Мәсәлән, шәһәр ныгытмаларыннан бераз арырак әрмәннәрнең 3 чакрымга сузылган сәүдә бистәсе урнашкан булган. Биредә археологлар «Грек пулаты» исеме белән йөртелә торган христиан гыйбадәтханәсенең хәра-



бәләрен тапканнар иде. Болгардан ерак түгел рус сәүдәгәрләре яши торган аерым бистә дә булган.

Болгар төзүчеләренең даны чит илләргә дә барып җиткән. Болгарда осталар кулы белән салынган 70 ләп бинаның хәрабәләрен әле 18 нче гасырда да күрергә мөмкин булган. Хәзерге көндә аларның бик азы гына сакланып калган. Кызганыч, әлбәттә. Игътибарсызлык һәм вакыт шәфкатьсезләр шул алар.

Ни генә булмасын, Болгарга килүче туристларның игътибарын иң беренче җәлеп итүче нәрсәләр — нәкъ менә шушы борынгы архитектура һәйкәлләре. Аларны эчке



Җәмигъ мәчет.

бер дулкынлану белән карамыйча мөмкин түгел. Ниндидер сихри тарту көче бар аларда. Күпне күргән халкыбыз тарихына, туган туфрагыбызга, изге җиребезгә тирән мәхәббәт хисләре уята алырлык мөкатдәс һәйкәлләребез алар! Әйдәгез, без дә кыскача гына танышып үтик бу истәлекләр белән.

Хан мәчете (Җәмигъ мәчет) башкаланың үзәк мәйданында 13 нче гасырның икенче яртысында төзелә. Ул башта буе 34, иңе 32 метрлы дүртпочмаклы таш бина рәвешендә булган. Алгы стенадагы гөмбәзле портал (төп ишеге) таштан чокып ясалган матур бизәкләр белән каймалап алынган. Шуның янына ук биеклеге 25 метрлы манара утыртып куйганнар. Берникадәр вакыт үткәч, 14 нче гасыр башында, мәчетнең һәр почмагын өстәмә рәвештә дүрт хәрби манара белән ныгытканнар. Шулай итеп, бу мәчет гыйбадәт кылу урыны да, бер үк вакытта дошманнан саклану урыны да булып хезмәт иткән.

Хан мәчете каршында 14 нче йөздә салынган таш төрбәләр дә (мавзолейлар) сакланып калган. Монда болгар патшаларының һәм югары катлау кешеләренең мәетләре күмелгән.

Кара пулат — Болгардагы 14 нче гасыр урталарында төзелгән биналарның иң хикмәтлеседер, мөгаен. Ул хәзер дә яхшы гына сакланган. Дүрт катлы бу таш корылманың түбәсе гөмбәз рәвешендә эшләнгән. Аскы катның күп өлеше инде җиргә сеңгән. Аның як-ягында кечкенә генә бүлмәләр булган. Икенче катның дүрт ягында да икешәр, ә көньяк стенасында өстәмә тәрәзәләр уелган. Өченче катта һәм сигез почмаклы итеп җиткерелгән дүртенче катның һәр ягында берәр тәрәзәсе бар.

Нинди корылма булган соң ул Кара пулат? Моны хәзер инде берәү дә тәгаен генә әйтә алмый. Риваятьләрдә, Кара пулат болгар ханының хөкем итү урыны булган, диелә. Хөкемне хан үзе һәм абруйлы аксакаллардан сайлап куелган өч казый чыгарган. Хөкем вакытында алар икенче катның гөмбәзле залына аерым ишекләрдән кергәннәр. Беренче катның тәбәнәк бүлмәләрендә хөкем ителгән кешеләрне ябып тотканнар.

Ак пулат әле узган гасырның 60 нчы елларына кадәр сакланып килгән. Аннан соң ул бөтенләй җимерелеп җир белән тигезләнгән. Археологлар аның бар кадәресен яңадан казып чыгардылар.

Ак пулат мунча булган. Аның үзәк өлеше 6 метр чамасы биеклектә булып, гөмбәз түбә белән капланган. Почмаклардагы янкормаларда биеклеге 4 метрга җитә

Кара пулат.

торган аерым бүлмәләр урнашкан. Бу янкормаларның да түбәсе гөмбәзсыман итеп эшләнгән. Бер бүлмәдә зур гына мич һәм кайнар су өчен казаннар урнаштырылган. Аннан юыну залына идән асты каналлары буйлап җылы һава, ә керамик торбалар буйлап су килгән. Юыну залына киенү-чишенү һәм ял итү өчен махсус бүлмәләр тоташкан. Идәнгә әйбәтләп таш плитәләр җәелгән, стеналары матур итеп штукатурланган.

Болгар мунчаларын юыну өчен генә түгел, үзенә бер төрле җыелу, ял итү урыны итеп тә файдалан-

Кече манара.

ганнар. Монда төрле әңгәмәләр уздырганнар, бәхәсләр куертканнар, шахмат-шашка уйнаганнар, тәмле ризык һәм эчемлекләр белән сыйланганнар.

Кече манара — Болгарның иң яхшы сакланган архитектура һәйкәле. Янындагы мәчет инде күптән җимерелеп беткән. Язмыш, күрәсең, аның мәһабәт манарасына гына миһербанлык күрсәткән. Хан мәчетенең Олы манарасыннан аермалы буларак, халык аны Кече манара дип атаган. Аның биеклеге 12 метр чамасы, 48 басмалы әйләнгеч таш баскыч өскә алып менә. Баскычны яктырту өчен стеналарда кечкенә генә тәрәзәләр уелган. Югарыдан Шәһри Болгар бигрәк тә матур булып күренә!

Кече манара янында элек ханнар зираты булган. Биредә әле хәзер дә «Хан төрбәсе» дип аталган мавзолей хәрабәләре саклана. Таш төрбә корылмалары — болгар бабаларыбызның каберләре өстенә куелган изге һәйкәлләр алар.

Шәһри Болгар истәлекләре турында бик озак сөйләп булыр иде. Халкыбызның бай тарихы чагыла аларда. Шуңа күрә дә кадерләп саклыйлар аларны. Ел саен өйрәнү эшләре алып баралар. Музейлар оештырылган. Эскурсиягә килегез Болгарга! Сезне шатланып каршы алырлар, истәлекле урыннарны күрсәтеп йөрерләр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Болгар шәһәре кайчан барлыкка килгән? Монгол яуларына кадәр ул ни белән данлыклы булган?
2. Алтын Урда чорында шәһәр һәм аның хуҗалыгы ничек үскән?
3. Шәһри Болгарның нинди архитектура һәйкәлләрен беләсез? Аларны кыскача гына тасвирлап сөйләгез.

22. АЛТЫН УРДА ҺӘМ БОЛГАР МӘДӘНИЯТЕ

Монгол яулары Болгар иленә гаять зур зыян китергән. Шактый күп шәһәр, авыллар җимерелгән. Элек җайга салынган һөнәрчелек, сәүдә, уку-укыту, дәүләт системасы тәмам бозылган. Мәҗүси монголлар ислам диненең, аның мәдәниятенең яшәешенә куркыныч тудырганнар. Бер гасырлап ил торгынлык кичергән. Бу вакытта иҗат иткән бер генә галимнең дә, язучының да исеме безгә билгеле түгел.

Еллар үткән. Яулап алучылар, шәһәрләр җимерүгә караганда, һөнәрчелек, сәүдә эше гөрләп торган шәһәрләрнең күбрәк һәм даими табыш китергәнен аңлаганнар. Борынгы бабаларыбызның фидакарь тырышлыгы белән шәһәр, авыллар аякка бастырылган, сәүдә юллары торгызылган. Болгар иленең нык үскән элеккеге мәдәнияте булмаса, алар алай тиз күтәрелә алмас иде. Анда яңа баштан тормыш гөрләи, остаханәләрдә чүкеч, пычкы, балта чыңы, базарларда сәүдә ыгы-зыгысы, мәчет-мәдрәсәләрдә изге Коръән укыган тавышлар ныграк ишетелә башлый.

Алтын Урда мәдәнияте — күчмә халык һәм шәһәр мәдәниятләре кушылмасы ул.

Болгар шәһәре Алтын Урданың беренче оешкан үзәгенә әйләнә. Аны олылап, Җучи ханнарының «Алтын тәхете» дип йөрткәннәр. Оешып килүче дәүләтнең беренче акча басу урыны да Болгарда була. Анда Алтын Урда ханнары исеменнән генә түгел, бөтен Монголия империясе хакимнәре исемнәре белән тәңкәләр басыла. Болгар акчалары — бик күп мәгълүмат бирә торган бер дөнья.

Акчаларны өйрәнә торган фәнне — нумизматика дип атыйлар. Болгар акчаларында яхшы теләкләр белән язылган гарәп язуларыннан тыш төрле тамгалар, җәнлек, кош-корт рәсемнәре дә күп. Алар арасында аеручы барс, ике башлы каракош рәсемнәренең күплеге күзгә ташлана.

Болгар һәм Сарай акчалары.

6 Ч-279



Йөгертмә бизәкле, гарәп язулы плиткалар.

Болгарда яңа Җәмигъ (үзәк) мәчет, мәхәллә мәчетләре, мәдрәсәләр, мунчалар һәм башка җәмәгать биналары төзелә. Аларга төсле күпертмә бизәкләр, сырлы-сырлы ташлар, чынаяк кирпечләр, түшәм һәм идәннәренә төрле-төрле пыяла, вак ташлар ябыштырылган. Урамнарда да ташлар җәелгән, сукмаклар түшәлгән. Үзәктән су бирү җайланмасы булган.

Элек-электән килгән мәдәният артык үзгәрешләр кичермичә дәвам иткән. Болгар иле Мисыр, Кытай, Урта Азия, Һиндстан, Иран, Көнбатыш Европа дәүләтләре белән тыгыз бәйләнештә булып, алар мәдәниятенең йогынтысы белән дә баеган. Болгарга төрле илләрдән һөнәрчеләр, дин белгечләре, галимнәр, шагыйрьләр агылган.

Болгар иле Урдага буйсынса да үзенең әүвәлге мөстәкыйльлеген сакларга тырыша. Болгар төньяк белән көньяк арасындагы сәүдә эшендә үзенең элеккеге арадашчылык ролен ныгыта. Озакламый, Урданың үзәге Түбән Иделдә төзелгән Сарай шәһәренә күчә. Әмма Болгар Сарай өчен күп яктан өлге, үрнәк булып кала. Сарайга бик күп һөнәрчеләр, төзүчеләр, галимнәр, шагыйрьләр күченеп китә. Алтын Урда шәһәрләрендә болгар һөнәрчеләре эшләгән көндәлек савыт-сабалар, хуҗалык кирәк-ярагы, бизәнү һәм башка көнкүреш әйберләрен еш очратырга була. Биналарны үзәктән, идән астыннан җылыту җайланмасы да Урда шәһәрләренә Болгардан керә. Шулай итеп, Алтын Урда мәдәниятен тудыруда Болгар әһәмиятле өлеш кертә. Болгар мәдәниятеннән башка Алтын Урда мәдәниятен күз алдына китерү дә кыен.

Монголлар борынгы бабаларының дине — мәҗүсилек белән яшәгәннәр. Үлгән бабаларының рухларына дога кылганнар. Җиз калайлардан сыннарын кисеп, аларга табынганнар. Андый сыннар Алтын Урда һәм Болгар шәһәрләрендә табыла.

Дөньяда иң зуры булып үскән бу дәүләткә абруйлы дин кабул итәргә кирәк була. Монда килеп, Византия, Русь православныйлары да, Италия католиклары да, будда монахлары да үз иманнарын мактыйлар. Әмма югары мәдәниятле Болгар, Хәрәзем, Кырым, Кавказ кебек ислам динен иман иткән төбәкләрнең булуы Урдада бу мәсьәләне ислам дине файдасына хәл итә.

Бәркә хан (1257—1266) тәхеткә утыргач, Кыпчак урдасы, кайчандыр болгарлар эшләгән кебек, Бохарадан рәсми рәвештә ислам динен кабул итә. Бу вакытта исламның үзәге Мисыр башкаласы Каһирәдә була. Анда Идел буеннан кол итеп китерелгән төрки халыклардан — башлыча кыпчак-болгарлардан — гаскәр оештырыла. Аларны мәмлүкләр (коллар) дип йөрткәннәр. Бер заман алар, Мисыр тәхетен яулап алып, үзләренең кешеләрен утырталар. 1262 елда Бәркә хан,

Кыпчак урдасының ислам динен кабул итүен хәбәр итеп, мәмлүкләр солтаны Бәйбарска илчеләр җибәрә.

Ислам дине аеруча Үзбәк хан хакимлек иткән вакытта (1312—1342) тамырын көчәйтә. Күпләгән мәчетләр, мәдрәсәләр салына. Шулай итеп, Алтын Урда югары мәдәнияткә ия булган ислам илләренә йөз тота. Шул чорның күренекле тарихчысы һәм сәяхәтчесе Ибн Гарәбшаһ болай дип яза: «Сарай шәһәре гыйлемнең һәм байлыкның бергә тупланган җиренә әверелде һәм кыска вакыт эчендә анда голәмәларның, олуг кешеләрнең, шагыйрь вә әдәбиятчыларның, осталарның һәм дә һәр төрле атаклы затларның мөхтәрәм төркеме җыйналды. Мисырның күп халыклы төбәкләрендә дә, аның авылларында да мондый хәлнең булганы булмады». Димәк, сәясәте һәм икътисады, фәне, мәгърифәте, мәдәнияте ягыннан Алтын Урда иң алда булган Мисырны да узып китә.

Илдә математика һәм астрономия, тарих һәм география, медицина, фәлсәфә, тел белеме кебек фәннәр алга китә. Алтын Урда мәдәниятен тудыруда, үстерүдә күп халыкларның вәкилләре катнаша. Шуны гына да әйтеп китү җитә: болгар, кыпчак укымышлылары Көнбатыш Европадан ике гасыр алда Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе, ерак йолдызларның һәркайсы үзе бер җиһан булуы, Галәмдә мәңгелек хәрәкәт яшәве хакында язып калдыралар.

Галим-голәмә генә түгел, гади халыктан да күпләр укый-яза белә. Кыпчак илендә башта уйгур язуы кулланыла. Ул өстән аска таба баганалап сулдан уңга таба язылган. Әмма ислам дине тамыр җәйгән саен гарәп язуы ныграк урнаша барган.

Алтын Урдада да гарәп язуына олы хөрмәт туа. Таш биналарның иң күренекле урыннары — гөмбәзләр, биек капка, ишек өсләре Коръәннең һәм Шәрык әдәбияты классикасының изге сүзләре белән бизәлгән. Гомумән, ул вакытта төрле савыт-сабаларга, тормыш кирәк-яракларына гарәп язулары төшерелгән. Шулай итеп, һәрчак игътибарны тартып, гарәп язулары кешеләрнең күз алдында торган.

Ул чакларда китапларны да кулдан күчереп язганнар. Бу күп вакытны сарыф итә торган мәшәкатьле эш булган. Моның өчен махсус кешеләр әзерләнгән. Алар каурый, камыш каләмнәр белән бик матур итеп язганнар. Шушы вакытта беренче мәртәбә корыч каләмнәр дә ясала башлаган. Гарәп хәрефе белән матур, дөрес итеп язу үзе бер сәнгать югарылыгына күтәрелгән.

Болгарлар үлгән кешеләрнең каберләренә таш кую гадәтен керткәннәр. Анда гарәп язуы белән Коръәннән өзекләр, күмелгән кешенең исеме, үлгән вакыты, теләк-

ләр язылган. Ташка уеп та, кабарынкы итеп тә язылган. Андагы язуларның, бизәкләрнең матурлыгына карап хәзер дә сокланасың. Аларның эчтәлеге дә матур булган. Менә 1317 елда вафат булган кешенең кабер ташы язмасыннан юллар:

Егетләр күрке, күңелләр үзәге,
Галимнәрне хөрмәтләгән, ятим, тол,
Үксезләрне асраган Муса углы

Алтынчы Шаһидулла зиараты торыр.

Шаһидулла, димәк, егетләрнең иң күренеклесе, гыйлемлелекне яратучы, кешеләргә ярдәмчел, үзе оста куллы, алтыннан төрле бизәнү әйберләре ясаучы кеше булган.

Алтын Урдада бик күп төрки халыклар берләшә: болгарлар, угызлар, башкортлар, каракалпаклар һ. б. халыклар. Ә кыпчаклар, болгарлар барыннан да күбрәк булганнар. Озак та үтми, кыпчак теле дәүләт, әдәбият теленә әверелә. Барча төрки халыкларның теле бер-берсенә бик нык якыная, тәрҗемәсез дә аңлашыла башлый.

Бу чор мәдәниятенең иң нык үсешкә ирешкән өлкәсе әдәбият була. Төрки телдә моңарчы күрелмәгән матурлыктагы шигырьләр, поэмалар, хикәяләр иҗат ителә. Шулардан Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки», Мәхмүд Болгари «Нәһҗел-фәрадис» (1358 ел), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1358 ел), Хөсам Кятибның «Җөм-



Язулы кабер ташы.



XIV гасырдагы язулы алтын болгар беләзеге.

җөмә солтан» (1370 ел), Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342 ел) әсәрләрен без бүген дә сокланып укыйбыз. Бу әсәрләрдә төркиләр иленә дан җырлана, аларда тугрылылык, кешелеклелек, намуслылык сабагы бирелә.

Кыпчак урдасы мәдәнияте — бик күп төрки халыкларының уртак мирасы ул.

23. АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАРКАЛУЫ. ИДЕГӘЙ

14 нче гасырның икенче яртысы Алтын Урда өчен авыр сынау еллары булып әверелә. Бердәм һәм куәтле империядә югары катлау феодаллары арасында бөек тәхет өчен көрәш башлана, әледән-әле фетнәләр кабынып тора.

Алтын Урда өстенә берьюлы әллә никадәр бәла-каза килә. Башта һич көтмәгәндә чума эпидемиясе килеп чыга, шәһәрләрдә, күп кенә төбәкләрдә меңнәрчә халыкны кырып китә. Аннан соң берничә ел тоташтан корылык була. Сәүдә элемтәләре бөтенләй өзелү дәрәҗәсенә килә, базарларга ерак чит илләрдән товарлар китерү туктала. Һөнәрчеләр дә авыр хәлдә кала, алар ясаган әйберләрне сатып алучылар кими. Әмма сугыш коралларына ихтыяҗ бетми. Ук-җәя, кылыч, сөңге, сугыш балталары базарда һаман сатыла тора.

Икътисади тормыштагы торгынлык мәдәният өлкәсендә дә нык сизелә. Әдәбият, сәнгатьтәге күтәрелеш сүрелә. Шәһәрләрдә яңа мәчетләр, кәрван-сарайлар төзү азая. Аның каравы кайбер шәһәрләр, дошманнар һөҗүменнән саклану өчен, крепость-ныгытмалар белән уратып алына.

Феодалларның үзара ызгыш-талашы илгә зур зыян китерә. Алар үзләренең биләмәләрен арттырыр өчен еш кына күршеләренең җирләренә яу чабалар, кешеләрен кырып, малларын талап алып китәләр. Урта хәлле феодалларга кадәр, ханнар хакимиятен танымыйча, үз олыслары белән мөстәкыйль идарә итәргә омтылалар.

Алтын Урда чорында сугышу ысулы. *М. Горелик рәсеме.*

Боларның барысы да Алтын Урдада хан идарәсенең көчсезләнүенә китерә. Җан тынычлыгын бозу, төрле сүз йөртү, фетнә чыгару юлы белән бөек хан тәхетенә үз кешеләрен утыртырга омтылучы аксөяк феодаллар күбәя. Шундый астыртын көрәш егерме ел чамасы дәвам итә.

Алтын Урданың көчсезләнүе аның кул астында яшәүче халыкларның баш күтәрүенә китерә. Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович (соңрак ул Донской исеме белән танылa), рус кенәзлекләрен бергә туплап, үзенә мөстәкыйльлек яуларга омтыла.

Алтын Урдадагы хәлләрне күрше илләрдә дә игътибар белән күзәтеп баралар. Алар монгол ханнарының кул астындагы җирләрне үзләренә тартып алу өчен уңай очракны сагалап торалар. Шул чакны Урданың эчке эшләре белән Урта Азиянең хакиме Аксак Тимер ныграк кызыксынуын сиздертә. Башта ул Алтын Урда ханының Туктамыш исемле улын үз канаты астына ала.

Урданың күпчелек феодаллары һәм халкы Туктамышны шатланып каршы алалар. Алар, яңа хан үзара ызгыш-талашларга чик куяр һәм илдә тәртип урнаштырыр, дип өметләнәләр. Әмма Туктамыш үзенең төп көчен яңа биләмәләр яулап алуга, күршеләрен талауга юнәлтә. Ул Мәскәүгә кадәр барып җитә, аны ала һәм яндыра. Аннан кайткач, үзенең элеккеге остазы һәм теләктәше Аксак Тимергә каршы күтәрелә.

Туктамыш Урта Азиянең күп кенә шәһәрләрен талый, яңа җирләр яулый. Ләкин Аксак Тимер нык каршы тора, ахыр чиктә Туктамышны җиңеп, үзе дә Алтын Урдага үтеп керә. Тиздән ул Иделгә кадәр килеп җитә. Кондырча елгасы буенда булган сугышта Туктамыш гаскәрен тар-мар китерә. Берничә елдан соң Аксак Тимер, зур көч туплап, яңадан яуга чыга. Ул Алтын Урданы бөтенләй юк итмәкче була. Идел буена үтеп, Аксак Тимер Сарай, Хаҗитархан, Үкек шәһәрләрен яндырып-җимереп юкка чыгара.

Кыпчак далаларында шул чакны бу дәүләтнең элеккеге данын яңадан кайтарырга сәләтле бер кеше табыла. Ул — Идегәй була. Идегәй яшьли үк күп сугышларда катнаша, үзен акыллы, кыю һәм бик оста батыр итеп таныта.

Яшь Туктамыш, Аксак Тимер яклы булып, Алтын Урданы даулап басып кергән чакта, Идегәй инде танылган хәрби җитәкче була. Тик бер кайчан да алар арасында дуслык туа алмый. Аксак Тимер 1391 елда Туктамышны беренче тапкыр җиңгәч, Идегәй, ногайларны һәм мангытларны туплап, үзенең мөстәкыйль олысын төзи. Ә инде Туктамыш бөтенләй тар-мар ителгәч, хакимлекне үз кулына алып, Алтын Урданы яңадан торгызуга керешә.

Ләкин Идегәйнең дошманнары

җиңел генә бирелергә теләми. Туктамыш, ярдәм сорап, Литва кенәзе Витовт янына чаба.

1399 елның җәе. Гаять зур гаскәр туплап килгән Витовт, Идегәй сугышчылары каршысына чыгып, аларны бирелергә, Туктамышның хакимиятен танырга чакыра. Идегәй бу тәкъдимне кискен рәвештә кире кага.

Быргы тавышы яңгырый. Барабан кага башлыйлар. Литвалылар ягыннан туплар атарга керешә, уклар оча. Атлы сугышчылар ябырылып ташлана. Витовтның полклары Идегәй гаскәрләрен кысрыклыйлар. Идегәй менә-менә җиңелер кебек. Әмма көтмәгәндә урдалыларның яңа көчләре пәйда була. Литвалылар куркып калалар һәм чигенә башлыйлар. Идегәй алар артыннан ташлана...

Идегәй Алтын Урда белән ун еллап идарә итә. Илне аякка бастыру өчен ул игелекле эшләр башкара. Шуңа күрә халык аны үзенең каһарманы итеп саный, ватандарлыгы һәм батырлыгы өчен тирән хөрмәт итә. Әмма ләкин Идегәй чыңгызлылар нәселеннән булмаганга күрә хан булып тәхеткә утыра алмый. Хокукы булмый. Шуңа күрә тәхет өчен даулашу бер минутка да тукталып тормый. Бу көрәштә Туктамышның уллары бик актив катнашалар. Идегәйнең аларга каршы көрәше фаҗигале төстә тәмамлана: 1420 елда ул үтерелә.

Батырлар бәйгесе.

Алтын Урданың таркалуын халык нәкъ менә Идегәйнең һәлак булуы белән бәйли:

— Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде...
Кырым, Казан, Әстерхан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Алтын Урда ни өчен таркала?
2. Туктамыш хан, Аксак Тимер, Идегәй. Бу шәхесләрнең Алтын Урда тарихында тоткан урыны турында сөйләгез.
3. Ни өчен Идегәй халык хәтерендә озак саклана? «Идегәй» дастаны турында ниләр беләсез?

24. ТАТАР ХАНЛЫКЛАРЫ

Идегәй һәлак булганнан соң берничә ел үтә. Алтын Урда танымаслык хәлгә төшә. Аны элеккеге кебек үзәкләштерелгән куәтле дәүләт дип булмый инде. Рус кенәзлекләре, Болгар иле үзләренең мөстәкыйльлекләрен яңадан кайтарып алырга ашыгалар. Далага сибелеп утырган күп санлы күчмә халыклар, жучилар хакимлегеннән котылып, аерым олысларга таркалалар. Шәһәрләр бетүгә, җимерелүгә йөз тота. Һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр Кырымга, Урта Азиягә, Болгар иленә — Казанга таралышып бетәләр. Шулай итеп, иксез-чиксез далаларда хуҗа булып, терлек асраучы күчмә урдалар гына кала. Тик аларга тынычлык килми. Феодалларның олуг хан тәхете өчен көрәше Идегәйдән соң да дәвам итә. Алтын Урданың соңгы ханы Әхмәт, Мәскәүне яңадан буйсындырмакчы булып, 1480 елда яуга чыккан җиреннән оятка калып кайта. Каршысына чыгып баскан көчле рус гаскәрләреннән куркып, сугыш башларга җөрьәт итмичә, ул кире чигенә. Руслар, ниһаять, Урдага ясак түләп торудан туктыйлар. Казан, Кырым, Әстерхан дәүләтләре дә мөстәкыйльлек алган булалар.

Шушы вакыйгалардан соң Алтын Урда бербөтен дәүләт буларак яшәвен тәмамлый.

Ногай урдасы Идел буе һәм Көньяк Урал далаларында оешкан. Аның башкаласы Җаек елгасы буендагы Сарайчык шәһәренә урнаша. Урданың төп халкын төрки телдә сөйләшүче күчмә кабиләләр тәшкил иткән. 16 нчы гасыр башында ул бик куәтле дәүләт берләшмәсе була. Ногай морзалары еш кына күршеләренә — Кырымга, Кавказга, хәтта Мәскәүгә дә яу чапканнар. Алар бигрәк тә Казанда һәм Әстерханда көчле йогынтыларын саклыйлар.

Әмирләр һәм морзалар арасында татулык булмау сәбәпле Ногай урдасы тиздән тагын да ваграк олысларга таркала. Бу олысларның бер өлеше соңрак Рус дәүләте тарафыннан яулап алына, икенче өлеше Кырым ханлыгына кушыла.

Әстерхан ханлыгы 1459 елдан мөстәкыйль яши башлый. Ул кечкенә территория биләгән. Аның төп биләмәләре Иделнең түбән агымында (хәзерге Әстерхан шәһәре янында) була. Әстерхан мөһим сәүдә юлы өстендә урнашкан, бу аның шактый гына үсүенә, баюына китергән. Халкы башлыча сәүдә эшләре белән шөгыльләнгән, күршеләре белән тынычлыкта яшәүне хуп күргән, сугыш эшенә артык әһәмият итмәгән. 1556 елда ул Рус дәүләте тарафыннан яулап алынган.

Кырым ханлыгы башкалардан алдарак барлыкка килә. Аны Туктамыш хан нәселеннән булган кешеләр төзи. 1425 елдан башлап

Ногайлар Әстерхан янында. *А. Олеарий рәсеме.*

Гәрәйләр династиясе хакимлек урнаштыра.

Ханлыкның башкаласы Бахчасарай шәһәре була. Азак (Азов), Кафа (Феодосия), Судак, Аккирмән (Белгород-Днестровский) кебек шәһәрләр дә дәүләтнең икътисади тормышында әһәмиятле урын тоталар. Аларда сәүдә һәм һөнәрчелек алга китә. Бизәнү әйберләре һәм сугыш кораллары ясаучы осталар базар тоталар. Кырым ислам һәм төрки мәдәниятенең көчле үзәгенә әйләнә. Биредә бөтен төрки дөньясына танылган мәдрәсәләр ачыла.

Дала киңлекләрендә яшәүче халыкның төп өлешен күчмә терлекчеләр тәшкил иткән. Аларның төп байлыгы ат булган.

Кырым ханлыгы белән күрше дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр еш кына киеренкелеккә барып җиткән. Кырымлылар төрле сәбәпләр белән Руска, Литвага һөҗүмнәр ясап торганнар, шәһәрләрен яндырганнар, кешеләрен әсир алганнар. Кырым ханнары берничә мәртәбә Мәскәүгә кадәр барып җиткәннәр.

16 нчы гасырда Кырым ханлыгы, өрәзлексез сугышып тору нәтиҗәсендә шактый көчсезләнеп, Төркия дәүләтенә бәйлелеккә эләгә, әмма үзенең тулы мөстәкыйльлеген барыбер 18 нче гасырга кадәр югалтмый. 18 нче гасырның ахырында Кырым ханлыгы Россия империясе тарафыннан яулап алына.

Кырым сугышчылары.
С. Герберштейн китабыннан.

Жучи олысының көнчыгыш биләмәләрендә 15 нче гасыр ахырында **Себер ханлыгы** оеша. Ул Иртеш, Обь, Тобол елгалары буенда яшәгән төрки халыкларны берләштерә. Аның башкаласы хәзерге Тобол шәһәреннән ерак түгел урнашкан Кашлык шәһәре була. Себернең иксез-чиксез киңлекләренә шәһәр һөнәрчелеге һәм ислам мәдәнияте үтеп керә башлый. Бу якларга — төрки кабиләләр арасына — еш кына болгар сәүдәгәрләре дә килеп йөргәннәр. Болгарларны Себер якларында да үз иткәннәр.

Әмма Рус дәүләте көчәйгән саен, аның күрше халыкларны басып алуга йөз тоткан куркыныч сәясәте активлаша барган. Ике дистә еллар тирәсе русларга каршылык күрсәткәннән соң, Күчүм исемле соңгы Себер ханы җиңелә. 16 нчы гасырның ахырында Себер ханлыгы тулаем Рус империясе составына кертелә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Алтын Урда һәм аннан соңгы ханлыкларда яшәгән халыкларның берсе дә бу якларга монголлар белән бергә килеп утырмаган. Алар бу төбәкләрдә монголларга кадәр күп элек яшәгән булганнар. Үзләре яши торган җирнең табигать шартларына яраклашып, алар башлыча мал-туар асрап көн иткәннәр. Барысы да бер-берсенә якын төрки телдә сөйләшкән.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Алтын Урда таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән ханлыклар турында нәрсәләр беләсез? Алар турында кыскача гына хикәя төзегез.
2. Бу ханлыкларда нинди халыклар яшәгән? Ни өчен алар барысы да бер исем белән аталган?
3. Татар ханлыкларының язмышы ничек була?

ӨЧЕНЧЕ
БҮЛЕК

КАЗАН ХАНЛЫГЫ

25. КАЗАН ХАНЛЫГЫ НИЧЕК БАРЛЫККА КИЛГӘН?

13 нче гасырның икенче яртысыннан башлап, ягъни Алтын Урда чорында, Болгар иле мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктый. Шулай да Болгар һәм Җүкәтау әмирләре монгол ханнарының рөхсәтеннән башка берни дә эшли алмаганнар икән, дип әйтү дә дөрес булмас. Болгарлар — тыныч холыклы халык — сугышып йөрергә яратмаганнар. Монголлар изүе астында яшәгәндә дә тыныч хезмәтне артык күргәннәр. Игенчелек һәм терлекчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә итешү аларның төп тормыш шөгыле булган.

Алтын Урдада хан тәхете өчен ызгыш-талашлар башлангач, болгарлар яши торган төбәкләрдә дә тынычлык бетә. Әледән әле руслар яу белән киләләр, шәһәр һәм авылларны талап китәләр. Алтын Урдадан тәхет өчен барган сугышларда җиңелгән бәкләр бирегә хәл алу, көч туплау өчен киләләр. Мондый шартларга түзә алмаган җирле халык әкренләп төньяк районнарга күченеп утыра башлый. Болгар иленең кайчандыр чәчәк атып утырган төбәкләре бушап кала. 1431 елда Мәскәү кенәзе Федор Пестрый Болгарны һәм Җүкәтауны талап, тәмам җимереп, юк итеп китә. Бу шәһәрләрдән кызганыч хәрабәләр генә кала.

Болгарның элеккеге даны торабара Казанга күчә. Дөрес, Казан күптән инде Каманың аръягыннан күченеп килгән болгарларны берләштерүче эре үзәккә әверелгән була. 15 нче гасыр башында бөтен Болгар илендә бердәнбер зур һәм яхшылап ныгытылган шәһәр булып Казан күтәрелеп чыга. Болгарлар алдында тагын мөстәкыйль дәүләт төзү мөмкинлеге ачыла.

* * *

Алтын Урда тәхете өчен көрәштә көндәшләре тарафыннан җиңелгәч, Олуг Мөхәммәт Мәскәү җиренә китә. Олуг Мөхәммәт һәм аның уллары русларга каршы берничә уңышлы яу оештыра. **Тиздән алар Түбән Новгородны һәм Муромны кулга төшерәләр. Аларның ниятләренә комачаулау өчен Василий II өстәмә отрядлар** оештыра. Бу ике гаскәр Суздаль янында очраша.



Казан җирләре картасы. Кол Шәриф мәчете күренеше. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

Мәскәү воеводалары һәм олуг кенәз, гаскәрләренең саны күплегеннән масаеп, курыкмыйча сугышка ташланалар. Ләкин Алтын Урда отрядлары, аз санлы булсалар да, яхшырак сугышалар, көтелмәгән җирләрдә кинәт һөҗүмгә күтәрелеп, русларны тәмам хәлдән тайдыралар. Мәскәүлеләрнең бер өлеше кача, икенче өлеше әсирлеккә эләгә. Әсирләр арасында олуг кенәз Василий II үзе дә була. Аны зур йолым түләү бәрабәренә кире кайтарып җибәрәләр.

Шуннан соң Олуг Мөхәммәтнең улы Мәхмүт 1445 елда Казанны ала һәм, аның патшасы Галимбәкне үтереп, үзе ханлык итә башлый. Димәк, Казан дәүләте бу бәрелешләргә кадәр үк яшәгән була.

Ниһаять, Мәскәү белән Казан арасында егерме ел чамасы тынычлык яши. Бу чор Рус дәүләтенең Мәскәү тирәсенә ныграк берләшүе һәм Казан ханлыгының тәмам оешып җитүе өчен бик кирәкле вакыт була. Мәскәү белән Казанның вакытлыча гына булса да үзара якынлашуына тагын бер сәбәп чыга. Үлеп баручы Алтын Урдага каршы алар икесе дә бер дәрәҗәдә каршы көрәшкә чыккан була.

Ләкин 1460 еллардан соң алар

Казан сугышчысы.
С. Герберштейн рәсеме.

арасындагы мөгамәләләр тагын бозыла. Мәхмүт хан үлгәннән соң Казан тәхете өчен төрле кешеләр арасында көрәш башлана. Казанның югары катлау кешеләре ике төркемгә бүленәләр. Аларның берсе Мәскәү кенәзеннән, икенчесе Ногай морзаларыннан яклау һәм ярдәм көтә. Бердәмлек булмагач, ханлыкның эчке эшләренә гадәттәгечә күрше дәүләтләрнең тыкшына башлавы бер дә гаҗәп булмый.

1467 елда Олуг Мөхәммәтнең Мәскәү кенәзендә хезмәттә торучы улы Касыйм хан Казанны үз кулына алырга омтылып карый. Алдан ук Казан феодалларының кайберләре белән сөйләшеп, аларның ярдәм итәргә вәгъдә бирүенә таянып, Касыйм Рус гаскәрен шәһәр диварлары янына алып килә. Ләкин коралланган халык, бердәм булып, чакырылмаган кунакны каршы алырга чыга. Мәскәү — Касыйм атлы гаскәре, һөҗүмгә түзә алмыйча, качып китә.

Моңа җавап итеп, Казанның яңа ханы Ибраһим Рус дәүләтенә яу белән бара. Мәскәүнең яңа патшасы Иван III дә Казанны үзе кулга төшермәкче була. Шул максат белән ул үзенең гаскәрләрен, ике яклап: югарыдан — Идел һәм түбәннән — Кама буйлап барып, Казанны яулап алырга җибәрә. Бу рәвешле шәһәрне камап алу планы, бәхеткә каршы, барып чыкмый. Мәскәү ягыннан килгән төп гаскәрләр яшеренеп кенә шәһәргә якынлашалар һәм аңа бәреп тә керәләр. Әмма Кама ягыннан килүче гаскәрләрне казанлылар юк итәләр. Сугыш ахыр чиктә русларның җиңелүе белән тәмамлана.

1469 елда рус патшасы, яңадан гаять зур гаскәр туплап, Казанга җибәрә. Шәһәрне озак кына камалышта тоталар, ләкин Казан барыбер бирелми. Бу сугыш ике арада солых төзү белән бетә. Солыхны егерме еллар чамасы бер яктан да бозарга батырчылык итмиләр. Ике дәүләттә дә төрле вакыйгалар булып тора, ә килешү тотрыклы булып кала бирә. Моның сәбәбе — Казан ханлыгының көчәюендә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Казан ханлыгының барлыкка килүендә җирле шартларның роле нинди?
2. Казан ханлыгының төп халкын кемнәр тәшкил иткән?
3. Сез «Казан ханлыгы — Алтын Урданың бер кисәге» дигән фикер белән килешәсезме?

26. «БӨЕК ҺӘМ ГҮЗӘЛ ИЛ»

(«Идегәй» дастаны)

Казан ханлыгы үз вакытында Көнчыгыш Европаның көчле һәм алдынгы дәүләтләреннән санала. Аның территориясе көнчыгышта Агыйдел буйларыннан башланып, көнбатышта Сура елгасына кадәр, төньякта Каманың югары агымыннан алып, көньякта Чирмешән елгасына кадәр булган җирләрне берләштергән. Бу җирләрдә яшәгән халыкларның күпчелеген элек-электән үк болгарлар тәшкил иткән. Шуңа күрә Казан ханлыгы, чынлыкта, болгарлар иле ул. Тәхетне Алтын Урдадан килгән хан тартып алган дип кенә Болгарстанның төп һәм берданбер варисы булган дәүләтебезне килмешәк монголлар нәселе белән бәйләү зур хата булыр иде. Бу вакытта болгарлар кыпчаклар белән ныклап кушылган булалар инде.

Казан ханлыгына кергән җирләрдә болгарлардан кала чирмешләр (марилар), арлар (удмуртлар), чувашлар һәм мордвалар да яшәгән. Эре шәһәрләр күп булмаган. Алар арасында Казаннан кала Арча, Лаеш, Тәтеш, Чаллы, Сембер кебек шәһәрләрне аерып күрсәтергә мөмкин.

Җирле халыкның күп өлеше авылларда яшәгән һәм игенчелек белән шөгыльләнгән. Бу аларның элек-электәнге изге эше саналган. Алар уңдырышлы җирләрне кирәгенчә эшкәртеп, мул уңыш үстерә белгәннәр һәм үзләреннән калган ашлыкны читкә чыгарып сатканнар. Башта Болгар, соңрак Казан халкы икмәк игүче осталар буларак дан тотканнар. Авылларда шулай ук күпләп кош-корт, мал асраганнар, нәселле атлар үрчеткәннәр.

Һөнәрчелек шәһәрләрдә болгар бабаларыбыздан ук килгән. 15—16 нчы гасырларда, Казан ханлыгы чорында, ул тагын да алга китә. Металл кою, алтын-көмештән, асылташлардан бизәнү әйберләре ясау, эш һәм сугыш кораллары, тормыш-көнкүреш әйберләре әзерләү нык үсә. Болгарлар чорыннан ук башлап халкыбызның матди тормышында зур урын тоткан һөнәрчелек тармаклары бар. Алар арасында чүлмәкчелек эшен — балчыктан матур һәм чыдам савыт-саба ясауны — аерып әйтергә кирәк. Формалары белән гаҗәеп камил һәм күптөрле, зәвык белән



16 нчы гасырдагы Казан күренеше. *Н. Калинин рәсеме.*

бизәлгән савытларны һәркайда яратып сатып ала торган булганнар.

Казан халкы эшләгән тире-күн әйберләре тирә-якны таң калдырган. Атаклы Арча читекләре — безгә бабаларыбыздан мирас булып күчкән һөнәрнең бүгенге көндә дә онытылмыйча саклануына бер дәлил.

Казан дәүләтендә шәһәр архитектурасы, ягъни агач һәм таш-кирпечтән йортлар, җәмәгать биналары (мәчетләр, мәдрәсәләр, кибет-базар, мунчалар), төрле хәрби ныгытмалар салу эше дә югары дәрәҗәдә торган. Казан каласында, тау башында, балкып утыручы мәчетләрнең кызыл кирпечтән салынган биек мәһабәт манаралары әллә кайлардан ук күренеп торган. Хан сараеның, мәчетләрнең ишекләре, ян-як стеналары таштан кисеп бик нәфис итеп ясалган үсемлек сурәтләре белән бизәлгән булган. Зиратлардагы кабер ташлары да, чын сәнгать әсәрләре кебек, нечкә зәвык белән җиренә җиткереп эшләнгән. Гарәп хәрефләре белән матур итеп язылган язуларына хәзер дә сокланмый мөмкин түгел!

Казан ханлыгы чорында күрше һәм ерак илләр белән сәүдә итешү бик абруйлы һәм мактаулы эш саналган. Сәүдәнең нигезен нык үскән авыл хуҗалыгы (игенчелек, терлекчелек) һәм һөнәрчелек әйберләре тәшкил иткән. Шул заман кешеләре язганча, Казан ярминкәләренә руслардан гына да 15 меңләп сәүдәгәр килә торган булган. Биредә сатарга һәм сатып алырга күп мөмкинлекләр булган дигән сүз.

Казан ханлыгы белән иң бай һәм абруйлы кеше — хан идарә иткән. Ул үзенең эшләрен әмир-би-



Билбау өчен алтын бизәкләр.

ләрне берләштергән махсус дәүләт органы — «диван» белән киңәшләшеп башкара торган булган. Бу диванга керә торган әмирләр дәүләтнең казнасы, гаскәрләре белән идарә иткәннәр. Шуңа күрә илдә ханнарның хакимияте чиксез булмаган. Аеруча мөһим эшләрне хәл итәргә кирәк булганда илдәге барлык югары катлау кешеләрен чакырып корылтай үткәргәннәр. Анда кабул ителгән карар хан өчен дә, диван өчен дә мәҗбүри булган.

Югары катлау кешеләре — әмирләр, биләр, морзалар һәм угланнар — дәрәҗәләренә карап, төрле күләмдә җир биләмәләре тотканнар. Шул биләмәләрдә яшәүче гади халыктан алар салым түләтеп торганнар. Гади халык сугышларда да катнашкан. Яуга алар үз атлары һәм сугыш кораллары белән барганнар. Мылтык һәм туплар белән коралланган махсус гаскәри отрядлар да булган.

Казан ханлыгында төп халык булып, хезмәтчел игенчеләр һәм шәһәр һөнәрчеләре яшәгәннәр. Дәүләтнең бөтен байлыгы — сугышып-талап җыелган түгел, ә гади хезмәт кешесенең тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән байлык булган.

Сөңге очы. 16 нчы гасыр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Казан ханлыгы нинди җирләрне биләп торган? Анда нинди шәһәрләр булган?
2. Хуҗалык тормышында игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә эше нинди урын тоткан?
3. Казан ханлыгында нинди катлау кешеләре яшәгән?

27. «КАПКАСЫ БИЕК ТАШ КАЗАН»

(«Идегәй» дастаны)

Казанның ерак гасырларга илтә торган олы тарихы бар. Борынгы кешеләрнең беренчел торулыклары биредә таш гасыры чорында ук барлыкка килгән. Бронза чорында һәм тимер гасырның элгәреге дәверендә дә булачак шәһәр территориясендә кешеләр яшәгән.

Шулай да чын шәһәрнең барлыкка килүе 12 нче гасырга гына карый һәм ул болгарлар белән бәйләнгән. Халкыбыз риваятьләрендә әйтелгәнчә, бу җирләргә башта болгар патшасы килеп чыга һәм аның урынын, табигатен бик ошатып, кала төзергә боера. Тик кала салынасы урында еланнар күп булган, имеш. Аларны куып җибәргәннән соң, 1177 елда, ниһаять, Казанга нигез салына.

Шәһәрнең барлыкка килү вакытын соңгы елларда үткәрелгән археологик казулар да ачык расладылар — һичшиксез, монголларга кадәрге чор! Дөрес, 12 нче гасырда ул әле кечкенә крепость (кальга) формасында гына була. Шул вакыттан ук ул ак таштан салынган диварлар һәм биек манаралар белән уратып алына, Идел Болгарстанының иң төньяк чикләрен саклый торган крепость рәвешендә төзелә.

Монголлар явыннан соң бу кала зур булмаган болгар кенәзлегенең үзәгенә әйләнә. Шәһри Болгар 1431 елда руслар тарафыннан җимерелгәннән соң, аның башкала буларак вазифасы һәм дәрәҗәсе Казанга күчә. Моны шул вакытларда сугылган Казан акчалары да раслый. Аларда «Болгар әл Җәдид» — Яңа Болгар дип язылган сүзләр бар.

14—15 нче гасырларда Казан тиз үсә, хуҗалыгы ныгый, болгар халкын яңа шартларда берләштерүче үзәк булып танылa.

Алтын Урда таркалган чорда кайбер ханнарның Казанга качуы да юкка гына булмый, әлбәттә. Урта Иделдә Болгар иленең яңа башкаласы булып куәтле шәһәр — Казан каласы — күтәрелә.

Шәһәрнең тау башына урнашкан биек стеналы кремле һәм аның көчле ныгытмалары, зиннәтле хан сарае, мәчетләре, мәдрәсә биналары, хан зиратындагы төрбәләр — барысы да уртак бер рух белән



Казанда хан сарае. *Н. Калинин рәсеме.*

эшләнгән. Сигез манаралы Кол Шәриф мәчете үзе ни тора! Ул әмир, морзаларның, бай сәүдәгәрләрнең берничә катлы биек таш йортлары. Һәркайсы борынгы заман архитектурасы үрнәге булырлык.

Кремль диварларының тышкы ягында һөнәрчелек бистәләре, базарлар урнашкан. Кремль тавының ышыгында, Болак елгасы буенда күнчеләр бистәсе булган. Ерак түгел генә тимерчеләр, чүлмәкчеләр, коралчылар һәм башка төрле һөнәр ияләре яши торган бистәләр төзелеп киткән.

Бизәнү әйберләре ясаучы осталар башлыча заказга эшләгәннәр. Бер елъязмада әйтелгәнчә, алардан «патша үзенә кыйммәтле таҗлар да, көмеш һәм алтын савытлар да, затлы киемнәр дә эшләткән». Алар алтын-көмештән, төрле асылташлардан, энҗе-мәрҗәннәрдән беләзекләр, йөзекләр, муенсалар, колак алкалары ясаганнар.

Корал ясаучылар исә күбесенчә ук-җәяләр, кылыч-хәнҗәрләр, көбә күлмәкләр, тимер башлыклар һәм башка әйберләр эшләгәннәр. Казан осталары бу вакытта әле туплар һәм дары белән ата торган мылтыклар ясамаганнар, шәһәргә аларны читтән кайтарта торган булганнар.



Казан янындагы Сәүдә утравы.

◀ Казан. 16 нчы гасыр башы. *Равил Заһидуллин рәсеме.*

Ул заманнарда Казан үзенең балта осталары белән танылган. Шәһәр йортлары һәм ныгытмалары башлыча агачтан эшләнгән. Бер тарихчы елъязмасында әйтеп калдырганча: «Казан шәһәре исә гаять нык, озын-озын юан имән бүрәнәләрдән төзелгән җиде кат стена белән әйләндереп алынган, һәм бу урыннан гаскәр үтәрлек түгел».

Шәһәр янәшәсендә махсус итеп ныгытылмаган бистәләр дә булган. Шуларның иң атаклылары — Кураиш һәм Биш Балта бистәләре. Соңгысы Казан елгасы тамагында урнашкан, биредә хәрби һәм сәүдә кораблары килеп туктый торган урын булган.

Казан, барыннан да бигрәк, Урта Идел буендагы мәшһүр сәүдә үзәге буларак дан тоткан. Җәенкышын үткәрелә торган ярминкәләргә чит илләрдән сәүдәгәрләр килгән. Бу ярминкәләр Сәүдә утравында һәм Арча кырында үткәрелә торган булган. Болак буендагы Ташаяк базарына шәрык илләреннән төрле җимешләр, кыйммәтле тукымалар, нәфис ефәк, келәмнәр, аш тәмләткечләр һәм чынаяк савыт-сабалар; Рус дәүләтеннән — кыйммәтле җәнлек тиреләре, балбалавыз; Кырымнан, Ногай һәм Әстерхан якларыннан — мал-туар һәм нәселле атлар китергәннәр.

Казан халкы гомер-гомергә сәүдә итәргә яраткан. Аларның тынгысыз хезмәте дәүләтнең байлыгын арттырган. Чит ил кешеләре Казанны «шәрык дөньясының капкасы» дип йөрткәннәр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Казан кайчан барлыкка килгән? Аңа хәзер ничә «яшь»?
2. 16 нчы гасырдагы Казанны ничек күз алдына китерәсез?
3. Мөмкинлек табып, Казан кремленә экскурсия оештырырга тырышыгыз.

28. МӘСКӘҮ БЕЛӘН КЫРЫМ АРАСЫНДАГЫ СӘЯСӘТ

Казан ханлыгының Көнчыгыш Европа үзәгендә, бик кулай җирдә урнашкан булуы, бер яктан, аның икътисади үсеше өчен уңайлы булса, икенче яктан, комсыз илбасарларның нәфесен һәрвакыт үзенә тартып торган. Ханлыкның югары катлау кешеләре арасындагы каршылыклардан бик оста файдаланып, Казанның дәүләт эшенә Рус кенәзләре, Ногай һәм Кырым ханнары тыкшына башлаганнар. Һәркем үз мәнфәгатен алга сөргән.

Казан тәхетенә үзенең тарафдарын куярга беренче адымны Мәскәү кенәзе Иван III ясап карый. 1487 елда Рус гаскәрләре шәһәр диварлары янына ук киләләр һәм Казанны камап алалар. Казанлылар батырларча сугышалар, шу-

лай да өч атналап дәвам иткән камалыштан соң бирелергә мәҗбүр булалар. Ханны, үзенең гаиләсе белән, Вологдага озаталар, һәм ул шунда әсирлектә үлә.

Казан тәхетенә яшь хан Мөхәммәтәминне утырталар. Шулай итеп, Казан ханлыгында Мәскәүгә бәйлелек башлана. Яңа хан, замандашларының әйтүенчә, «уңышлы» булып чыкмый. Ул сәүдәгәрләрне таларга керешә, алардан бик күп салым таләп итә һәм үзенә тәхеткә килергә ярдәм иткән әмирләр, бәкләр, морзалар белән арасын өзәргә тырыша. Аның мондый сәясәтенә түзеп тора алмыйлар һәм тәхеттән бәреп төшерәләр.

Казанга хан итеп, Мәскәү яңадан үзенең кешесен куйдырта. Халык аны бик салкын кабул итә, ахыр чиктә ул тәхетен калдырып китәргә мәҗбүр була. Хан итеп яңадан Мөхәммәтәминне чакыралар.

Икенче мәртәбә хан булгач, Мөхәммәтәмин бөтенләй яңа сәясәт үткәрә башлый. Ул Мәскәү тарафдарларын һәм Рус сәүдәгәрләрен Казаннан куа һәм Иван III гә каршы сугышка чыга. Казанлылар, ногайлар белән бергәләшеп, Түбән Новгородка яу чабалар һәм Идел буенда урнашкан Рус авылларын туздырып ташлыйлар.

Моңа җавап итеп, Рус хөкүмәте 100 меңлек гаскәр туплый һәм 1506 елның язында Казанга юл тота. Башта алар уңышлы гына хәрәкәт итәләр, Казанга килеп җитеп, аның бистәләрен алалар. Әмма ахыр чиктә казанлылар җиңә. Гаскәрләре русларныкыннан кимрәк булса да, алар бик оста сугышалар һәм дошманны бирелергә мәҗбүр итәләр. Русларның бер өлеше һәлак була, бик күбесен әсир итәләр, калганнары качып таралышып бетәләр.

Шушы вакыйгадан соң Казан белән Мәскәү арасында солых төзелә. Русларның барча тоткыннарын кайтарып җибәрәләр. Бу солых каршы якларның үзара тигез хокуклы булуын шарт итеп куя.

Ун ел буе Казан җирендә сугыш булмый тора. Хуҗалык күтәрелеп китә, сәүдә итү өчен уңай мөмкинлекләр ачыла. Мөхәммәтәминнең бу чорда хакимлек иткән еллары иминлек һәм үсеш чоры булып истә калалар.

Ләкин хан үлгәч, тәхет өчен көрәш өр-яңадан башланып китә. Башта тәхеткә Мәскәү тарафдары, Касыйм ханы, Шаһгали утыра. Әмма ул озак идарә итә алмый. Шулай да халыкны талап калырга өлгерә, Мәскәү яклы кешеләргә ирек ача. Казанлылар үзләренең ачуларын яшереп тормыйлар, Шаһгалине куып, тәхеткә Кырым ханзадәсе Сәхибгәрәйне утырталар. Шулай итеп, Казан дәүләтендә Кырым ханнарының көчле йогынтысына юл ачыла.

Казанның югары катлау әһелләре үзләренә хан сайлауны гомер

буе бер-берсе белән дошманлыкта яшәүче ике дәүләт — Мәскәү яки Кырым ризалыгы белән генә башкарып киләләр. Кырым үзенең Мәскәүгә каршы көрәшендә Казанның ярдәменә таяна. Сәхибгәрәй, аннан соң тәхеткә утырган Сафагәрәй хан Мәскәүгә каршы берничә тапкыр күтәреләләр.

1524 елда рус гаскәрләре Казанга ябырылалар, шәһәрне, туплардан атып, штурм белән алырга тырышып карыйлар. Казанлылар бирешмиләр. Руслар өчен шартлар авырая. Юл өзелә. Азык-төлек белән тәэмин итү, гаскәрне яңа көчләр белән тулыландыру туктала. Дошман лагеренда ачлык башлана. Руслар җыеләләр.

Бераз вакыттан Казан дәүләтендә хәлләр тагын кискенләшә. Сафагәрәйнең сәясәте белән риза булмаган феодаллар, баш күтәреп, аны тәхеттән куалар. Хан итеп патша династиясеннән булган кешеләр генә чакырыла алганга, тәхеткә Касыйм ханлыгыннан Мәскәү тарафдары Җангали утыртыла.

Татар бәге. *18 нче гасыр рәсеме.*

Җангалигә ул вакытта әле 15 яшьләр чамасы гына була, шуңа күрә дәүләт белән күбесенчә әмирләр һәм Рус кенәзенең куштаннары идарә итә. Казан бөтенләе белән, кем әйтмешли, Мәскәү җырын җырлый. Мондый хәл, әлбәттә, күпләрдә ризасызлык тудыра. Шәһәрдә фетнә башлана. Җангалине тәхеттән бәреп төшерәләр һәм үтерәләр. Хан итеп Кырымнан тагын Сафагәрәйне чакыралар.

Сафагәрәй бу юлы, югары катлау әһелләренең дә, гади халыкның да мәнфәгатьләрен ихтирам итеп, аңлап эш итәргә омтыла. Алар белән уртак тел таба. Казанлыларның басымы нәтиҗәсендә ул Кырымнан да, Мәскәүдән дә бәйсез, Казан мәнфәгатьләрен генә чагылдырган мөстәкыйль сәя-

сәт үткәрә башлый. Мондый омтылыш, әлбәттә, казанлыларның күңеленә хуш килә. Илдә тәртип һәм тынычлык урнаша.

Әмма бу хәл озакка бармый. Сафагәрәй, Кырым ханлыгыннан чыккан кеше буларак, гел шул якка тартыла. Халык моның белән килешмичә ризасызлык белдерә. Сафагәрәй тагын Казанны ташлап китәргә мәҗбүр була. Фетнәчеләрдән куркып, бу юлы ул үзенең хатыны Сөембикәнең әтисе, Ногай морзасы Йосыф янына кача.

Казанлылар яңадан Мәскәүгә мөрәҗәгать итәләр. Василий III, аларга хан итеп, шул ук Шаһгалине җибәрә. Казанлылар арасында аның абруе булмый, халык аны яратмый. Шаһгалигә үзе белән бернинди гаскәр алып килергә рөхсәт итмиләр. Шунлыктан ул Казанда озак утыра алмый, аның ханлык итүе бер айдан артмый. 1546 елда Сафагәрәй ногайлар гаскәре белән Казанга килеп җитәргә дә өлгерми, шәһәр кешеләре аны, капкаларны киң ачып, каршы алалар. Шаһгали кача. Сафагәрәй өченче тапкыр хан тәхетенә утыра.

Казан тарихы шуңа охшаш вакыйгаларга бик бай. Ханнарның еш алмашынып торуында Казанның үзендә бердәмлек җитмәү төп сәбәп була. Тәхет тирәсе кешеләре һәм феодаллар арасында ызгыш-талашлар бер дә өзелеп тормый. Бу исә дәүләтнең һаман көчсезләнүенә, таркалануына китерә.

Без сезгә Казан ханнарының исемнәрен тәкъдим итәбез. Менә алар Казан ханнары:

Галимбәк — Казан кенәзлегенең соңгы патшасы, 1445 елга кадәр идарә итә.

Мәхмүт хан — Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәтнең улы, 1445 елда Казанны сугышып ала һәм, Галимбәкне үтереп, үзен хан итеп игълан ясый, 1467 елга кадәр идарә итә.

Хәлил хан — Мәхмүт ханның улы, 1467 елда хан була, шул ук елда үлә.

Ибраһим хан — Мәхмүт ханның икенче улы, 1468—1479 елларда идарә итә.

Илһам хан — Ибраһим ханның улы, 1479—1487 елларда идарә итә.

Мөхәммәтәмин хан — Ибраһим ханның улы, 1487—1496 һәм 1502—1519 елларда идарә итә.

Мамык хан — Себер ханлыгындагы Шәйбанилар нәселеннән, 1496 елда Казанны кулга төшереп, берничә ай хан булып тора.

Абдуллатыйф хан — Ибраһим ханның улы, 1497—1502 елларда идарә итә.

Шаһгали хан — Алтын Урда ханнары нәселеннән Шәехәүлияр улы, 1519—1521, 1546 (бер ай чамасы), 1551—1552 елларда идарә итә.

Сәхибгәрәй хан — Кырым ханнары нәселеннән, Миңлегәрәй

хан улы, 1521—1524 елларда идарә итә.

Сафагәрәй хан — Кырым ханнары нәселеннән, Миңлегәрәй ханның оныгы, 1524—1532, 1536—1549 елларда идарә итә.

Җангали хан — Шаһгали ханның туганы, 1532—1535 елларда идарә итә.

Үтәмешгәрәй хан — Сафагәрәй хаң белән Сөембикәнең улы, 154. елда туган. 1549—1551 елларда аның исеменнән әнисе идарә итә.

Ядъкәр хан — Әстерхан ханы Касыймның улы, 1552 елда идарә итә. Казанның соңгы ханы.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Сез, бу бүлекне укып, Казан ханнарының кайсыларын хәтерегездә калдыра алдыгыз?
2. Ни өчен хан тәхетенә һаман чит кешеләрне чакырып торганнар? Казан өчен моның нинди тискәре яклары булган?
3. «Тарихи сүзлек»кә Казан ханнарының исемнәрен язып куегыз.

29. КАЗАН ХАНЛЫГЫ НИЧЕК ЯУЛАНА?

Рус кенәзләре гасырлар буена Болгар-Казан иленә тынгы күрсәтмиләр. Моның бер «сәбәбе» була: Урта Иделнең сәүдә итү өчен иң уңайлы төбәген казанлылар биләп торалар. Рус дәүләте бу җирләрне кулга төшерү өчен хыяллана, мәкерлекләр кора. Казанлылар аңа нинди игелекләр генә эшләмәсен, русларның бөтен максаты — Казан ханлыгын ахырынача җимерү, юк итү була.

Сафагәрәйнең кинәт кенә үлеп китүе, шуннан соң Сөембикәнең һәм улы Үтәмешгәрәйнең Мәскәүгә әсирлеккә озатылуы Казан халкында зур борчылу һәм шом тудыра. Хан булып Мәскәүдән тагын Шаһгали килә. Тәхеткә утырыр алдыннан аны Мәскәү патшасы Иван IV белән килешү төзергә мәҗбүр итәләр. Бу килешү нигезендә Казан ханлыгының Тау ягы дип йөртелгән өлеше (Иделнең уң ягы) Мәскәү дәүләтенә күчә. Тиздән биредә руслар Казанга һөҗүм ясаганда файдалану өчен Зөя крепостен төзи башлыйлар.

Шаһгалинең үзе белән Казанга рус гаскәрләрен дә алып килүе, Тау ягын киңәшсез-нисез русларга бирүе һәм казанлыларның мәнфәгатьләрен бөтенләй исәпкә алмавы зур канәгатьсезлек тудыра. Алар, ниһаять, үзләренең алданганлыкларын, Шаһгалинең чын хан булмавын, ә Мәскәү патшасының Казанга җибәрелгән хезмәтчесе икәнлеген бик ачык аңлыйлар.

Рус сугышчылары.



Казанны яулау. *План-карта.*

1551 елның октябрендә Мәскәүгә Казанның иң мөхтәрәм әмирләреннән, аксакалларыннан төзелгән илчелек килеп төшә. Алар, казанлылар үзләрнең Тау ягындагы биләмәләреннән ваз кичмиләр, ул җирләрдән килгән керем дә Казанныкы булырга тиеш дип, патшага мөрәҗәгать итәләр. Иван IV бу тәкъдимнәрне тупас рәвештә кире кага һәм илчеләрне кулга алырга боера.

Бу хәл казанлыларның ачуларын бик нык кабарта. Шаһгали хан, халыкның ризасызлыгын бетерү турында уйлыйсы урынга, аның сәясәте белән канәгать булмаган кешеләрне каты җәзага тарта. Бик күпләр корбан була.

Рус патшасы Казан белән килешергә түгел, киресенчә, аны тизрәк буйсындырырга омтыла. Аның мәкерле уе 1552 елның февралендә тәгаен ачыла. Иван IV нең исәбе — казанлыларны үзенә тугрылыкка ант иттереп, аларның

Казан сугышчылары.

Казанны яулап алу сугышлары. *Рус елъязмасыннан рәсемнәр.*

җирләрен тыныч юл белән Рус дәүләтенә кушу. Март башында казанлылар антын кабул итү өчен, Иван IV нең наместнигы килергә тиеш була. Шаһгали шулвакыт Казанны калдырып китә.

1552 елның 9 мартында, рус наместнигы Казанга киләсе көнне, халык баш күтәрә. Берәү дә үз теләге белән русларның колы булырга теләми. Казанлылар русларның шәһәрдәге хәрби отрядларын тар-мар итәләр. Бушап калган Казан тәхетенә Әстерханнан Ядъкәр хан чакырыла.

Мәскәүдә шулай ук хәлиткеч яуга әзерләнәләр һәм гаять зур гаскәр туплап (150 меңнән артык сугышчы) Казанга юл тоталар. 1552 елның августында рус яулары Казанга килеп җитәләр. Шәһәрне шунда ук камап алалар. Казан искитәрлек дәрәҗәдә яхшы ныгытылган була. Иван IV аны ничек кулга төшерү турында уйлана башлый.

8 Ч-279

Казан халкы бердәм булып туган каласын сакларга күтәрелә. Шәһәр сакчыларының кораллары, бигрәк тә туплары, аз була. Шулай да алар каушап калмыйлар. Дошман тылында каһарман партизан Япанча атлылары русларга көн күрсәтми. Көтмәгәндә әледәнәле шәһәр капкасыннан атлы сугышчылар чыгып, дошман өстенә ыргылалар һәм, русларны туздырып, күз ачып йомганчы яңадан крепостька кереп югалалар.

Мондый сугышлар бер ай чамасы дәвам итә. Сентябрь урталарында Япанча отрядлары камалышка эләгә. Арча шәһәре яндырыла. Казан өчен көрәш тагын да кискенләшә. Шәһәр өстенә көне-төне уклар, ут ява. Чит илдән махсус чакырылган хәрби остазлар кремльнең биек диварларын, манараларын ничек җимерттерергә план коралар. Аларның киңәше белән ныгытмалар астына тирән чокырлар казыйлар һәм шунда дары мичкәләре тутыралар. Көчле шартлаудан җирләр селкенә. Кремль диварларының бер өлеше һәм манарасы җимерелеп төшә. Ләкин казанлылар бирелергә теләми. Шәһәрне саклап калырга мөмкин түгеллеген аңласалар да, соңгы сулышларына кадәр көрәшәләр.

1552 елның 15 октябрендә руслар бөтен фронт белән штурмга күтәреләләр. Алар тагын берничә урыннан шәһәр диварларын шартлаталар һәм таш капкадан үтеп керәләр. Урам сугышлары башланып китә. Казанлыларның бу кадәрле үз-үзләрен аямыйча сугышуы руслар өчен көтелмәгән хәл була. Урамнардан кан инешләре ага. Йорт-каралтылар яндырыла. Мәчетләр җимертелә. Бөтен җирдә канга баткан гәүдәләр аунап ята. Тарихыбызның мондый вәхшилекне беркайчан да күргәне булмый.

Бу вакыйгалардан соң еллар, гасырлар үтте. 12 октябрь көне халык хәтерендә һаман олы фаҗига булып яши. 12 октябрь — Хәтер көне, бәйсезлегебез өчен изге көрәштә һәлак булган ерак бабаларыбызны искә алу көне.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Иван IV Казан ханлыгын Рус дәүләтенә сугышсыз гына кушу өчен нинди адымнар ясый?
2. 1552 елның 9 март вакыйгасын сез ничек аңлыйсыз?
3. Явыз Иванның Казанны басып алуы турында хикәя төзегез.
4. Нәрсә ул Хәтер көне һәм ул кайчан үткәрелә?

◀ Казан мәхшәре. *В. И. Вениг рәсеменнән репродукция. XIX гасыр.*

30. КАЗАН ИЛЕНЕҢ МӘДӘНИЯТЕ

Казан ханлыгына озак яшәү насыйп булмаган. Язмыш аңа бик аз вакыт биргән. Бу вакытның да шактый өлеше чит илбасарларга каршы көрәшкә, эчке ызгыш-талашларга сарыф ителгән. Шуңа карамастан, ул кыска гына вакыт эчендә дә Көнчыгыштагы һәм Көнчыгыш Европадагы алга киткән илләр белән бер югарылыкка менә, Идел, Кама, Урал, Себер төбәкләренең мәдәни үзәгенә әверелә.

Казан ханлыгы чынлыкта Бөек Болгар иленең, халкының, мәдәниятенең дәвамы булган. Ул Кыпчак Урдасыннан да мирас итеп күп нәрсә алган. Башка илләр белән борын-борыннан килгән бәйләнышлар дәвам иткән. Аеруча Урта Азия, Мисыр, Төркия, Рус, Кырым, Иран, Гарәбстан белән элемтәләр көчле була. Иранннан, Урта Азиядән Казанга китаплар килә. Хөрмәтле хаҗилар, кыен ерак юлларны үтеп, мөселманнарның иң изге җире — Мәккәгә баралар, илчеләр Әстерхан, Бакчасарай, Мәскәү, Константинополь арасында ил мәнфәгатьләрен кайгыртып эш йөртәләр.

Казан илендә нигездә элекке Болгар дәүләте халкы яши. Монда мари, удмурт, чуваш һәм башкорт, мордваларның бер өлеше тел, әхлак һәм мәдәни казанышларны алмашып көн итәләр. Һәр вакыйга, һәм бәйрәм бу халыклар өчен уртак. Мәсәлән, безнең матур бәйрәмебез Сабантуйны алар элек тә бергә үткәргәннәр.

Казан чит дәүләт илчеләрен, кунакларын һәм сәүдәгәрләрен, бик ерактан ук балкып, берсеннән берсе матур диварлары, биек, күп манаралы мәчет, мәдрәсәләре белән, моңлы азан тавышлары белән каршы алган. Авыллар да мәчетсез булмаган. Ә һәр мәчетнең мәктәп-мәдрәсәсе булган. Бар халык диярлек аң-белемгә тартылган. Казан иле кешеләренең мәдәниятле, аң-белемле булуына чит ил кешеләре дә сокланганнар. Шул вакытта Казанга килгән немец сәяхәтчесе С. Герберштейн: «Казан татарлары бүтәннәргә караганда аң-белемлерәк, алар иген игәләр, әйбәт өйләрдә яшиләр, киң сәүдә алып баралар»,— дип язган үзенең юлъязмасында. Шулай шул, аң-белемнән башка иген игеп тә, йортлар төзеп тә, сәүдә итеп тә булмаган.

Казан шәһәрендә күп гыйлем йортлары урнашкан. Аларда укырга-язарга өйрәтү белән бергә, дәүләтнең эш кәгазьләрен язучылар да, матур итеп китап күчерүчеләр дә, ясак җыючылар да, галимнәр, шагыйрьләр, дин белгечләре дә әзерләнгән. Казан иле укымышлылары күп телләр белгәннәр. Ә гарәп, фарсы телләре туган тел белән бер дәрәҗәдә диярлек кулланышта булган. «Татарга

тылмач кирәкми» дигән әйтем шул чорлардан ук килә, ахрысы. Ул чорда мәгърифәт эше дин әһелләренә йөкләнгән. Алар арасында зур хөрмәт иясе, илдә ханнан кала икенче кеше — сәед булган. Алар зур-зур мәчетләр, мәдрәсәләр тотканнар. Сәед Кол Шәриф исеме бүген дә онытылмый. Аның 8 манаралы мәчете һәм янындагы мәдрәсә бөтен тирә-якта дан тоткан.

Зур түрәләрнең балаларын, борынгы болгарлар кебек үк, тормыш тәҗрибәсе туплаган бабайларга тәрбиягә биргәннәр. Аларны сөт аталары, аталыклар дип олылаганнар.

Коръәнне дөрес итеп укырга, яттан белергә өйрәткәннәр. Аларны хафизлар дип йөрткәннәр. Казан укымышлылары изге китапка аңлатмалар да язганнар. Шундыйлардан 1508 елда ук язылган «Коръән тәфсире», Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы, әйткән сүзләре (хәдисләр) җыелмасы (1552 ел) безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Суфилар, шәехләр мәҗүсилектә яшәүче халыкларны ислам диненә өндәп йөргәннәр. Көч куллану галәмәтләре тыелган. Башка диндәге кешеләргә дә игътибарлылык күрсәткәннәр. Казанда христиан-әрмән чиркәве эшләгән.

Казан ханлыгында эш кәгазьләренә мөнәсәбәт бик югарылыкта торган. Хан идарәсендә сәркатипләр (секретарьлар), хисапчылар, күчереп язучылар, тамгачылар (мөһер сугучылар) эшләгән. Аларга бахшилар җитәкчелек иткән. Ханнар, теге яки бу түрәгә җир бүлеп, ясак түләүдән азат итеп ярлык биргәннәр. Безнең көннәргә кадәр, мәсәлән, Ибраһим һәм Сәхибгәрәй хан ярлыклары килеп җиткән. Алар озын кәгазьләргә матур итеп язылган. Ахырдан төрле төс белән тамга-мөһер сугылган.

Менә Сәхибгәрәй хан ярлыгы ничек башланып китә (безнең чор стилендә бирелә):

«Әссолтан әлгазый Сәхипгәрәй сүзем Әмирләргә, хәкимнәргә, олы сәедләргә, ислам казыйларына, хөрмәтле хуҗаларга, вәкаләтле кешеләргә, урыннардагы түрәләргә, урам-төбәк башлыкларына, сакчыларга, тамгачыларга, барча халыкка, барлык Казан өлкәләренә һәм бәла, афәтләрдән саклана торган барлык мәмләкәтләргә бу нишан җиткәч, минем сүзем шул...»

Бу ярлык 1523 елның 3 гыйнварында язылган. Аңа инде 460 ел. Ул Казан ханлыгы хакында күп мәгълүмат бирә.

Осталар үзләре ясаган әйберләрен матур язулар, хикмәтле сүзләр белән бизәгәннәр. Менә Мөхәммәтәмин ханның бакырчы остасы Насыйри күркәм нәфис комганга, сөйгәнен мактап, хәтта шигъри юллар язып калдырган.

Ата-бабаларга ихтирам, үлгәннәрне хөрмәтләп искә алу без-

нең халкыбызга борынгыдан ук хас. Бу чорда каберләргә куелган ташъязмалар аеруча бизәкле. Аларның кайберләре катлаулы бизәкле келәмнәрне хәтерләтә. Аларда еш кына кайгы-хәсрәтләрен белгертеп, үлгәннәрне юксынып, шигырьләр дә язылган. Бу ташлар, изге итеп кадерләп, саклап тотылган.

Казанда галимнәр яшәгәннәр. Кешеләр көнчыгышның Әбу Гали Сина, Ибн Халдун, Гомәр Хәйям, Газәли, Бируни кебек атаклы галимнәренең китапларын укыганнар. Аеруча бөек табиб Әбу Гали Синаның сихәтлек китабын яратып укыйлар. Андагы киңәшләрне тотып, үзләре туплаган тәҗрибәне дә кушып, авыруларны дәвалаганда файдаланалар.

Болгар, Алтын Урда чоры әдәбият традицияләре Казан илендә яңа баскычка күтәрелә. Күп гасырлар буе камилләшкән төрки телдә бик күп шагыйрьләр, әдипләр иҗат итә. Гарифбәк, Кол Шәриф, Мөхәммәтшәриф, Өмми Камал, Мөхәммәтәмин... Шагыйрь Мөхәммәдъяр Казан турында болай яза:

«Бер гаҗәб бу кем шәһәрнең әче тулы,
Шагыйрь булганнар барча кечәсе һәм олысы»;—

Бу дәвер шигъриятенең иң күренекле вәкиле, билгеле, Мөхәммәдъяр (1502—1552 еллар). Аның өч әсәрен без бүген дә сокланып укый алабыз. Бу — 1540 елда тәмамланган «Төхфәи мәрдән» (Егетләргә бүләк), 1542 елны «Нуры содур» (Күңелләр нуры), «Нәсихәт» әсәрләре. Аның шигъриятендә гаделлек, халыкка хезмәт итү, кешелеклелеккә дан җырлана.

Бизәкле, язулы җиз кувшин. XVI гасырның беренче яртысы.

Шагыйрь Мөхәммәдъяр. *Р. Шәмсетдинов рәсеме.*

«Бер сәгать гадел кылмак
яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш елдин
озаграк».

Димәк, бер сәгать яхшылык эшләү 60 ел дога кылудан да саваплырак икән.

Илдә азәрбайҗан, үзбәк, төрек, төрекмән, гарәп, фарсы шагыйрьәдипләре әсәрләрен дә яратып укыганнар. Ул вакытта галимнәр, шагыйрьләр, җырчылар, музыкантлар, талантлы остазлар хан һәм зур түрәләр мәрхәмәте белән генә иҗат итә алганнар. Казан иле тарихында гыйлемгә, әдәбият, сәнгатькә бирелгән ханнарның берсе Мөхәммәтәмин булган. Шагыйрь кеше буларак, ул үз сараена илдәге галим-голәмәне, шагыйрьләрне, остазларны тупланган. Бохара, Сәмәрканд төбәкләре ханы Мөхәммәт Шәйбани (1451—1510 еллар) Мөхәммәдәмингә, бүләк ясап, музыкантлар, җырчылар, шагыйрьләр, рәссамнар җибәргән. Алар арасында үз чорының күренекле җырчысы Голәм Шади Гуди да булган.

Бу дәвердә бик күп дастаннар, бәетләр, тарихи җырлар, экиятләр, риваятьләр, табышмак, мәкальләр туа. Болгар-Казан турындагы риваятьләрдә, «Амәт», «Идегәй» кебек дастаннарда туган илне ярату, аны саклау, тарихны олылау кебек иң зарури темалар сурәтләнә.

Әмма бу мөстәкыйль дәүләттә туган ирек җырлары, шигырьләр



Казан һөнәрчеләре эшләгән алтын аел.

аһәңе бер вакыт өзелеп, тукталып кала. Дошман илне канга батыра. Халыкны Казан һәм аның тирәсеннән ерак җирләргә куалар. Ил талана. Алтын, көмеш, энҗедән эшләнгән бизәнү әйберләре, затлы киемнәр 12 корабка шыплап төялә һәм Мәскәүгә озатыла.

Дошман иң беренче чиратта изге мәчет, мәктәп, мәдрәсәләрне җир белән тигезли. Казанның рухын мәсхәрәли, бөтенләйгә юк итмәкче була. Халыкның иң изге җирләрендә — Биләр, Болгар, Казан шәһәрләрендә — мәчетләр урынына чиркәүләр, монастырьлар үсеп чыга. Дошман изге кабер ташларын шул чиркәү, монастырьларның нигезләренә сала. Изге Коръән, китапханәләр, борынгы кулъязмалар яндырыла.

Дошман халыкның тарихын оныттырырга тели. Ут, кылыч, кан белән көчләп чукындыру башлана.

Әмма дә, манкортлар хәленә калмас өчен, халык гасырларга сузылган көрәшкә күтәрелә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Болгар һәм Казан илләре мәдәниятләрен чагыштырып сөйләгез.
2. Казан илендә нинди шагыйрьләр иҗат иткән?
3. Сезнең шәһәр, авыл зиратларында кабер ташлары бармы?
4. «Тарихи сүзлеккә» Колшәриф, сәед, хаҗи, суфи, шәех, бахши, казый, нишан, ярлык, дастан дигән сүзләрне аңлатып язып куегыз.

31. СӨЕМБИКӘНЕ САГЫНУ

Казандагы Сөембикә манарасы борынгы шәһәр архитектурасының сокландыргыч үрнәге булып исәпләнә. Ак кремль диварлары уртасында, Казанның иң бик ноктасында, бала итәкле милли күлмәк кигән алсу йөзле, зифа буйлы сылу бер кыз басып тора диярсең. Бу һәйкәлнең кайчан төзелүе тәгаен билгеле түгел. Галимнәрнең кайберләре аның төзелү вакытын XVII гасырга, икенчеләре элегрәк чорларга кайтарып калдыралар. Ни генә булмасын, халык аны «Хан мәчете» яки «Сөембикә манарасы» дип йөри. Ул — кызыл кирпечтән өелгән җиде катлы манара. Аның беренче, икенче, өченче катлары дүрт кырлы, бишенче, алтынчы, җиденче катлары исә сигез кырлы. Манара очлаеп тәмамлана, югаргы өлеше калай белән ябылган.

Казан иленең иң соңгы ханшаларыннан булган Сөембикә исеме белән бәйле бу манара хакында күп риваятьләр йөри халыкта. Имеш, Сөембикәне күреп гашыйк булган Мәскәү патшасы аны хатынлыкка сораган. Сөембикә риза булмаган. Шуннан соң Мәскәү патшасы: «Үз теләгең белән чыкмасаң, мин сине сугышып алам!» — дигән дә, Казан ханлыгына сугыш ачкан. Җиде ел камап торганнан соң, шәһәр диварларын ваттырып, Казан шәһәрен алган бу. Сөембикә, Мәскәү патшасына кияүгә чыгып иленнән киткәнче, биек бер манара төзетергә, шунда халык белән хушлашырга тели. Мәскәү патшасы ризалаша, озакламый мин аны үземә хатынлыкка алып китәм, үзенчә эшләп калсын инде, дип уйлый. Сөембикә манара очына менеп соңгы мәртәбә иленә, халкына баш ия, хушлаша һәм, явыз Мәскәү патшасына хатын булып китәргә теләмичә, манарадан аска ташланып һәлак була.

Шуңа охшаш бер риваятьне без алдагы бер дәрестә дә укып үткән идек инде. Аерма зур түгел — аларда сөйләнелгән вакыйгаларның чорында һәм тарихи шәхесләрдә генә: монголларның басып алу чоры яки Алтын Урда ханнарының Болгарга һөҗүмнәре сурәтләнә. Анда да Болгар патшасының кызы илбасарга кол булып киткәнче манарадан ташланып үлүне артыграк күрә.

Сөембикә манарасы.

Шулай итеп, Болгар дәүләтенең җимерелү вакыйгаларын сурәтләгән риваять Казанны руслар алганда Сөембикәгә бәйле рәвештә тагын яңара. Бу, бер яктан, халыкның хәтере хакында сөйләсә, икенче яктан, аның рухи мәдәниятенең өзлексез агышын күрсәтә.

Риваятьләрдә, бәетләрдә сөйләнерлек, җырларда җырланырлык Сөембикә кем булган соң?

Идел белән Җаек (Урал) елгалары арасында Ногай Урдасы далалары җәйрәп ята. Көннәрдән бер көнне Ногай морзасы Иосыф белән Фатыйманың бер кызы туа. Аңа

Сөембикә. *Р. Төхфәтуллин рәсеме.*

шатланып, сөенеп, Сөембикә исеме кушалар, ягъни кешеләргә сөенеч, шатлык китерүче кыз, дигән сүз.

Сөембикә матур далаларда, сахраларда уйнап, ата-бабасыннан үгет-нәсихәт, табигатьтән акыл алып, сылу кыз булып үсеп җитә. Аның кебек гүзәл, аның кебек акыллы кыз Ногай илендә генә түгел, Казан, Рус илләрендә дә булмый. Аның чибәрлеген, акыллылыгын ишетеп, Казанның яшь ханы Җангали кызның кулын сорый. Сөембикә Ногай иленнән Казан иленә килен булып төшә. Казан илендә ирек, бәйсезлек яратучы халык яши. Хәтта ханнарны да алар үзләре сайлыйлар. Ошаганнарын чакырып алалар, ышанычларын акламаганнарны куып җибәрәләр. Халыкның, ирек сөюче батыр Сөембикәнең өметен акламаган Җангалине дә шундый язмыш көтә. Нәфрәтләнгән халык аны бер көнне үлемгә дучар итә. Казанлылар 1535 елны Сафагәрәйне хан итеп алалар. Ике яшь — Сафагәрәй һәм Сөембикә беренче күрешүдә үк берберсен ярата. Алар, бергәләшеп киңәш корып, 15 ел буе Казан иле белән идарә итәләр. Бу чорда ил ныгый, чәчәк ата. Илне таларга, кол итәргә килгән дошманнар да җиңелүгә дучар булалар.

Бу дәвер халыкның тыныч хезмәт, иҗат еллары була. Сөембикә бай китапханә җыя. Ул гади китапханә генә булмый. Анда китаплар күчерәләр, кычкырып китап укыйлар, шагыйрьләр, рәссамнар, галимнәр җыела. Ә алар арасында шагыйрь Гарифбәк Сөембикәне мактап язган илһамлы шигырьләре белән дан казана.

1546 елны Сафагәрәй белән Сөембикәнең Үтәмешгәрәй исемле уллары туа. Әмма бәхетле еллар озакка бармый. 1549 елда көннәрдән бер көнне Сафагәрәй кинәт вафат була. Сөембикә кара кайгыга кала. Ул яраткан ирен сагынып бик күп кан-яшь түгә. Иренең төрбәсе янына бик матур манара салдыра.

Үтәмешгәрәй әтисеннән 2 яшьтә ятим кала. Үтәмешгәрәйне хан дип игълан итәләр. Ә ул балигъ булганчы Казан иле белән Сөембикә идарә итәргә тиеш була. Ләкин дошманнар Үтәмешгәрәйнең буй-сыны ныгыганын, үсеп җиткәнен көтеп тормыйлар. Киресенчә, аның сабыйлыгыннан файдаланып, әтисе үлгәч тә, гаскәр белән бертуктаусыз Казан иленә килә торалар. Күп кешеләр башын сала бу сугышларда. Рус патшасы явыз Иван, казанлылар Сөембикәне һәм сабый хан Үтәмешгәрәйне биреп җибәрсәләр, илне тынычлыкта калдырачагын җиткерә. Мәкерле дошман Сөембикә белән Үтәмешгәрәйне кулга төшерсә, буйсынмас Казан илен ничә еллар буе хыялланганнан соң җиңел генә басып аласын бик яхшы аңлый. Казан илендә бердәмлек бетә, мал һәм тамак өчен илен, халкын сатарга әзер кешеләр дә күбәя. Сугышлардан йончыган халык, алар коткысына бирелеп, Сөембикәне һәм аның яшь улын

явыз Иван кулына бирә.

Явыз Иван 5 яшьлек сабыйны — Үтәмешгәрәйне — Сөембикәнең йөрәк парәсен кочагыннан йолкып ала. Сабыйны көчләп чукындыралар. Александр дип исемен дә алыштыралар. Үз диненнән, исеменнән язган баланы христиан законына өйрәтү, илен, халкын, туган анасын тизрәк оныттыру өчен бер монахка бирәләр. Маңкортка әйләндерелгән Үтәмешгәрәй озак гомер итә алмый. Ул 20 яшендә (1566 елда) әллә үтерелә, бу дөньяда бер ямь калмаганлыктан, әллә үзе үлә. Ул, рус патшаларының каберләре белән беррәттән, Мәскәү кремленең Архангельск чиркәвенә күмелә.

Әнисе Сөембикәне, мәҗбүр итеп, Касыйм ханы Шаһгалигә кияүгә бирәләр. Шаһгали кара тут йөзле, салынкы озын колаклы, кыска аяклы, зур корсаклы, табак битле бик сөйкемсез зат була. Шаһгали берничә мәртәбә Казан тәхетенә менеп утыра. Халык бу булдыксыз түбән җанны һәрчак куып җибәрә.

Казан илен туздыруга, юкка чыгарырга булышкан кешеләр ул чакта аз булмый. Әмма ләкин икейөзле булуда, түбәнлеккә төшүдә Шаһгали барысыннан да уздыра. Ул иленә, халкына хыянәт итә. Тарихта аның исеме кара хәрефләр белән сатлык җан дип язып куелган.

Сөембикә, шушы түбән җаннан мәсхәрәләнеп, күзгә күренеп сула, саргая һәм газабын кичерә алмыйча дөньядан китә.

Халык бүген дә Сөембикәне хәтерли, сагына. Аңа багышлап чыгарылган җырлар, бәет, риваятьләрне буыннан буынга тапшыра. Тарих хәтере яңара тора. Менә Сөембикә манарасы очына тагын изге алтын ай менеп кунды. Монда һәр елны 15 октябрьдә* аеруча күп кеше җыела. Бу — халкыбыз тарихында иң дәһшәтле, иң зур кайгылы көннәрнең берсе — Казан дәүләте бетерелгән, бик күп меңнәрнең каны коелган көн. Бүген Сөембикә манарасы төбендә Коръән укыйлар. Галимнәр узган тарихны искә төшерәләр, шагыйрьләр шигырь укыйлар. Барысы да Сөембикә хатирәсен яңарта.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен Явыз Иван казанлылардан Сөембикә белән Үтәмешгәрәйне алып китә?
2. Ни өчен Үтәмешгәрәйне ашыгыч рәвештә чукындыралар, руслаштыралар?
3. Ни өчен бу хикәя «Сөембикәне сагыну» дип атала?
4. Сөембикә манарасының макетын ясагыз.

* 16 нчы гасырда иске һәм яңа стиль белән ел исәпләү аермасы 10 көн тәшкил итә. Димәк, Хәтер көне, фәнни исәпләгәндә, 12 октябрьгә туры килә.

ДҮРТЕНЧЕ
БҮЛЕК

БОЛГАР-КАЗАН ҖИРЛӘРЕ РОССИЯ ИМПЕРИЯСЕ СОСТАВЫНДА

32. РУС ПАТШАЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ ИЗҮЕ ҺӘМ АҢА КАРШЫ КӨРӘШ
(16 нчы гасырның икенче яртысы)

Мәшһүр Болгар иленең варисы булган Казан патшалыгын басып алганнан соң, Россия күпмилләтле бөек державага әйләнә. Дөрес, аның «бөеклеге» байлыктан түгел, бәлки территориясенең зурлыгыннан һәм халкының күплегеннән гыйбарәт була. Моңарчы үз тормышлары белән тыныч кына яшәп яткан дистәләгән халыкларны, үз канатыбыз астына алабыз дигән булып, һәркайсын корал кулланып буйсындыра торгач, ничек зур булмасын ди дә аның җирләре, ничек күп булмасын ди аның халкы? Безнең Болгар җирләре дә шул рәвешчә, Россиянең бер колониясенә әйләнеп китә.

Нәкъ шушы чорда руслар болгар-кыпчак халкын татарлар дип атап йөртә башлыйлар. Ул язма әдәбиятка, дипломатлар-илчеләр теленә татарлар дигән атама белән кереп китә. Шушыннан соң тарихыбызда болгар-татарлар дип аталган дәвер башланып китә.

Казан патшалыгы яшәүдән туктагач, биредә ханнар хакимлеге бетерелә. Элекке ханлык җирләре белән идарә итү өчен Мәскәүдә махсус Казан приказы оештырыла. Казанга һәм Зөя каласына рус патшасының идарәче урынбасарлары — «олы воеводалар» җибәрелә. Алар үзләре белән укчы отрядлар алып киләләр. Бу отрядлар Казаннан һәм аның тирә-юнендәге барча авыллардан җирле халыкны куып бетерәләр. Игътибар итегез, бүгенге көндә дә Казанга 45 чакырымнан якынрак урнашкан бер татар авылын очратмассың. Гомер буе һөнәрчелек һәм сәүдә белән тормыш иткән халыкка бу эшләр белән шөгыльләнү бик нык чикләштерелә. Металл эшкәртү, корал ясау һәм алар белән сәүдә итү катгый тыела.

Элек болгар калалары булган Арчада, Лаештa һәм Тәтештә тиз арада русларның хәрби ныгытмалары төзелә. Шундый ук ныгытма-шәһәрләр чуваш һәм мари җирләрендә (Чабаксар, Козьмодемьянск, Кокшайск һәм Царевококшайск — хәзерге Йошкар-Ола) барлыкка киләләр. Аларга рус кешеләрен күчереп утырталар.

Казан да әкренләп рус шәһәренә әверелә. Аның төп халкы кырылган була. Калганнарына Болак елгасы һәм Кабан күле артына гына күчеп урнашырга рөхсәт ителә. Анда Татар бистәсе төзелә. Шәһәрнең үзендә исә рус кешеләренә яки чукынганнарга гына яшәргә ирек бирелә.

1556 елда Казан кремленең агачтан салынган ныгытмаларын таш стеналар белән алмаштыра башлыйлар. Төзү-төзәтү эшләрен Псковтан һәм Новгородтан махсус чакыртылган Постник Яковлев һәм Иван Ширяй җитәкчелегендә 200 кешелек ташчылар бригадасы башкарып чыга. Кремльнең стеналары биек манаралар белән ныгытыла. Кирәк була калса дип, ату өчен махсус ясалган тишекләр янына туплар (пушкалар) урнаштырыла. Урыны белән киңлеге 6 метрга җитә торган таш стеналар буйлап көндез дә, төнлә дә кораллы сакчылар йөреп тора. Шәһәргә керә торган тимер капкаларны төнгелеккә, баш каравылчының чаң кагуын ишетүгә, ныклап бикләп куялар һәм иртән кояш чыкканчыга кадәр ачмыйлар.

Кремльдә патша воеводалары, югары катлау боярлар, руханилар, хәрбиләр яшәгән. Моннан тыш анда архиепископ йорты, монастырьлар, чиркәүләр, ашлык амбарлары һәм берничә төрмә булган. Элеккеге хан сараеның яртылаш җимерелгән таш биналарын һәм мәчетләрен хәрби складларга әйләндергәннәр. «Кремльне руслар гына саклый, анда бер генә татарга да аяк басарга рөхсәт ителми, үлем җәзасы белән куркыталар»,— дип язып калдырган шул елларның бер шаһите.

1552 елгы канлы вакыйгалардан соң, Казан тирәсендәге һәм башка күп кенә төбәкләрдәге авылларны, уңдырышлы җирләре белән, рус феодаллары — дворяннар һәм алпавытлар биләп алган. Ханлыкның төп халкын Идел-Кама һәм эре сәүдә юллары буена урнашкан авыллардан бөтенләйгә куганнар.

Казан дәүләтендәге халыкларның күпчелеген тәшкил иткән крестьянар элек тә башлыча турыдан-туры дәүләткә, ягъни ханга буйсынып яшәгәннәр. Хәзер исә алар ясакны, төрле налогларны рус патшасына түләргә тиеш булганнар. Урындагы воеводалар, хөкүмәт билгеләгән налогларны үз файдаларына икеләтә-өчләтә арттырып, халыкны рәхимсез рәвештә талаганнар. Ә болгар-татар крестьяннарын һәртөрле салымнарны башка халыкларга караганда да күбрәк түләргә мәҗбүр иткәннәр.

Тиздән Казан җирләренә рус чиркәве әһелләре, руханилар да күпләп күчеп утыра башлыйлар. Яңа чиркәүләр, монастырьлар төзелә. Аларга да җирле халыктан тартып алынган җирләрне бүләк итәләр. Мөселманнарны һәм әле мәҗүсилектән чыкмаган чуваш, мари, удмурт, мордва халыкларын мәҗбүри чукындыру башлана. Барлык

9 ч-279

мәчетләрне җимерәләр, мәҗүсиләрнең изге агачларын кисәләр, табыну урыннарын яндырып туздырып бетерәләр.

Татар феодалларының бер өлеше, үзләренең җир биләмәләрен саклап калу максатын тотып, рус патшасына ялчылыкка күчә, кайберләре хәтта христиан динен кабул итә. Аларны йомышлы татарлар дип йөрткәннәр. Йомышлы татарларны, ягъни рус хөкүмәте яклы булган татар морзаларының бер өлешен, Россиянең төрле өлкәләренә, шул исәптән Арзамас, Темников, Алатырь, Касыйм өязләренә күчереп утырталар. Аларга хәрби хезмәтләре өчен җир һәм крестьяннар бирәләр.

Явыз Иван тарафыннан үткәрелгән колониаль изү сәясәте коллар дәрәҗәсенә төшерелгән болгар-татар һәм рус булмаган башка җирле халыклар арасында көчле нәфрәт тудырган. Казан дәүләтен яңадан торгызу һәм Россия хакимлегеннән котылу өчен алар күп еллар буена каты көрәш алып барганнар.

Басып алучыларга каршы беренче баш күтәрүләр 1552—1557 елларда ук башланган. Болгар-татарлар һәм, аларга кушылып, мари, чуваш, мордва халыклары, куллырына корал алып, рус феодалларының милли изүенә каршы изге сугышка күтәрелгәннәр, үзләренә хан итеп Сөембикәнең энесе Али Әкрамны чакырып китергәннәр. Җансәет һәм Сарый батыр җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр отряды патша гаскәрләрен берничә тапкыр тар-мар иткән. Әмма яхшы коралланган 30 мең кешелек рус укчылары мондый фетнәләрне рәхимсез рәвештә бастырганнар. Баш күтәрүчеләрнең күбесе үтерелгән, ә 6 мең ир-атны, 15 мең хатын-кызны, бала-чаганы кол итеп, алып киткәннәр һәм рус феодалларына таратып бетергәннәр.

1572—1574 елларда Урта Идел буе халыкларының рус феодалларына каршы баш күтәрүләре дәвам итә. Көрәшне мари крестьяннары башлап җибәрәләр. Аларга тиздән болгар-татарлар, чувашлар, удмуртлар һәм башкортлар кушыла. Патша гаскәрләре бу фетнәне дә рәхимсез рәвештә бастыралар.

1582 елда милли-азатлык хәрәкәте яңа көч белән дөрләп китә. Явыз Иван, Мәскәүдә көчле гаскәр туплап, үзенең боярларын һәм воеводаларын фетнәчеләргә каршы җибәрә. Баш күтәрүчеләр «Алладан да курыкмыйча, Мәскәү гаскәре белән өзешеп сугыштылар,— дип хәбәр итә елъязмачы.— Яу кырындамы, станнардамы — бик күп урысларны кырып салдылар. Аларны боярлар һәм воеводалар да тынычландыра алмады». Сугышлар 1584 елда Явыз Иван патша үлгәч тынып тора. Әмма колониаль изү дәвам итә. Ачыктан-ачык басып алу, халык байлыгын талау, яндыру, юк итү, туган төбәгеннән куып, җирләрен алпавытларга өләшү, көчләп чукындыру тукталмый. Болгар-татарлар боларны бик авыр

кичерәләр. Халкыбыз милли фаҗигага эчендә яши.

1592 елда болгар-татарлар һәм мариларның күп кенә авыллары янәдән рус баскыннарына буйсынудан чыгалар. Шул заман тарихчысы болай дип яза: «Каһәр төшкән болгарлар безнең хакимиятебезне теләмичә тагын баш күтәрделәр. Федор патша үзенең идарәчесе Борис Годуновка Казан болгарларына каршы күп гаскәр җибәрергә кушты һәм алар болгарларны тәмам буйсынырга мәҗбүр иттеләр».

Шулай итеп, 16 нчы гасырның икенче яртысы халкыбыз тарихына рус патшаларының түзеп тора алмаслык җәберле изүләренә каршы күтәрелгән милли-азатлык сугышлары белән кереп калган. Халыкның изге максаты Явыз Иван тарафыннан 1552 елда канга батырылган һәм колония хәленә төшерелгән җиребезнең мөстәкыйльлеген кире кайтару булган. Бу тигез булмаган көрәштә безнең бабаларыбыз җиңелү ачысын кичергәннәр, ләкин җиңүгә булган өметләрен бервакытта да югалтмаганнар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Явыз Иван Казан җирләрендә болгар-татарларга каршы нинди сәясәт үткәргән? Колониаль һәм милли изүнең формаларын санап чыгыгыз.
2. 1552 елдан соң Казан шәһәре ничек үзгәрә?
3. Элеккеге Казан дәүләтендәге җирле халыклар милли изүгә каршы ничек көрәшәләр? Ничәнче елларда баш күтәрүләр була? Даталарны дәфтәрегезгә язып куегыз.

33. КРЕПОСТНОЙ ТӘРТИПЛӘР. 17 НЧЕ ГАСЫРДАГЫ КРЕСТЬЯН СУГЫШЛАРЫНДА БОЛГАР-ТАТАРЛАР

16—17 нче гасырларда Россиядә крепостной тәртипләр урнашкан. Ул чакларда җирләрнең барысы да патша, бояр, алпавыт, дворян һәм чиркәү башлыклары — эре феодаллар кулында булган. Урман-болыннарга кадәр алар милке булып исәпләнгән. Җир — кешеләр өчен яшәү чыганагы. Ә крестьян җирсез кая барсын? Җир эшкәртмичә, иген икмичә, аңар ничек яшәмәк кирәк? Шуңа күрә ул җирне, вакытлыча файдалану өчен дип, боярлардан һәм алпавытлардан алып торырга мәҗбүр булган. Крестьян шул җирдә үзенең хуҗалыгын алып барган: йорт салган, мал-туар асраган, иген иккән. Ул җир биләүче хуҗага бөтен яктан бәйле булып калган. Җир биргән өчен, крестьян беренче чиратта хуҗасының (барин-

ның) басуын сөрергә, чәчәргә һәм уңышын җыеп алырга тиеш булган. Бу мәҗбүри эшләрне барщина дип йөрткәннәр. Шушы барщина крестьянны тәмам чыгырыннан чыгарган! Аның үз җирләрен эшкәртергә бөтенләй диярлек вакыты калмаган. Ә вакытында чәчеп, вакытында җыеп алмагач, ашлык та бик уңмаган, көч-хәл белән кыш чыгарга җиткән.

Крестьяннар үзләренең комсыз хуҗаларына оброк та түләгәннәр: ит, май, йомырка һәм башка төрле продуктларның бер өлешен феодаллар файдасына җыеп торганнар. Моннан тыш хуҗа өчен кышка утын әзерлисе, яңа өй саласы, юллар, күперләр төзәтәсе һәм тагын әллә ни кадәр эшләр эшлисе бар. Крестьян бөтенесенә өлгерергә тиеш! Югыйсә, аны тотып кыйный да алган хуҗасы, гаиләсенннән аерып, башка хуҗага сатып җибәрергә дә күп сорамаган.

Элегрәк крестьяннар бер хуҗа ошамаса, икенчесенә күчеп китә алганнар. Ләкин мондый ирек тора-бара бетерелгән. Башта, җир биләүче феодалларның таләбе белән, крестьяннарга хуҗаларыннан елның бер вакытында, көз ахырында, игеннәр җыелып беткәч кенә китәргә рөхсәт итү турында закон чыккан. Тик крестьяннар хуҗадан киткәнче, аның җирендә яшәгән өчен бөтен бурычларын түләп бетерергә тиеш булганнар. 1649 елда кабул ителгән закон нигезендә аларны тулысынча крепостнойга әйләндергәннәр, ягъни җиргә һәм бер хуҗага гомерлеккә беркетеп куйганнар. Әгәр крепостной крестьян башка җиргә качып китсә, аны тотып каты җәзага хөкем иткәннәр һәи элекке хуҗасына кайтарып тапшырганнар.

Крепостной тәртипләр Россиянең колониясе булып киткән Болгар-Казан җирләрендә дә хөкем сөргән. Йомышлы һәм ясаклы татарлар, турыдан-туры алпавытларга буйсынмыйча, рус патшасына хезмәт иткәннәр һәм дәүләт казнасына салым түләгәннәр.

Казан җирендә крестьяннарның хәле тагын да авыррак булган, чөнки крепостной тәртипләргә милли изү дә өстәлгән. Элеккеге татар феодалларының (морзаларның) өстенлекләре әкренләп бетерелгән, аларны гади крестьян хәленә төшергәннәр. Мөселман динендәгеләрне эзәрлекләгәннәр, көчләп чукындырганнар, руслаштыру сәясәте үткәргәннәр, һәрьяклап кыерсытканнар. 1593 елда чыккан указ нигезендә бөтен мәчетләрне җимергәннәр. Боларның барысы да халыкның көчле ризасызлыгын китереп чыгарган.

* * *

1606—1607 елларда Россиянең үзәк районнарында крепостной тәртипләргә түзә алмаган крестьяннар баш күтәрергә мәҗбүр булалар. Алар отрядларга берләшә-



17 нче гасырдагы Казан күренеше. *А. Олеарий рәсеме.*

ләр. Чалгы, сәнәк һәм балталар белән коралланып, алпавытларга һөҗүм итәләр, утарларын яндыралар, җирләрен тартып алалар. Моңарчы күрелмәгән крестьяннар сугышы башлана. Аңа гади рус крестьяны, акыллы һәм батыр йөрәкле Иван Болотников җитәкчелек итә.

Болотников җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында болгар-татарлар, чувашлар, марилар, мордвалар актив катнашалар. Алар тарихта беренче тапкыр үзләренең изүчеләренә каршы рус крестьяннары белән бергәләп күтәреләләр. Фетнәчеләр Зөя, Алатырь, Курмыш, Темников, Арзамас һәм башка шәһәрләрне кулга төшерәләр.

Патша гаскәрләре белән каты сугышларда крестьяннар җиңелә. Ә Урта Идел буйларында көрәш 1616—1619 елларда да дәвам итә. Аның җитәкчесе Җангали Вәлиәхмәтов дигән кеше була. Ул зур гына отряд белән хөкүмәт гаскәрләренә һөҗүмнәр ясый, ләкин ахыр читкә җиңелүгә дучар була.

Шунысы игътибарга лаек: кайбер татар морзалары, крестьяннар



Тәтеш шәһәре күренеше. *А. Олеарий рәсеме.*

хәрәкәтеннән файдаланып, Казан ханлыгын яңадан торгызу өчен омтылыш ясап карыйлар. Әмма бу хыял чынга аша алмый, чөнки көчләр бик таркау була.

Крестьяннар сугышыннан тәмам куркуга төшкән патша хөкүмәте халыкларны талау һәм изү сәясәтен вакытлыча булса да йомшартып тора. Һәм озакка түгел. Милли изү бераздан тагын көчәя башлый. Җимертелгән мәчетләр урынына чиркәүләр, монастырьлар төзү дәвам итә. Чукынырга теләмәгән татар морзаларыннан крестьяннарын һәм җирләрен тартып алалар. Гади халыкның хөкүмәткә түли торган салымнарын арттыралар.

17 нче гасыр урталарында Кама аръягында Биләр, Яңа Чишмә, Кичү, Зәй, Минзәлә крепостьлары төзелә һәм алар арасында йөзәр чакрымнарга сузылган балчык, агач ныгытмалар барлыкка килә. Төзү эшләренә җирле халыкларны, шул исәптән ясаклы болгар-татарларны, көчләп куып китерәләр. Бу хәрби шәһәрчекләргә рус укчыларын (стрелецларны) һәм крестьяннарын күчереп утырталар. Болгар-татарлар күпләп яши торган төбәкләрдә калкып чыккан хәрби ныгытмалар крестьяннарның Россиядән көнчыгыш районнарга качуын туктату һәм җирле халык баш күтәргән очракта аларны бастыру өчен кирәк була.

* * *

1670—1671 елларда илдә яңадан крестьяннар сугышы кабынып

китә. Аңа Дон казагы Степан Разин җитәкчелек итә. Ул ярлыларны яклаучы, гади һәм кыю көрәшче була. Разинның канәчкеч байларны — алпавытларны, боярларны һәм воеводаларны кырып бетерергә чакырган өндәмәләре изелгән халыкны кузгатып җибәрә. Аның отрядына крепостной крестьяннар һәм шәһәр ярлылары агыла.

Степан Разин Мәскәүгә походын Әстерханнан башлый, Царицын (хәзерге Волгоград), Сарытау (Саратов), Самара шәһәрләрен ала һәм Сембергә якынлаша. Крестьяннар сугышының иң кызган һәм күп халыкны кузгаткан вакыты Урта Иделдә 1670 елның җәендә була. Сембергә килеп җиткәч, Степан Разин болгар-татарларга восстаниегә кушылырга чакырып хатлар җибәрә.

Аның отрядына, җир һәм ирек өчен көрәшүчеләрнең берсе булып, Кадом өязенең йомышлы татары Хәсән Айбулат улы Карачурин килеп кушыла. Ул Разинның якын киңәшчесенә әйләнә, аны Казанга барырга чакыра, мөселманнарга өндәмәләр, мөрәҗәгатьләр яза.

Хәсән Карачурин үзенең 6 мең кешелек отряды белән Степан Разин кул астында Сембер янында сугышлар алып бара. Хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан җиңелгәч, ул яңадан 15 мең кешелек отряд туплый. Бу отрядта Самара, Сарытау, Пенза, Алатырь, Курмыш һәм башка өязләрдән төрле милләт крестьяннары катнаша. Хөкүмәт гаскәрләре белән сугышта Хәсән Карачурин тагын җиңелә. Ләкин ул бу юлы да каушап калмый. Рус атаманы Алексей Савельев белән берлектә, алар 20 меңлек крестьян армиясе җыялар! Бөтен җирдә алпавыт утарлары дөрләп яна. Крестьяннар үзләренең изүчеләреннән үч алалар. Безнең якларда көчле сугышлар Зөя, Буа, Тәтеш тирәсендәге авылларда, хәзерге Апас районының Куланга, Чүти авыллары тирәсендә булып уза.

Патша фетнәчеләргә каршы пушкалар белән коралланган атлы гаскәр җибәрә. Көчле хәрби крепость буларак, Казан крестьяннар сугышына каршы көрәшнең төп үзәгенә әверелә. Кенәз Барятинский командалыгындагы хөкүмәт гаскәрләре фетнәчеләрне бастыруда бигрәк тә актив катнаша. Алар баш күтәрүчеләрне дистәләп, йөзәрләп асалар, төрмәләргә ябалар, авылларына ут төртәләр. Степан Разинны Мәскәүгә алып килеп, каты җәзалаулардан соң, Кызыл мәйданда асып үтергәннәр. Хәсән Карачуринның башта кулларын, аякларын, аннан соң башын чабып өзгәннәр.

Крестьяннар сугышы бастырыла. Әмма патшаның рәхимсез үч алуы халыкны куркытмый. Изүчеләргә каршы нәфрәт көчәя генә бара.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Крепостной тәртипләрне сез ничек аңлыйсыз? Нәрсә ул барщина, оброк?
2. Иван Болотников җитәкчелегендәге беренче крестьяннар сугышында болгар-татарлар ни өчен актив катнашалар?
3. Степан Разин җитәкчелегендәге икенче крестьяннар сугышында татарларның катнашуы турында сөйләгез. Кем ул Хәсән Карачурин?
4. Крестьяннар нилектән җиңеләләр? Бу сугышларның тарихта нинди әһәмияте бар?

34. 18 НЧЕ ГАСЫРДА КАЗАН ГУБЕРНАСЫ ҺӘМ АНЫҢ ХАЛКЫ

18 нче гасырның башларында, Петр I патшалык иткән вакытта, Россиядә җитди үзгәрешләр барлыкка килә. 1708 елда «Казан патшалыгы» дигән исем бетерелеп, аның урынына Казан губернасы төзелә. Бояр-воеводаларга, укчы полкларның начальникларына алмашка кулына чиксез власть туплаган губернатор һәм яхшы өйрәтелгән армия башында торучы генераллар килә.

Казан губернасының җирләре бик зур булган. Бу чорда аның чикләре төньякта Костромага, көнчыгышта Урал тауларына, көнбатышта Муромга һәм Пензага, ә көньякта Кавказ тауларына диярлек барып җиткән. Патша указы нигезендә, бераз соңрак, күбесенчә болгар-татарлар яши торган Минзәлә һәм Бөгелмә өязләрен яңа оештырылган Оренбург губернасына, ә Сембер һәм Пенза төбәкләрен Сембер губернасына күчерәләр.

Казан губернасында төрле милләт халыклары яшәгән. Казан, Зөя, Лаеш, Спас, Чистай һәм кайбер башка өязләрдә, ягъни Идел-Кама буйларында урнашкан төбәкләрдә, борынгы Болгар дәүләтенең төп җирләрендә, килмешәк руслар күпчелекне тәшкил иткән. 18 нче йөздә хәзерге Татарстан территориясендә һәр 100 кешенең кырыгы болгар-татар булган.

Тырыш халыкның хезмәте нәтиҗәсендә Казан губернасы хуҗалык үсеше ягыннан Россиядә алдынгы урыннарның берсен тоткан. Икътисади тормышның нигезен авыл хуҗалыгы — игенчелек һәм терлекчелек — тәшкил иткән. Яңадан-яңа җирләр үзләштерелгән. Ашлыкны читкә чыгарып сату өчен дә күпләп игә башлаганнар. Чөнки дәүләткә салымнарны оброк сыйфатында, әйберләтә генә түгел, акчалата да түләгәннәр. Икмәкне якын тирәдәге өязләрдән җыеп, Казаннан Россиянең бик күп шәһәрләренә озата торган булганнар.

Шәһәрләрдә һәм авылларда һөнәрчелек, бигрәк тә күн, тире эшкәртү, төрле тукымалар, сабын, шәм, бизәнү әйберләре эшләү нык

үскән. Һөнәрчеләр ясаган әйберләр базарга чыгарылган. Күп кенә җирләрдә бакыр кою заводлары төзелгән. Минзәлә, Зәй, Әлмәт, Бөгелмә һәм башка төбәкләрдә бакыр чыгару рудниклары барлыкка килгән.

18 нче гасыр урталарында Казанда һәм кайбер башка шәһәрләрдә эре промышленность мануфактуралары — дистәләгән, хәтта йөзләгән кешеләр эшли торган зур һөнәр мастерскойлары, чын завод-фабрикалар үсеп чыккан. Аларны, кул көче белән эшләгәнгә күрә, мануфактура дип атаганнар. Шундый мануфактураларның берсе — сукно фабрикасы Казанда 1714 елда ук төзелгән. Бу мануфактураларның кайберләрендә крепостной крестьяннарны көчләп эшләткәннәр, ә кайберләрендә яллы хезмәт кулланылган. Аларда күпчелек хөкүмәткә акчалата салым түләп торырга тиешле элекке ясаклы татарлар, дәүләт крестьяннары ялланганнар.Аларда эшләүчеләрнең дә тормышлары түзә алмаслык авыр булган. Мәсәлән, сукно мануфактурасында йон язучылар, эрләүчеләр, тукучылар һәм буяучылар караңгы, юеш, пычрак һәм салкын биналарда тәүлегенә 18 әр сәгать эшләгәннәр. Моның өчен аларны бераз ашатканнар һәм аз гына акча түләгәннәр. Кечкенә генә гаеп өчен дә кыйнаганнар. Мануфактураның хәтта үз төрмәсе дә булган. Гаепле кешеләрне, аякларына богаулар кидереп, чылбырга бәйләп куйганнар.

Авыл хуҗалыгының һәм промышленностьның кызу темплар белән үсеше сәүдә үсешенә уңай йогынты ясаган. Болгар-татарлар — элек-электән үк сәүдәгә хирыс кешеләр. Ләкин патша хөкүмәте аларга бу эш белән иркенләп шөгыльләнергә мөмкинлек бирмәгән. Шуңа да карамастан, Казан 18 нче йөздә Россиянең иң эре сәүдә үзәкләренең берсе булып киткән. Биредә 700 гә якын рус һәм 600 ләп татар сәүдәгәре исәпләнгән. Чистай да сәүдәгәрләр шәһәре төсендә дан тоткан, 500 дән артык сәүдәгәрнең 300 гә якыны татар булган. Алар күбесенчә икмәк сату белән шөгыльләнгәннәр. Бай сәүдәгәрләр Россиянең төрле өлкәләренә генә түгел, чит илләргә дә, бигрәк тә Урта Азия, Иран, Һиндстан, Кытай кебек илләргә төрле товарлар чыгарганнар һәм сатып алып кайтканнар.

Авыл хуҗалыгы, промышленность һәм сәүдә өлкәсендә ирешелгән уңышларга карамастан, Казан губернасында яшәүче халыкларның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе әллә ни яхшырмаган.

Сөрүлек җирләренең күп өлеше элеккечә казна (дәүләт) кулында калган. Ул җирләрне бик күп салым һәм акчалата налоглар түләү исәбенә дәүләт крестьяннарына биреп торганнар. Шул ук вакытта җир биләүче алпавытлар күбәй-

гән. Алар төрле ялган юллар белән, ахыр чиктә көч кулланып булса да, рус булмаган халыкларның җирләрен тартып алганнар. 18 нче гасырның икенче яртысында хәзерге Татарстан җирләрендә 832 рус алпавыты була. Аларның кайберләре, мәсәлән, Нарышкин, Молоствов, Толстой кебекләре, берничә мең крепостной крестьян тотканнар.

Крепостной крестьяннар бик аяныч хәлдә яшиләр. Аларның күбесе атна буе диярлек барщинада эшли, оброк түли, бер өлеше алпавыт йортында бил бөгә. Бай алпавытның дистәләрчә хезмәтчеләре булган. Алар аш пешергәннәр, кер юганнар, киндер сукканнар, киемнәр теккәннәр. Крестьяннарның бер хокукы да калмаган: аларны сатарга һәм сатып алырга, бүләк итәргә, әйбергә алмаштырырга, җәзага тартырга мөмкин булган.

Дәүләт крестьяннары да җиңел яшәмәгәннәр. Петр I патшалык иткәндә йорт башыннан түләнә торган салымнар урынына җан башыннан салым җыю тәртибе кертелгән. Ул элеккегә караганда берничә тапкыр авыррак булган. Христиан динен кабул иткән кешеләрне берничә елга салымнардан азат иткәннәр. Элек мәҗүсиләр булган мари, чуваш, удмурт, мордва халыклары көчләү нәтиҗәсендә бөтенесе диярлек христиан диненә күчеп беткәннәр. Ә салымнарны алар өчен мөселманнар түләп торырга тиеш булган. 1736—1740 елларда патша хөкүмәтенә икмәкләтә налогны рус булмаган халык русларга караганда ике тапкыр артык түләгән. Моннан тыш дәүләт крестьяннары тегермән тоткан, урман-болыннардан файдаланган, хәтта елгаларда балык тоткан өчен, казнага махсус оброк керткәннәр. Сугышлар һәм хәрби өйрәнүләр вакытында алар атлы гаскәрләрне фураж, олаулар, сбруйлар белән тәэмин итеп торганнар.

Патша хезмәтенә ел саен рекрутлар (солдатлар) җибәрү, меңләгән кешеләрне төрле крепостьлар, диңгез һәм елга портлары, каналлар төзү кебек эшләргә куу крестьяннарны бөтенләй бөлгенлеккә төшергән. Мәсәлән, 1703 елда Петербургка нигез салынгач, анда эшләргә ел саен 5 меңләп татар кешесе җибәрелә торган булган.

Казан тирәсендә бик яхшы имән һәм нарат урманнары булуы, биредә күптәннән бирле елга кораблары төзелү Петр патшаны гел кызыктырып килгән. Аның әмере буенча Казан янында адмиралтейство корыла. Монда Россиянең хәрби флоты өчен зур-зур кораблар, баржалар, суднолар төзелгән. Адмиралтействогa бик күп крестьяннар беркетелгән, аларның саны 18 нче йөз ахырына 100 мең кешегә якынлашкан. Эшчеләрнең күбесе болгар-татарлар, чувашлар, марилардан торган. Алар агач хә-

зерләүдә иң авыр эшләрне башкарганнар. Бигрәк тә урман кисүчеләрнең — лашманнарның хезмәте авыр булган. Бу эшләргә 15 яшьтән алып 60 яшькәчә ир-атларны җыйганнар. Лашманнар үзләренең коточкыч авыр тормышлары турында җырлар, бәетләр чыгарганнар:

— Лашман эшен нужа диләр
аннан кайткан кешеләр,
Кар урманда кар эчендә алар
бар да өшиләр.
Лашман эшенә киткәндә
елый-елый баралар,
Бәхетсезгә — вакытсыз ди,
шунда үлеп калалар.
Бу лашманның тарихын күбрәк
язарга кирәк,
Исән барып, сау кайтучы лашман
эшеннән сирәк.

* * *

Күргәнебезчә, болгар-татар халкы, башка халыклар кебек үк, 18 нче гасырда да хәерчелектә яшәгән. Тормыш авырайганнан-авырая барган. Шуның өстенә рус хөкүмәтенең Явыз Иваннан башланган милли колониаль изүе дә дәвам иткән.

Петр I 1713 елда болгар-татарларның йомышлылыларын ярты ел эчендә чукындырып бетерергә әмер бирә. Чукынган кешеләргә төрле өстенлекләр вәгъдә итә. 1742 елда Казан губернасындагы яңа салынган барлык мәчетләрне җимереп бетерергә, яңаларын салмаска дигән закон чыга. Ике ай эчендә Казан өязендә 536 мәчеттән 418 ен җимереп ташлаганнар. Мәчетләр белән бергә мәктәп-мәдрәсәләрне дә юкка чыгарганнар. Поплар, татар авылларына чыгып, кешеләрне көчләп чукындырып йөргәннәр. Чукынырга теләмәгәннәрне кыйнаганнар, өйләренең ишек-тәрәзәләрен ватып, мичләрен җимереп чыкканнар. Авылда берничә кеше рус диненә күчсә, анда тиз арада чиркәү салдырып куйганнар. Казанның татар бистәләрендә дә җимертелгән мәчетләр урынына чиркәүләр төзегәннәр, зиратлардагы кабер ташларын ватып бетергәннәр. Мөселманнарга ана телендә укырга-язарга рөхсәт ителмәгән, аларның милли хисләрен мыскыллаганнар.

Крепостной тәртипләрнең, милли һәм колониаль изүнең көчәюе халыклар арасында законлы ризасызлык тудырган. Крестьяннар хәрәкәте беркайчан да тукталып тормаган. Милли-азатлык көрәше дәвам иткән. Мәсәлән, 1704—1711 елларда хәзерге Татарстан һәм Башкортстан җирләрендә булып үткән Алдар-Күчем фетнәсе вакытында Морат Солтан дигән берәүне хәтта Казан җиренең патшасы итеп сайлыйлар. Болгар-татарлар үзләренең данлы тарихын тиз генә онытмаганнар, һаман Россиядән аерылып чыгып, мөстәкыйль дәүләт булып яшәргә омтылганнар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 18 нче гасырда Казан губернасында авыл хуҗалыгы, промышленность һәм сәүдә эшенең үсеше турында сөйләгез.
2. Алпавыт крестьяннарының һәм дәүләт крестьяннарының тормыш хәле ничек булган? Алар нинди эшләр башкарганнар һәм хөкүмәткә нинди салымнар түләп торганнар?
3. Рус булмаган халыкларны, бигрәк тә болгар-татарларны милли изү ничек алып барылган?
4. Болгар-татарларның мөстәкыйль дәүләтне торгызуга булган омтылышлары нидә күренә?

35. БАТЫРША ВОССТАНИЕСЕ. ПУГАЧЕВ ЯУЛАРЫНДА БОЛГАР-ТАТАРЛАР

Халкыбызның 18 нче гасырдагы тарихы канечкеч патша самодержавиесенә һәм ул үткәргән милли-колониаль изүгә каршы көрәш сәхифәләре белән тулы.

Шундый көрәшләрнең берсе Батырша исеме белән бәйләнгән. Батырша (аның чын исеме Абдулла Гали углы) 1715 елда Башкортстанның хәзерге Балтач районы Карыш авылында татар гаиләсендә туган. 1733—1743 елларда Татарстанның хәзерге Әлмәт районындагы Тайсуган һәм Арча районының Ташкичү авылы мәдрәсәләрендә укыган. Искиткеч тырыш һәм зирәк акыллы Абдулла тиздән зур белемле гыйлем иясе, мөгаллим дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Болгар-татарларны көчләп чукындырулар, мәчет-мәдрәсәләрне җимерүләр, мөселман халкын христиан диненә күчкән кешеләр (керәшеннәр) исәбенә өстәмә салымнар түләтеп интектерүләр — боларның барысы да Абдулланың күз алдыннан үткән һәм аның күңелендә изүчеләргә каршы чиксез нәфрәт үстергән. Мондый хәлләргә түзә алмыйча, болгар-татар һәм башкорт крестьяннарының әледән-әле баш күтәрүләрен ул ишетеп-күреп торган. 1735—1736 елларда булып үткән шундый фетнәләрдән соң, мәсәлән, русларның җәза отрядлары 700 ләп татар һәм башкорт авылын яндыралар, 9 меңнән артык хатын-кызны, бала-чаганы рус алпавытларына коллыкка озаталар, 3400 кешене каторгага җибәрәләр. 17 меңләп кеше һәлак була.

Батыр йөрәкле, тәвәккәл Абдулла гомеренең ахырына кадәр халыкның азатлыгы өчен, гаделлек өчен көрәшергә ант итә. Ул Казан, Оренбург, Уфа, Троицк якларына чыгып китә, рус патшасы үткәрә торган милли изү сәясәтен аңлатып, халыкка өндәмә язып тарата. Аны һәр җирдә көтеп алалар, яратып, Батыр шаһ — Батырша дип йөртәләр. Кайда гына булмасын, Батырша халыкны баш күтәрергә чакыра. Русларның хакимлеген бетереп, галим-голәмә ке-

шеләребезнең идарә итүен булдырырга, мөселманнар мәҗлесе оештырырга өнди. Һәр җирдә бу өндәүләрне зур хуплау белән каршы алганнар.

1755 елда Башкортстанның күп кенә төбәкләрендә крестьяннар хәрәкәте башланып китә. Фетнәчеләр патша хөкүмәте куйган старшиналарны, налог җыючыларны үтерәләр, хәрби крепостьларга, почта станнарына һөҗүмнәр оештыралар. Утарлар яна. Бөтен төбәк кайный. Губернатор куркуга кала. Батырша төзегән план нигезендә бу хәрәкәт, Кама буйлап барып, Казан татарлары арасына да таралырга тиеш була. Ләкин баш күтәрүчеләр арасында оешу җитми. Фетнә рус гаскәрләре тарафыннан бастырыла. Батыршаны тотып төрмәгә ябалар һәм ул шунда үлә.

Шулай да Батырша восстаниесенең бик зур тарихи әһәмияте бар. Восстаниенең бөтен әйләнә-тирәгә таралып китү ихтималы патшаның котын алган. Ул чукынган кешеләре булган авыллардан мөселман халкын куып җибәрүне ашыгыч төстә туктаткан, керәшеннәр өчен алардан налог түләтүне бетергән, хәтта авылларда яңа мәчетләр салырга рөхсәт итә торган указ чыгарган.

Татар-башкорт халыкларын алдагы көрәшләргә хәзерләүдә дә аның әһәмияте зур була. Батыршаның, рус түрәләрен куып, болгар-татарларның һәм башкортларның мөстәкыйль хакимиятен урнаштырырга өндәмәсе күпләр тарафыннан кайнар яклау таба. Мәсәлән, 1760 елларда Морат мулла үзе язып-күчереп тараткан китапларда Болгар дәүләтен яңадан торгызырга вакыт җитте, дип халыкны милли-азатлык сугышына үгетләгән.

Е. И. Пугачев.

Ләкин гади халык гомере буе рәхәт күрмичә ничек кенә изелеп яшәмәсен, ул иң элек «яхшы» патша турында хыялланган. Авылда алпавытларның халыкны ничек талаганын, җәберләгәнен патша белми, янәсе. Белсә, ул мондый хәлләргә түзмәс, чик куяр, гаделсезлекне бетерер иде, дип уйлаган.

* * *

Менә 1773 елның көзендә, Екатерина II патшалык иткән заманда, Урал казаклары арасында үзен Петр I патшаның оныгы — Петр III дип таныткан бер кеше килеп чыга. Чынлыкта исә ул Дон казагы Емельян Иванович Пугачев була. Ул халыкны көрәшкә чакыра. «Мин сезгә җирләрегезне, суыгызны, урман-болыннарыгызны кайтарып бирермен, барыгыз да иреккә чыгарсыз», дип манифестлар, өндәмә хатлар язып, авылларга тарата.

Урал һәм Идел буенда яшәгән хезмәт иясе халкы: руслар, болгар-татарлар, башкортлар, марилар, чувашлар, удмуртлар, төркем-төркем булып, Пугачев армиясенә агыла. Җаек елгасыннан алып Оренбург крепостена кадәр булган җирләрдә крестьяннар сугышы башлана. Баш күтәрүчеләр Оренбург һәм Җаек крепостьларын камап алалар. Урал заводларының крепостной эшчеләре дә фетнәчеләр ягына чыга. Алар Пугачев армиясен туплар һәм мылтыклар белән тәэмин итеп торалар.

Хәзерге Татарстан җирләрендә крестьяннар хәрәкәте 1773 елның октябрь — ноябрь айларында җәелеп китә. Казан — Арча тирәләрендә Мәсәгут Гомәров җитәкчелегендәге зур бер отряд хәрәкәт итә. Бөгелмә төбәге тулысынча диярлек баш күтәрүчеләр кулында була. Минзәлә крепостен Каранай Муратов җитәкчелегендәге 10 мең кешелек фетнәчеләр отряды дүрт ай буена камалышта тота. Берничә тапкыр штурмлап та карыйлар, әмма ала алмыйлар. Зәй крепосте исә баш күтәрүчеләргә сугышсызнисез бирелергә мәҗбүр була.

Кама һәм Урта Идел буенда да тынычлык бетә. Бигрәк тә Алабуга, Әгерҗе, Кукмара якларында көчле чуалышлар куба. Крестьяннар байларның утарларын яндыралар, җирләрен тартып алалар, үзләрен асып үтерәләр.

Пугачев гаскәре 1774 елның 29 июнендә Әгерҗегә килеп җитә. Крестьяннар сугышы моңарчы күрелмәгән көч белән дөрләп китә. Әгерҗе халкы Пугачевны «үзебезнең гадел патша Петр Федорович» дип хөрмәтләп каршы ала. Авыл уртасындагы мәчет мәйданында учак ягып зур казан асалар. Кайсы тавык, кайсы каз-үрдәк һәм башка төрле ризык-сый чыгарып, бай табын әзерлиләр. «Гадел патша»га кадер-хөрмәт күрсәтеп алгач, мәйданның бер ягына Пугачев армиясенә кушылырга килгән крестьяннар тезелеп баса, икенче ягына тиз генә дар агачы ясап куялар. Гади халыкның күрсәтүе белән кулга алынган комсыз байларны Пугачев астырып үтертә. Крестьяннар үзләренең изүчеләреннән шулай үч алганнар.

Әгерҗедән Пугачев армиясе Алабуга, Мамадыш, Арча аркылы Казанга юл тоткан. Крестьяннарга

ул, Казанны алгач, Мәскәүгә китәбез, тәхетне алып, бөтен Россиядә гадел патшалык урнаштырырбыз, дип вәгъдәләр биргән. Болгар-татарларга үз диннәрен тотарга, милли гореф-гадәтләре белән яшәргә хокук вәгъдә иткән. «Алпавыт һәм башка изүчеләрне кырып бетерегез, үзегез теләгәнчә иректә яшәгез»,— дип чакырып язган хатлар Урта Идел халыкларының Пугачев армиясенә күпләп кушылуына сәбәп булган. Һәр җирдә халык аны, кадерле кунак кебек, ипи-тоз белән каршы алган.

1774 елның 12 июлендә Пугачевның 20 меңлек гаскәре Казанга керә. Кремльне тупка тота башлыйлар. Бөтен яктан туктаусыз мылтык аткан тавышлар ишетелеп тора. Кремль эченә яшеренгән хөкүмәт гаскәрләре фетнәчеләргә каршы ут ачалар. Шулвакыт шәһәр төрле яктан яна башлый. Крестьяннар һәм аларга кушылган шәһәр халкы байлар яшәгән йортларны көл-күмер итәләр. 2 меңнән артык йорт, 800 ләп кибет, 30 лап чиркәү һәм башка төрле биналар янып юкка чыга. Ләкин ут-төтен эчендә кремльне штурмлау мөмкин булмый. Кичкә таба Пугачев гаскәрен шәһәрдән чыгарырга мәҗбүр була.

Кич алар полковник Михельсон командалыгындагы хөкүмәт отрядлары белән кара-каршы очрашалар. Канкойгыч сугышлар берничә көн дәвам итә. Баш күтәрүчеләр җиңеләләр. Пугачев үзенең армиясе белән Казан яныннан Иделгә таба качып китә.

Пугачев Татарстан җирләрендә, бигрәк тә Казанда булган көннәрдә руслар һәм болгар-татарлар, башкортлар, марилар һәм чувашлар үзләренең изүчеләренә каршы иңгә-иң торып сугышканнар. Бу көрәштә крестьяннарның сыйнфый бердәмлеге ныгыган. Алар арасыннан Бәхтияр Канкаев, Мәсәгут Гомәров, Каранай Муратов, Муса Мостафин, Әбҗәлил Сөләйманов кебек чын халык геройлары үсеп чыга.

Екатерина II баш күтәрүчеләргә каршы зур гаскәр җибәрә. Царицын шәһәреннән ерак түгел бер урында Пугачев патша гаскәрләре тарафыннан җиңелә. Аны тотып алалар, богауланган хәлдә тимер читлеккә ябып, Мәскәүгә китерәләр һәм җәзалап үтерәләр.

Крестьяннар сугышы бастырыла. Патша һәм алпавытлар фетнәчеләрдән ерткычларча үч алалар. Әмма каһарман бабаларыбыз хатирәсе халык күңелендә мәңге саклана.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Кем ул Батырша һәм ул нәрсә өчен көрәшкән?
2. Ул оештырган восстаниенең болгар-татарлар өчен нинди нәтиҗәсе була?

3. Ни өчен Емельян Пугачев үзен Петр III патша дип танытырга мәҗбүр булган? Халыкка улниләр вәгъдә иткән?
4. Безнең якларда Пугачев армиясе һәм восстаниечеләрнең аерым отрядлары булган урыннарны картадан күрсәтеп сөйләгез.
5. Сез яши торган төбәкләрдә Пугачев яулары булмаганмы? Нинди риваятьләр сакланып калган?

36. 1812 ЕЛГЫ РУС-ФРАНЦУЗ СУГЫШЫНДА ТАТАРЛАР

Еллар бер-бер артлы узган. Крестьяннар сугышыннан соң тормыш әкренләп үз җаена кергән. Россия тәхетендә патшалар алышына торган. Дворяннар, зиннәтле сарайларда баллар үткәреп, кайгы-хәсрәт күрмичә, кәеф-сафа корып яшәгәннәр. Гади халык барщинада һаман билен бөккән, елдан-ел күбәя барган завод-фабрикаларда иң кара эшләрне башкарган.

19 нчы гасыр башында Россия империясе һәм аның халыклары зур куркыныч алдында калалар. Франция императоры Наполеон Бонапарт, яхшы коралланган күпсанлы армия туплап, Европада басып алу сугышлары башлап җибәрә. Күп кенә дәүләтләрне үзенә буйсындырып, ул Россия чикләренә якынлаша. «Өч елдан мин бөтен дөньяның хакиме булачакмын,— дип күкрәк кага Наполеон.— Хәзергә Россия генә кала, ләкин мин аны сытып юк итәчәкмен!»

1812 елның июнь аенда 456 мең кешеле француз армиясе Неман елгасын кичә һәм, сугыш игълан итеп тормыйча, Россиянең көнбатыш чикләренә үтеп керә. Рус гаскәрләре французларга караганда өч тапкыр азрак була. Шуңа күрә алар, дошманның кысрыклавына түзә алмыйча, чигенәләр һәм сугышның башлануын булдырмаска тырышалар.

Французлар белән сугыш башлану турындагы манифест И. Хәлфин тәрҗемәсендә татарча бастырылып халыкка таратыла. Россиянең бөтен халкы азатлык сугышына күтәрелә. Рус тарихында аны Ватан сугышы дип атадылар. Дошман басып алган җирләрдә партизан отрядлары оеша. Партизаннар француз гаскәрләренә көтмәгәндә һөҗүмнәр ясыйлар, алар үтә торган юллардагы авылларны яндыралар, дошман кулына эләгердәй бер нәрсәне дә калдырмыйлар. Наполеон армиясе күп югалтулар кичерсә дә һаман алга бара һәм Мәскәүгә якынлаша.

Шушы авыр көннәрдә рус армиясенең башкомандующие итеп талантлы һәм тәҗрибәле полководец Михаил Илларионович Кутузов билгеләнә. Ул үзенең армиясен французлар белән хәлиткеч бәрелешкә әзерли башлый. 26 августның таңында Мәскәүдән 120 чакрымдагы Бородино авылы

янында ике яктан да дәһшәтле һөҗүм башлана.

...Дошман туплары гөрелтесеннән җирләр селкенә, күк йөзен төтен һәм тузан болыты каплап ала. Атлар кешни, яраланган солдатлар ыңгырыша. Әле тегендә, әле монда офицерларның команда тавышлары яңгырый. Сугыш көне буе дәвам итә. Кич җитә. Бородино кыры коточкыч күренешкә керә. Французларның шуңарчы беркайчан да бу кадәр күп кеше кырылганын күргәне булмый. Бер көн эчендә генә дә русларның 44 мең, французларның 58 меңнән артык солдаты һәлак була. Соңыннан Наполеон: «Мин катнашкан сугышларның иң яманы Бородино кырында булды»,— дип искә ала.

Руслар шулай да җиңеләләр, әмма французлар да үзләренең максатларына ирешә алмыйлар: рус армиясе исән кала. Кутузов Наполеон белән кабат очрашырга теләмичә, Мәскәүне дошман кулына сугышсыз гына бирергә, дигән карарга килә. «Мәскәүне югалту Россияне югалту дигән сүз түгел. Армияне саклап калырга кирәк!» — ди ул.

Сентябрь башында Кутузов армиясе Мәскәүне калдырып чыга. Шәһәр халкы да солдатлар артыннан иярә. Бушап калган шәһәргә дошман гаскәрләре кереп тула. Мәскәү яндырыла, талана. Рус халкы үзенең иң авыр һәм фаҗигале көннәрен кичерә.

Россиянең барлык төбәкләрендә дошманга каршы көчле хәрәкәт башлана. Казан губернасында яшәүче халыклар да бу хәрәкәттән читтә калмый. Күпләр үзләре теләп сугыш кырына китәләр. Наполеон яулары Мәскәүгә якынлаша башлагач, Казанда халык ополчениесе җыела. Бу ополчениегә рус, татар, чуваш авылларыннан килгән крестьяннар, мануфактура эшчеләре керә. Казанның шул чордагы язучысы В. Панаев язганча, халык ополчениесе «бердәм омтылыш белән бик тиз оешты: картлар да, яшьләр дә бер байрак астына басты». 3300 кешелек ополчение сугышчыларын шәһәр халкы кремль янында тантаналы төстә озатып кала. Шул вакытта меңәр кешедән торган тагын ике батальон оештырыла. Аларның берсе — атлылар батальоны — татар крестьяннарын берләштергән.

Казан халкы француз илбасарларын тизрәк Россия җирләреннән куып чыгару өчен көчен кызганмый. Мәскәүдән качып киткән бик күп кешеләрне Казан үзенә кабул итә. Кремльдә туплар коя торган махсус завод төзелә. Сукно мануфактурасында көне-төне эш кайный. Эшчеләр, «сугышчыларыбызга мич кебек җылыта торган сукно әлгертик», дип тырышалар. Армиягә кирәкле әйберләрне озату өчен үз атларын, арбаларын биреп торырга теләк белдергән авыл кешеләре Казан юлын-



Мәскәү янындагы сугыш. 1812 елның октябре. *А. Адам рәсеме.*

нан өзелеп тормый. Бөтен җирдә сугышчылар өчен икмәк, фураж, кием-салым җыю башлана. Хатын-кызлар үзләренең алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләрен иганә фондына тапшыралар. Халыктан 346 мең сум акча җыела. Ул чор өчен бу бик зур сумма була.

Бөтен Россиядә кабынып киткән патриотик күтәрелеш нәтиҗәсендә француз армиясе Мәскәүдә озак тора алмый. Октябрь аенда алар шәһәрне ташлап чигенергә мәҗбүр булалар. Наполеон, армиясен Россиянең сугыш үтмәгән җирләреннән алып китәргә теләп, көньякка борылмакчы була. Әмма Кутузов аның планына каршы төшә. Каты сугышлардан соң, французлар Мәскәүгә килгәндә үзләре талаган җирләр аша чигенергә мәҗбүр булалар. «Җиңелмәс» Наполеон армиясе әкренләп юкка чыга бара: ачлык башлана, һәръяклап партизаннар һөҗүм итеп тора, каты салкыннарга күнекмәгән солдатлар кырылалар. Татар атлы гаскәрләре, кинәт һөҗүм итеп, французларга бик күп зыян китерәләр. Ноябрь аенда Белоруссиядәге Березина елгасын кичкән вакытта, Россия җирендәге соңгы бәрелештә французлар ягыннан һәлак булучылар бигрәк тә күп була. Наполеонның кайчандыр 500 меңләп гаскәреннән 30 меңләбе генә Россия чикләрен исән-имин үтеп чыга ала.

Шулай итеп, 1812 елгы рус-

Рус гаскәрләре һөҗүме. *П. Лалоз рәсеме.*

француз сугышы Россия халыкларының уртак җиңүе белән тәмамлана.

М. И. Кутузов армиясе Көнбатыш Европа илләрен французлардан азат итүдә актив көрәшә. Бу сугышларда безнең Казан ополчениесе солдатлары да катнашкан. Дрезденны азат итү өчен барган сугышларда алар чын батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Казаннан чыккан атлы батальон сугышчыларының Мерзебург һәм Гамбург шәһәрләрен азат итүдә үзүзләрен аямыйча көрәшүе хәтта француз генералларын да шаккатырган.

1812 елгы сугыш батырлары арасында Надежда Андреевна Дурова да була. 1806 елда ул Сарапул шәһәрендәге ата-анасы йортыннан качып китә һәм, ирләр киеме киенеп, Александр Соколов исеме белән казаклар полкына килә. Ватан сугышы башлангач, бу батыр «егетне» эскадрон командиры итеп куялар. Аның хатын-кыз икәнен Кутузов белеп ала. Хатын-кызның армия сафларында хезмәт итеп йөрүе, бигрәк тә сугыш вакытында, гадәттән тыш хәл булса да, Кутузов аны үзенең ординарецы итеп билгели. Дурова-Соколов башкомандующийның ординарецы булып Бородино кырында сугыша, соңыннан Көнбатыш Европада Гамбург һәм Прага шәһәрләрен французлардан азат итүдә катнаша.

Сугыш беткәч, ул Россиягә кайта һәм озак еллар буе Алабуга шәһәрендә яши, «Кавалерист кыз язмалары» дигән истәлекләр китабы яза. Н. И. Дурова 1866 елда 83 яшендә үлә. Аның каберен әле дә Алабуганың шәһәр паркында күрергә мөмкин.

Татар халкының 1812 елгы рус-француз сугышында катнашуы тарихыбызда эзсез генә югалмаган. Бу вакыйгалар турында җырлар-бәетләр чыгарганнар. Буыннан-буынга күчеп, алар безнең көннәргә тикле килеп җиткәннәр:

Французлар килеп кергән Мәскәү
дигән калага,
Безнең гаскәр килгәчтен,
качты алар далага.

Мәскәүгә дә кердек без,
Наполеонны күрдек без,
Французларны җиңгәндә җир
җимереп йөрдек без.

Французның илләре,
түгәрәк икән күлләре,
Французларны куганда үттек
без күп илләрне.

Дүрт-биш кердек сугышка,
каннар билдин актылар.
Сугышларны бетергәч,
безгә медаль тактылар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен 1812 елгы рус-француз сугышы тарихта Ватан сугышы, халык сугышы дип атала?

2. Аның төп вакыйгаларын кыскача гына тасвирлап бирегез.
3. Казан губернасы халыклары, шул исәптән татарлар, бу сугышта ничек катнашалар?
4. Кем ул Надежда Дурова? Аның батырлыгы турында сөйләгез.

37. КРЕПОСТНОЙ ТӘРТИПЛӘРНЕ БЕТЕРҮ ӨЧЕН КӨРӘШ

Россияне һәм Европаны коллыкка төшүдән коткарып калган герой солдатлар, сугыштан соң шатланышып, рухи күтәренкелек белән өйләренә таралышалар. Алар, патша безнең хәлне инде җиңеләйтер, крепостной тәртипләрне бетерер, дип өметләнәләр. Тик акланмый бу өметләр. Патша да, алпавытлар да крестьяннарның тормышын яхшырту өчен артык борчылмыйлар. Киресенчә, сәүдә үскән, чит ил базарларына ашлык чыгару арткан саен крестьяннарны изү көчәя барган.

Крестьяннарны тагын да күбрәк эшләтү өчен, аларны чыбыркылар белән кыйнаганнар, чыбык белән суктырганнар, башка төрле җәзаларга тартканнар. Крепостной крестьяннарның хәлләре колларныкыннан берни белән дә аерылмаган диярлек. Аларны сату турындагы белдерүләрне шул вакытта чыга торган Казан газеталарында еш очратырга мөмкин булган. Шул белдерүләрнең берсендә болай диелә: «Алпавыт хатын Настасья Кроткованың йорт хезмәтчеләре сатыла: Андреян исемле малай һәм Дарья исемле кыз, фамилияләре Григорьевлар; беренчесенә 8 яшь, ә кызга 11 яшь. Малай 40 сум, кыз 20 сум тора».

Мондый хәлләр Казан губернасындагы рус крестьяннары арасында булган. Татар крестьяннары исә крепостной булмаганнар, дәүләт крестьяннары дип саналганнар.

1812 елгы Ватан сугышыннан соң күпләр Россия халыкларының аяныч язмышы һәм аларны крепостной коллыктан азат итү юллары турында уйлана башлыйлар. Дәүләтнең бөтен байлыгын барлыкка китерүче, зиннәтле сарайларда кәеф-сафа корып ятучы дворяннарны туендыручы хезмәт халкының тормышын ничек итеп җиңеләйтергә мөмкин? Дворяннар даирәсеннән чыккан бер төркем алдынгы карашлы офицерлар бу сорауга җавап эзли башлыйлар. Алар, халыкны бары тик кораллы восстание юлы белән генә азат итәргә мөмкин, дигән фикергә киләләр. Восстаниене әзерләү өчен, дворян революционерлары яшерен оешмалар төзиләр. Ул оешмаларның иң күренекле җитәкчеләре Павел Пестель һәм Кондратий Рылеев була.

Берничә ел җентекле әзерлек алып барганнан соң, революционерлар Санкт-Петербургта **1825 елның 14 декабрендә** восстание күтәрәләр. Бу көнне рус тәхетенә

яңа патша — Николай I утырырга тиеш була. Дворян революционерлары, патша яши торган Кышкы сарайга һөҗүм ясап, патшаның үзен һәм аның министрларын кулга алырга, илдә крепостной тәртипләрне бетерергә, самодержавиене юк итәргә һәм Россиядә гадел хакимият урнаштырырга ниятлиләр. Алар үзләренә буйсынган һәм теләктәшлек белдергән солдат полкларын ияртеп, иртән иртүк Сенат мәйданына чыгалар. Ләкин һөҗүм башларга боерык бирергә батырчылык итмиләр. Командир итеп сайланган Трубецкой мәйданга килми. Баш күтәрүчеләрнең икеләнеп торуыннан файдаланып, Николай I үзенә тугрылыклы гаскәрләргә мәйданны тиз генә камап алырга куша. Туп тавышы яңгырый. Мылтыклардан ата башлыйлар. Беренче корбаннар күренә, яралылар ыңгыраша. Төнгә таба фетнә бастырыла. Шушы вакыйгадан соң дворян революционерларын декабристлар дип атый башлыйлар.

Декабристлар — кыю һәм фидакарь революционерлар — ни өчен җиңелә соң? Алар, халыкка ирек яулап алу өчен оешсалар да, югары катлау кешеләре буларак, халыкның баш күтәрүеннән куркалар. Патшаны җиңел генә, гади халык катнашыннан башка гына бәреп төшереп, яңа җәмгыять төзергә уйлау ялгыш фикер була. Гади халык декабристларның ни өчен баш күтәргәнен аңламыйча да кала.

* * *

Шул ук вакытта крестьяннар җир һәм ирек өчен үзләренең көрәшен туктатмаганнар. Дөрес, 19 нчы гасырда Степан Разин һәм Емельян Пугачев заманындагы кебек зур крестьян сугышлары булмаган. Ләкин көрәш кискенләшкән, алпавытларга иркенәергә мөмкинлек беткән. Ел саен диярлек Казан губернасының әле бер, әле икенче төбәгендә бербер артлы крестьян бунтлары булып торган. 1828 елда Минзәлә һәм Алабуга якларында башланган чуалышларны патша гаскәрләре генә бастыра алган. Шундый ук хәл 1831 елда Спас өязенең Әҗмер, Кожаевка, Пичкассы авылларында кабатлана. Алар артыннан Биләр һәм Яңа Чишмә крестьяннары күтәреләләр. 1834 елда Чистай өязендә, ике елдан соң Буа, аннан соң Лаеш, Зөя, Тәтеш һәм яңадан Спас төбәкләрендә крестьян бунтлары булып уза.

Казанның үзендә дә тынычлык югала. Сукно мануфактурасының хуҗасы эшләп чыгару нормасын үз белдеге белән арттыра һәм эш көнен 19 сәгатькә кадәр озынайта. Ә тамак туйдыруга да җитми торган эш хакы шул килеш кала. Түземлеге беткән эшчеләр губернаторга, хәтта патшаның үзенә шикаятьләр язалар, «коллык изүеннән коткаруны» таләп итәләр, «хаклык эзләүдән туктамаячакларын» әйтәләр. Ләкин болар барысы да

кулга алулар, төрмәгә утыртулар, сөргенгә җибәрүләр белән генә тәмамлана.

1836 елның августында меңнән артык эшче халык Арча кырына җыела (хәзер Казанның Үзәк паркы тирәсе). Биредә Россия императоры Николай I Казан гарнизоны гаскәрләре белән очрашырга тиеш була. Халык төркеме арасыннан берәү чыгып, патшага сукно тукучыларның үтенеч язуын тапшыра. «Шикаятегезне тикшерермен,— ди император.— Тик сакланыгыз, әгәр дә хак булмаган нәрсәләр чыкса, барыгызга да бик каты эләгер». Әлбәттә, «Хак булмаган нәрсәләр» табыла. Ярты ел да үтми, 1837 елның салкын кышында эшчеләрне искиткеч каты җәзага тарталар. Фабриканың ишек алдында махсус чакырылган солдатлар фетнәчеләрне ялангач калдырып, эскәмияләргә бәйләп салалар һәм һәрберсен чыбыркы белән бик каты суктыралар. Күбесе үлә. Исән калганнарын, аяк-кулларына богау салып, ерак Себергә каторгага җибәрәләр.

Ни генә булмасын эшчеләр куркып калмыйлар, көрәшләрен дәвам иттерәләр. Ниһаять, 1849 елда аларны фабрика хуҗасына бәйлелектән азат итәргә мәҗбүр булалар.

19 нчы гасырның беренче яртысында Казанда төрле мануфактураларның саны 80 нән артып киткән. Аларның күбесендә кул хезмәте кулланылган. Яңа завод-фабрикалар ачыла торган. Ә аларда эшләү өчен кеше көче җитмәгән. Чөнки крепостной крестьяннар алпавытларга буйсынганнар, аларның рөхсәтеннән башка шәһәргә күчеп китә алмаганнар. Бу хәл завод-фабрика хуҗаларында да ризасызлык тудыра башлаган. Шулай итеп, шәһәрдә промышленностьның үсүе өчен дә крепостнойлыкны тизрәк бетерергә кирәк булган.

Бөтен Россиядә яңа көч белән күтәрелә башлаган крестьяннар хәрәкәте патша даирәләрен, крепостной тәртипләрне үзгәртә башларга кирәк, дигән фикергә китергән.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Кемнәр алар — декабристлар һәм алар ни өчен көрәшкәннәр?
2. Декабристлар восстаниесе турында кыскача гына сөйләп бирегез. Ни өчен декабристлар җиңелгән?
3. Казан губернасында крестьяннар хәрәкәте һәм сукно мануфактура эшчеләренең бунтлары турында сөйләгез.
4. Крепостной тәртипләрне бетерү ни өчен кирәк булган?

38. КАРАҢГЫЛЫКТАН — ЯКТЫЛЫККА

Казан ханлыгы басып алынганнан соң XIX гасырга кадәрге чор халкыбыз тарихында чын мәгънәсендә дәһшәтле, караңгы еллар, ифрат авыр гасырлар була. Патша хөкүмәте халыкның рухына да хуҗа булырга тели. Аның исемен, динен, чын тарихын алыштыруны, руслаштырып бетерүне максат итеп куя. 1740 елда моның өчен махсус «Чукындыру эшләре буенча контора» оештырыла. Аның башында торган Казан архиепископы Лука Конашевич бу эшне үтә явызлык, рәхимсезлек белән башкарган. Аның җитәкчелеге белән инде Казан губернасында күп мәчетләр юк ителгән.

Бу шартларда рухи мәдәнияттә төшенкелек, торгынлык күзәтелә. Әмма шуңа да карамастан, халкыбыз үзенең гасырлардан килгән аң-белемгә омтылышын югалтмаган.

Шушы чорның бөек фикер иясе Габденнасыйр Курсавиның (1776—1812) язган китаплары, әйткән сүзләре караңгы төндә яшен яшьнәгән кебек була. Ул халык акылына ирек даулый, диннең караңгы якларына каршы көрәш ача. Бохарада чагында аны әмир үлемгә хөкем итә. Г. Курсави бу үлемнән туган якларына кайтып кына котыла.

Бу дәвердә күп кенә гарәп, фарсы китаплары татарчага тәрҗемә ителә. Әдәби әсәрләр языла. 1602 елда Кадыйргали исемле кеше Касыйм шәһәрендә «Җәмигыт-Тәварих» (Гомуми тарих) дигән әсәр иҗат итә. Шушы чорның иң күренекле шагыйрьләреннән берсе булып Мәүла Колый үсеп чыга. Аның 1670—1678 елларда язган шигырьләре бүген дә акыллы яңгырый.

1758 елда Казанда, Мәскәүдән, Петербургтан соң Россиянең үзәгеннән еракта, беренче урта уку йорты, гимназия ачыла. Икенчесе 1835 елда беренче укучыларны кабул итә. Бу гимназияләрдә татар теле дә укытыла. Бу эшкә башта Екатерина II указы белән Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Ул 1778 елда Мәскәүдә беренче татар әлифбасы бастырып чыгара, русча-татарча сүзлек төзи. Аның әшен улы Исхак, туганы Исмәгыйль, Исхакның улы Ибраһим, Ибраһимның улы Шаһигәрәй дәвам итә.

1804 елда Казанда, Россиянең Мәскәү, Тарту (Эстония) шәһәрләреннән кала, университет ачыла. Казан тиз арада Россиянең иң зур фән һәм мәдәният үзәкләренең берсенә әверелә. Математика, химия, астрономия, медицина фәннәрендә зур ачышлар ясала.

Яңа геометриягә нигез салучы бөек математик Н. И. Лобачевский (1792—1886) 20 елга якын университетның ректоры була. Аның җитәкчелегендә университет корыл-



Казан университеты.

малары төзелә, бик күп яңа бүлекләр ачыла.

Казан университеты галимнәренең ачышлары бөтен дөньяга танылa. Астроном һәм сәяхәтче И. М. Симонов, химик Н. Н. Зинин, Көнчыгышны өйрәнүчеләр И. Н. Березин, О. М. Ковалевский, А. Казем-бек һәм башка галимнәр — шундыйлар.

Казан университетында бик бай китапханә, лабораторияләр, астрономик обсерватория, музейлар ачыла. Анда Россиядә көнчыгыш илләрен, халыкларын, гарәп, фарсы, төрек, татар, әрмән, кытай, монгол телләрен өйрәнә торган бердәнбер бүлек тә ачылган. Анда, рус галимнәре белән беррәттән, татар укымышлылары да укыткан.

Университет укытучысы Ибраһим Хәлфин (1778—1829) татарча әлифба һәм башка дәреслекләр төзи. Ул рус, гарәп, фарсы, төрек, латин телләрен яхшы белгән. Татар мәктәпләрендә укытуны яхшырту планнары эшләгән, ләкин аларны патша хөкүмәте кире каккан.

Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1824—1891) гарәп әлифбасы белән матур язу буенча дан казана. Аны 19 яшендә үк Беренче гимназиядә һәм университетта укытырга алалар.

Н. И. Лобачевский.

Н. Н. Зинин.

Әмма озак еллар буе татар, башкорт, чуваш һәм башка рус булмаган халыкларга университетта укырга рөхсәт ителми. Соңрак бары тик медицина бүлегенә генә укырга ала башлыйлар.

Китап басу, газета-журналлар чыгару эше дә университет белән тыгыз бәйләнә. Казанда беренче рус типографиясе 1800 елда ачыла. Китап басу эшендә Казан Россиядә Мәскәү белән Петербургтан соң өченче урында бара. Монда татарчадан башка казах, башкорт, таҗик, үзбәк, төрекмәннәр өчен дә беренче әлифбалар, дәреслекләр басыла.

Беренче татарча китап 1612 елда Германиянең Лейпциг шәһәрендә Иероним Мегисер (1551—1618) тарафыннан чыгарыла. Бу татар теле грамматикасы, латинча-татарча сүзлек була. Ә беренче милли татар китабы 1722 елда 15 июльдә Әстерханда басыла. Ул — Петр I нең Иранга походы вакытындагы Манифесты (мөрәҗәгате) була. Аны татар телендә бастырып ул якта яшәгән татарлар, ногайлар, азәрбайҗаннар, кумыклар, фарсылар арасында тараталар. Бу чорда аралашу өчен татар теле дипломатия теле итеп кулланыла. 1992 елда без беренче татар милли китабының 270 еллыгын бәйрәм иттек.

Беренче татар календаре 1841 елда Рәхмәтулла Әмирханов тарафыннан чыгарыла.

Казанда беренче газета 1811 елны чыга. Ул «Казанские известия» дип атала.

XVIII гасыр ахырында алпавыт П. Есипов беренче театр ача. Артистлар булып аның крепостной крестьяннары уйнаган. 1845 елда театрның яңа зур бинасын сала башлаганнар. Театрга мөселман татарлар да йөргән. Алар өчен рәшәткәле ябык махсус ложалар эшләнгән.

Бу театрда Н. К. Милославский, А. И. Стрелкова, В. И. Виноградов, Е. Г. Пиунова кебек талантлы артистлар уйнаган.

Нәкъ шушы вакытта Казанда күркәм биналар да төзелә. Шулардан гостиний двор, университет, аның ишек алдында төзелгән анатомия театры, астрономия обсерваториясе бинасы, дворяннар җыелышы йорты (хәзерге Ирек мәйданындагы Офицерлар йорты). 1815 һәм 1842 елгы зур янгыннардан соң төрлечә бизәклəп, кәрниз, һәм кечкенә балконнар белән эшләнгән бик күп ике катлы таш йортлар салына.

Бу чорда мәдәният һәм әдәбият өлкәсендә зур җанлылык сизелә. XVIII гасырда Казанда Г. П. Каменев, Г. Р. Державин кебек мәшһүр шагыйрьләр яши һәм иҗат итә. 1806 елда Казанда галим, тәрҗемәче, беренче гимназия, университет укытучысы Нигъмәт Ибраһимов (1778—1818) тарафыннан әдәбият түгәрәге оештырыла. Н. Ибраһимов укыткан күп кенә кешеләр күренекле галим, язучылар булып китә. Аның русча язган кайбер шигырьләре бүген дә җыр булып яши. Ул Н. И. Лобачевскийның да укытучысы була.

Русларның күренекле язучылары С. Т. Аксаков, Л. Н. Толстой Казан университетында укыйлар, иҗат эшләрен башлыйлар. Бу чорда Казанда күренекле галим, врач К. Ф. Фукс йортында әдәби кичәләр, җирле халык тарихы һәм мәдәнияты турында зур сөйләшүләр үтә. Анда 1833 елда Казанга килгән А. С. Пушкин да була.

Татар әдәбиятында да яңа әсәрләр барлыкка килә. Татар халык авыз иҗатын җыю һәм китап итеп бастыру эшчәнлеге башлана. Габдерәхим Утыз Имәни (1754—1834) Һибәтулла Салихов (1794—1867), Әбелманих Каргалый (1782—1833) Габделҗаббар Кандалый (1797—1860), Шәмсетдин Зәки (1825—1865) кебек язучылар, шагыйрьләр талантлы әсәрләр иҗат итәләр.

Алар арасында Габделҗаббар Кандалый иҗаты аерым игътибар итүне сорый. Ул бик күп шигырьләр, поэмалар яза. Аның теле һәм эчтәлеге гади, җиңел аңлаешлы була. Г. Кандалый халыкны гомерне бушка уздырмаска, халыкка хезмәт итәргә чакыра.

Аның:

Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән,

дигән шигъри юлларын бүген дә матур, тапкыр әйтем буларак кабатлыйбыз.

Шулай итеп, XIX йөзнең беренче яртысында мәдәният өлкәсендә зур җанлану башлана. Беренче уку йортлары, беренче типография, беренче газет-журнал, беренче театр барлыкка килә. Казан Россиянең Мәскәү, Петербургтан кала иң зур мәдәни учагына әверелә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен бу дәрес «Караңгылыктан — яктылыкка» дип атала?
2. Беренче татар китабы кайда һәм кайчан басыла?
3. Каникул вакытында Казан университетына экскурсиягә барыгыз.

39. КРЕПОСТНОЙ ТӘРТИПЛӘРНЕҢ БЕТЕРЕЛҮЕ. БЕЗДНА ВОССТАНИЕСЕ

Ниһаять, 1861 елның 19 февралендә Россия императоры Александр II крепостной тәртипләрне бетерү турындагы манифестка кул куя. Бу хәбәр Казан губернасына март башларында гына килеп җитә.

Спас өязенең Мораса авылы. Крестьяннарга патша манифестын игълан итәргә дип махсус җибәрелгән вәкил урам буйлап үтеп бара. Җай гына юыртып барган атлар, поп йортына килеп җиткәч. туктап калалар.

Авыл халкы арасында яшен тизлеге белән хәбәр тарала: «Ирек! Безгә ирек бирергә килгәннәр!» Тиздән чиркәү чаңнары яңгырый. Авыл халкының олысы-кечесе урамга чыга. Кешеләр төркем-төркем булып чиркәүгә агылалар.

Чиркәү эче халык белән шыгрым тулы. Поп алга чыгып баскан. Аның янәшәсендә, кәгазен култык астына кыстырып, шәһәрдән килгән вәкил басып тора. Киеренке тынлык урнаша.

— Крестьяннар! Хәзер сез крепостнойлар түгел,— дип башлый ул үзенең сүзен.— Сезне хәзер сатып җибәрергә дә, сатып алырга да, башка кешегә бүләк итеп бирергә дә ярамый. Алпавытларның андый хокуклары бетерелә. Яңа закон буенча сезне хуҗагыз мәҗбүри өйләндерә дә, мәҗбүри кияүгә дә бирә алмый. Телисез икән, бүгеннән үк икенче урынга күчеп китә аласыз. Шәһәргә барып, завод-фабрикаларга эшче булып урнашырга мөмкин.

Крестьяннар тын алмыйча тыңлыйлар. Аларның язмышын, Россиядәге миллионлаган крепостнойларның азатлыгын хәл итә торган бик мөһим указ алып килгән вә-

кил. Озак сөйли ул. Попка да сүз бирәләр. Икесе дә, крестьяннарга «бөек указ» бүләк иткәне өчен, император галиҗәнабларын мактый, аңа озын гомер тели.

Җыелган халык тора-бара искәреп ала: ә җирләребез, урман-болыннарыбыз кем кулында кала? Нишләп бу хакта бер сүз дә әйтмиләр? Шунда берәү түзми, сорап куя:

— Безнең һәркайсыбызга күпме җир бирелер икән? Ирек белән генә яшәп булмый ич, җир дә кирәк безгә! Барщина һәм оброк белән нишләргә?

Халык шаулаша башлый. Казаннан килгән вәкил, канәгатьсезлек белдереп, аңлатырга тотына:

— Анысын дөрес әйтәсез. Җир кирәк инде ул. Менә монда, указда, язылган, җир мәсьәләсен крестьяннар үзләренең алпавытлары белән бергәләшеп хәл итәргә тиешләр, диелгән.

Крестьяннар, озак сөйләшеп тормастан, алпавыт йортына юнәләләр.

Якын-тирә авылларның хуҗасы, алпавыт хатын Ермолованың утары авылдан читтәрәк тыныч, матур җирдә урнашкан. Юан нарат бүрәнәләрдән салынган ике катлы зур йорт. Алгы яктан колонналар белән бизәлгән, икенче катында балконы да бар.

Ярсыган халык төркемен күреп, Ермолова каушаган кыяфәттә ишек төбенә чыгып баса.

— Ник килдегез, мужиклар? — дип эндәшә ул коры гына.

— Патша безгә ирек биргән. Җирне кайчан бүлешәбез? — дип шаулашалар крестьяннар.

— Әйе, сезгә ирек бирелгән. Җир мәсьәләсенә килгәндә, эш болайрак тора,— дип аңлата башлый алпавыт хатын.— Һәрберегезгә имана җире бүлеп бирелер, ләкин аның өчен йолым түләргә кирәк булачак. Җирнең бәясен кайтарып бетергәч, ул үзегезгә калыр. Ә хәзергә барщинада эшләп торырсыз, я акчалата оброк түләрсез.

Крестьяннар бер мәлгә телсез калалар. Мондый «ирекне» көтмәгәннәр иде ич алар! Ничек була инде бу? Йолым өчен кайдан акча алырга? Яңадан каһәр суккан барщинада эшләргә туры килер микәнни? Ә терлекләрне кайда йөртергә? Урман, елга, болыннар да алпавытларныкы булып кала, ди бит. Ничек яшәргә болай булгач?

Ачулары чыккан крестьяннар авылга кайтып китәләр. «Безне бу алпавыт хатын алдалый. Указда болай язылмагандыр,— диләр алар.— Башка авылларда хәлләр ничегрәк икән? Белешергә кирәк».

Тиздән яңа хәбәр килеп ирешә: Бездна авылыннан Антон Петров исемле кеше патша указын, дөрес итеп, башкача аңлата икән. Мораса крестьяннары Безднага үзләренең кешеләрен җибәрәләр.

...Бездна тирәсендә урнашкан

авыллар тузынган умарта күчен хәтерләтәләр. Алар үзләренең алпавытларына буйсынудан баш тартканнар. Дистәләгән, йөзләгән крестьяннар Бездната таба юнәләләр.

Биредә аларны уртача буйлы, киң җилкәле, кара чәчле, ир уртасы яшендәге кеше каршы ала. Бу Антон Петров була. «Барлык җирләр сезнеке,— дип башлый ул көчле тавыш белән.— Алпавытларга таулар да чокырлар, комлык та камышлык, аларга урманнан бер генә чыбык та кистермәскә! Ә үз җирләреннән читкә чыксалар, башта әйбәтләп кенә әйтергә, тыңламасалар, муеннарын сындырырга! Барщинага йөрмәскә, оброк түләмәскә! Патша үзе шулай кушкан».

— Менә бу чын ирек! — дип хуплый җыелган халык.

Восстание кабынып китә. Крестьяннар алпавыт җирләрен бүлешә башлыйлар, барщинага йөрүдән, буйсынудан туктыйлар.

Куркуга төшкән алпавытлар бу хәлләр турында тиз генә губернаторга хәбәр салалар. Патша боерыгы буенча Санкт-Петербургтан Казанга җибәрелгән генерал Апраксин восстаниене бастырырга үзе килә. 1861 елның 9 апрелендә берничә рота солдат белән ул Спаска килеп керә, аннан 12 апрельдә Бездната чыгып китәләр.

Солдатлар чиркәү мәйданында җыелган меңләгән крестьяннар алдында туктап калалар. Генерал алга чыгып баса һәм Антон Петровны тотып бирүләрен таләп итә. Халык моны эшләүдән баш тарта. Ачуы чыккан генерал атарга команда бирә. Залп тавышы яңгырый, баш өстеннән пулялар сызгырып үтә. Берничә кеше җиргә ава. Тагын бер-бер артлы залп — коралсыз кешеләр төрле якка кача башлыйлар. Төркем арасыннан Антон Петров үзе килеп чыга. Аны тотып алалар. Ату тавышлары дәвам итә. Үлүчеләрнең һәм каты яраланучыларның саны 350 гә җитә.

Восстание бастырыла. Антон Петровны Спас төрмәсенә ябып куялар. Бер атнадан аны яңадан Бездната алып киләләр һәм авылдашларының күз алдында атып үтерәләр. Ул авыл зиратыннан ярты чакрым читтә, атып үтерелгән урынында күмелә.

...Бу вакыйгалардан соң күп еллар үтсә дә халык үзенең батыр йөрәкле яклаучысын һаман онытмый. Бездна авылының исеме аның хөрмәтенә Антоновка дип үзгәртелде. Авыл уртасында аның истәлеген мәңгеләштереп мәһабәт һәйкәл тора. Геройның каберен авылдашлары кадерләп саклыйлар.

1861 елда крестьяннарны менә шулай «азат» иткәннән соң Казан губернасының һәм Россиянең башка төбәкләрендә дә восстаниеләр дулкыны кузгалып китә. Халык патша галиҗәнабларының «бөек» указына үзенең мөнәсәбәтен шулай белдерә.

1861 ел Россия тарихына кре-

постной тәртипләрнең, феодализм строеның җимерелүе белән кереп кала. 1866 елда дәүләт крестьяннары турында да шундый ук закон чыгарыла. Җәмгыять үзенең үсешендә тагын бер баскычка югары күтәрелә. Илдә капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Крепостной хокукның бетерелүе хакында крестьяннарга ничек белдерәләр?
2. Крестьяннар патшадан нинди указ көткән булалар? Аларга нәрсәләр бирелә?
3. Антон Петров бу указны ничек аңлата? Бездна восстаниесе турында сөйләгез.
4. Мөмкин булса, шундый истәлекле урыннарга экскурсия оештырыгыз.

40. КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДА КАПИТАЛИЗМНЫҢ ҮСҮЕ

1861 елгы реформа патша һәм алпавытлар тарафыннан үткәрелгән. Алар бары тик үзләренең мәнфәгатьләре турында гына кайгыртканнар.

Патшаның «бөек» указы тормышка ашырыла башлагач, Казан губернасында элек крепостной крестьяннар кулында булган җирләрнең шактый өлешен (78 мең дисәтинә) алпавытлар үзләре файдасына кисеп алалар. Калган җир өчен крестьяннар 49 ел буена йолым түләп торырга тиеш булалар. 11 меңнән артык хуҗалык бөтенләй җирсез кала. Татарларның күбесе дәүләт крестьяннары була. 1866 елгы реформадан соң аларның да чәчүлек җирләре кими, бөтен акчалары җир һәм урман өчен хөкүмәт казнасына салым түләргә китеп бара.

Ләкин крестьяннарның күпчелеге крепостной тәртипләр бетерелгәннән соң бераз иркенлек ала. Аларның бер өлеше йолымны тиз арада түләп бетереп, алпавыттан үз җирен сатып ала, хуҗалыгын тергезә. Болар авылның яңа байлары — кулаклар — булалар. Алар, алпавытлар кебек үк, тиздән үзләренең авылдашларының өлешенә керә башлыйлар. Ярлы крестьяннарны бик аз хакка гына яллап, үзләренең җирләрендә эшләтәләр, бурычка алган акчаларын икеләтә арттырып кайтаруларын таләп итәләр.

Җир азлыктан бөлгенлеккә төшкән крестьяннар гаиләләре белән, төянеп, авылларын ташлап, шәһәргә чыгып китәләр. Монда да аларны ачык чырай белән каршы алучы булмый. Эш эзләп йөрүчеләр күп. Кемгә кем кирәк? Меңләгән татарлар, бәхет эзләп, тагын да ераграк якларга — Донбасс шахталарына, Урал заводла-

рына, Бакуның нефть промыселларына чыгып китәләр һәм күбесе шунда утырып калалар.

Завод-фабрика эшчеләре дә авыл крестьяннары кебек үк һич тә җиңел яшәмәгәннәр. Менә 100 меңнән артык халкы булган Казан шәһәре. Төрле өязләрдән, күрше рус губерналарыннан килгән йөзләгән кеше Алафузовның җитен эрләү фабрикасы алдында басып тора. Аларны бирегә җирсезлек һәм ачлык китергән. Халык эш сорый. Берәүләр, ничәдер көн көткәннән соң, өметләрен тәмам өзеп, Крестовниковларның сабын-шәм заводына, Әҗемов, Үтәмещев, Юнысов фабрикаларына юнәләләр. Сабыррраклары, фабрика капкасыннан күзләрен алмыйча, һаман көтәләр. Ниһаять, фабрикантның хезмәткәре күренә.

— 3 татар, 12 урыс! — дип кычкыра ул. Димәк, шулкадәр кешене эшкә алачаклар. Төркемдә җанлану. Елгыррраклары шунда ук хезмәткәр артыннан фабрика ишек алдына томырыла. Булачак эшчеләр конторага кереп китәләр. Иртәгәсе көннән — эшкә!

...Таң беленгәнче үк эшчеләрне фабрика гудогы уята. Балаларны иртә уяту бигрәк тә кыен. Алар йокы аралаш диярлек иртәнге ашларын ашык-пошык кына капкалыйлар да фабрикага чабалар.

Эрләү цехы. Бу эссе һәм тынчу бинага килеп керүгә үк борынга әллә нинди әчкелтем авыр исләр килеп бәрелә, станоклар тавышыннан колаклар тона. Тузан болыты арасыннан эшчеләрнең йөзләрен дә ачык күреп булмый. Станоклар артында торучыларның күбесе — хатын-кызлар. Ирләр, авыр вагонеткаларны этеп, чимал ташып йөриләр. Баш күтәрмичә эшлиләр. Талчыгып беткән ябык балалар нинди эш кушсалар, шуңа риза: йөк ташыйлар, төйиләр, бушаталар. Зурлар белән бер дәрәҗәдә эшлиләр. Эш көне тәүлеккә 14—16 сәгатькә җитә.

Айлар, еллар буе шундый коточкыч шартларда эшләү җиңел түгел, әлбәттә. Эшчеләр бик тиз сәламәтлекләрен югалталар, чахотка белән авырый башлыйлар. Машиналар, станоклар куелган цехларда еш кына кысылу, имгәнүләр булып тора.

Нишлисең, түзәргә кирәк. Эшеңнән гаеп табып, куып чыгарсалар, кая барасың? Синең урынга килергә дип атлыгып торучылар әнә күпме капка төбендә! Башка чара юк: я эшлисең, я ачтан үләсең.

Эшләгән өчен акчасын юньләп түләсәләр икән! Әнә, ирләр булып ирләр сентябрь аенда 5 сум алганнар, октябрь өчен 3 сум гына биргәннәр, ди. Хатын-кызга ике тапкыр кимрәк түләгәннәр. Малайларга аена 1 сум —1 сум 25 тиен, ә кыз балаларга 50—80 тиеннән арттырмыйлар. Ярый ла шул хезмәт хакын тулысынча кулыңа тоттырсалар. Эшкә бер-ике минут соңга калдыңмы — штраф түли-

сең, мастерга каршы сүз әйттеңме — штраф, тагын башка юк кына тәртип бозулар өчен дә штраф салалар.

Фабрика хуҗасы Иван Алафузов үзенең эшчеләренә тору өчен уңайлы йортлар салып мәшәкатьләнмәгән. Күпләр гаиләләре белән тулай торакта — казармаларда яшәгәннәр. Гаиләгә аерым бүлмә сирәк очракта гына бирелгән. Шәһәрдә торыр җире булмаган эшчеләр тынчу һәм караңгы казармада карават куярлык урын бирсәләр дә риза булганнар.

Эшчеләр фабрика ашханәсендә тукланырга мәҗбүр булганнар, ә кибеттә сатылмыйча яткан товарларны, бозыла башлаган азык-төлекне әҗәткә биреп торганнар. Шуңа күрә эш хакы аласы көнне эшченең кулына тиеннәр генә кергән, чөнки акчаны штрафларга, торак өчен, фабрика кибетенә әҗәтне түләү өчен тотып калганнар.

Алафузов фабрикаларында гына түгел, Крестовниковларның сабыншәм заводында да хәлләр мөшкел булган. Ялланган эшчеләр казармаларның караңгы һәм кысан биналарында катлы-катлы сәндерәләрдә йоклаганнар. Анда сасы селте, дегет, сабын һәм төрле май исе аңкып торган. Завод цехларында көне буе пычрак һава сулап, авыр хезмәттән соң ял итәргә кайтып егылган эшчеләр шундый шартларда да түзгәннәр.

Үзләренә аерым фатирлар, өйләр булдырып, чагыштырмача яхшы гына яшәүче эшчеләр дә булган, әлбәттә. Оста куллы, тәҗрибәле эшчеләр эш хакын да аз алмаганнар. Ләкин андыйлар бик сирәк.

Россиядә капиталистик тәртипләр ныграк урнаша барган саен шәһәрләрдә яңадан-яңа завод, фабрика корылмалары калкып чыга, авыллардан килгән крестьяннар исәбенә эшчеләр саны арткан-нан-арта. Казан Россиянең иң эре промышленность һәм сәүдә үзәкләре рәтендә йөргән. Бондюгның (хәзерге Менделеев шәһәре) химия заводлары, Кукмараның күн эшкәртү заводы, киез итек басу һәм туку фабрикалары эшләп чыгарган продукция бөтен илгә танылган.

Шулай итеп, капиталистик тәртипләр урнашу нәтиҗәсендә җәмгыятьтә тирән үзгәрешләр килеп чыккан. Бер-берсенә дошман сыйныфлар — капиталистлар (буржуазия) һәм эшчеләр сыйныфы (пролетариат) формалашкан. Авылда элеккеге алпавытлар сакланып калган. Крестьяннар сыйныфы исә төрле сәбәпләр аркасында таркалып, кулаклар, урта хәлле һәм ярлы крестьяннар (авыл пролетариаты) барлыкка килгән.

11 ч-279

Сораулар һәм биремнәр:

1. Капиталистик җәмгыятьне сез нинди итеп күз алдына китерәсез? Төп сыйныфларны санап чыгыгыз. Бу сыйныфлар крепостной тәртипләр вакытында (феодализм чорында) булганмы?
2. 1861 елгы крестьян реформасы ничек итеп капиталистик тәртипләрнең урнашуына китергән?
3. «Алафузов фабрикасында эшчеләрнең хезмәт һәм тормыш шартлары» дигән темага хикәя төзегез.

41. КАЗАН КАПИТАЛИЗМ ЧОРЫНДА. РЕВОЛЮЦИЯГӘ БЕРЕНЧЕ АДЫМ

19 нчы гасырның икенче яртысында, ягъни моннан йөз еллар чамасы элек, Казан Россиянең эре промышленность, сәүдә һәм мәдәният үзәгенә әверелә. Илдә капиталистик тәртипләр урнашкач, шәһәр бик тиз үсә башлый. Түбәндәге саннарга игътибар итегез: 1863 елда Казанда 63 мең кеше яшәгән булса, егерме елдан соң аның халкы 140 меңгә җитә. Чагыштырып карагыз: 1897 елда Самарада 90 мең, Уфада — 49 мең, Пермьдә — 45 мең, Сембердә 42 мең кеше яшәгән.

Казан халкы элек-электән күп милләтле булган. Аның иң күп өлешен руслар тәшкил иткән, һәр йөз кешенең бары 22 се татар булган.

Шул вакытлардагы Казанны күз алдына китерергә тырышып карыйк. Менә без утырган пароход пристаньга килеп туктады, ди. Ул Бакалтай дигән җирдә Казанка тамагында урнашкан. Вокзал каршында эре хәрефләр белән язылган исемнәр яр буендагы конторкаларның, кибетләрнең, трактирларның һәм складларның кайсы сәүдәгәрнеке, нинди компаниянеке икәнлеген күрсәтеп торалар. Баржалардан ярга таба басма буйлап, авыр капчыклар күтәреп бөкрәйгән, сәләмә киемле йөкчеләр йөгереп йөри. Ярлы халык трамвайга ашыга. Ыспай киенгән бай эфәнделәр һәм ханымнар, тәкәббер генә атлап, пар ат җигелгән фаэтоннарга юнәләләр. Дәррәү кузгалып киткән экипажлар артыннан тузан болытлары күтәрелеп кала.

Алда — Казан. Тонык кына булып Сөембикә манарасы һәм кремльнең таш диварлары күренә башлый. Алтмышлап чиркәү һәм дистәдән артык мәчет шәһәргә ниндидер үзенчәлекле төс биреп торалар. Казанка елгасы, аның кушылдыгы Болак суы һәм Кабан күле шәһәрне өч өлешкә бүләләр кебек.

Борынгы кремль һәм аның тирәюнендә урнашкан Воскресенская (хәзерге Ленин урамы), Большая Проломная (Бауман), Банковская (М. Җәлил), Грузинская (Карл

Маркс) урамнары Казан шәһәренең үзәге саналган. Биредә бай капиталистлар — завод-фабрика хуҗалары, банкирлар, сәүдәгәрләр, алардан кала университет профессорлары, атаклы адвокатлар, врачлар, төрле чиновниклар яшәгән. Аларның таштан салынган матур-матур йортлары, күпсанлы дәүләт учреждениеләре, банк һәм кунакханә биналары шәһәргә ямь биреп торганнар. Ләкин элек-электән бу районда татарларга яшәргә рөхсәт ителмәгән.

Үзәктән читтәрәк, Болак суы һәм Кабан күле артында, Иске һәм Яңа татар бистәләре урнашкан. Биредә бер һәм ике катлы агач йортлар, мәчет-мәдрәсәләр, татар сәүдәгәрләренең эреле-ваклы кибетләре, базарлар күп булган. Аеруча хәзерге Киров һәм Г. Камал урамнары төбәгендәге Печән базары байлыгы белән дан тоткан. Гади халык борынгыдан килгән гадәт буенча күн читек-кәвеш, мех бүрек-малахай, кәләпүш-түбәтәйләр тегеп һәм башка әйберләр эшләп көн күргән, сәүдә иткән. Татарлар шушы тирәдә урнашкан атаклы Крестовниковлар заводында, шулай ук Әҗемов, Арсланов, Үтәмешев предприятиеләрендә эшләгәннәр.

Шәһәрнең төп промышленность районы Казан елгасының аръягында тупланган. Биредә, Ягодный бистәсендә, Алафузов предприятиеләре үзләре бер шәһәрчек булып утыра. Бишбалтада (Адмиралтейская слобода) — Свешниковның механика заводы, Игумный бистәсендә — Ушковның химия заводы, Пороховой бистәсендә дары заводлары урнашкан була. Бу бистәләр фәкыйрь эшчеләрнең шыксыз казармалары, яртылаш җиргә сеңгән тәбәнәк өйләре, вак-төяк кибетләре белән тулган.

Казан үз вакыты өчен Россия империясенең иң алдынгы мәдәниятле шәһәрләреннән саналган. Университет, ветеринария институты, укытучылар институты, хатын-кызлар өчен югары курслар, гимназияләр, театрлар аны фән һәм мәдәният үзәге итеп танытканнар.

Шул вакытларда ук шәһәр урамнары керосин һәм газ фонарьлары белән яктыртылган. 1897 елдан үзәк урамнарны, дәүләт учреждениеләрен һәм бай аристократ йортларын электр лампочкалары белән яктыртуга күчәләр. 1882 елда шәһәрдә телефон үткәрә башлыйлар. 1890 елда Казан тимер юлы буйлап Зөягә, ә бераздан Рязаньга һәм Мәскәүгә беренче поездлар китә. 1899 елның ноябрендә үзәк урамнарда трамвай йөри башлый. Казан чын капиталистик шәһәргә әйләнә.

* * *

Капитализмның кызу темплар белән үсүе җәмгыятьтә зур каршылыклар китереп чыгара. Халыкның бай һәм ярлы катлаула-

ры арасында булган каршылыклар сыйнфый көрәшнең бик нык кискенләшүенә, революцион бәрелешләргә китерә.

Чорының алдынгы акыл ияләре төп халык массасының авыр тормышта яшәвен патшадан һәм аның илдә урнаштырган тәртипләреннән күрәләр. Берәүләр, крестьяннар арасында аңлату эше алып барып, аларны патшага каршы бердәм революцион көрәшкә күтәрергә кирәк дип, авылларга чыгып китәләр. Бу революционерларны народниклар дип йөрткәннәр. Авыл халкын тиз генә уяту мөмкин түгеллеген аңлап, народникларның бер өлеше террор юлына баса, патшаны үтерү өчен берничә тапкыр һөҗүм ясау оештыра. Ләкин боларның берсе дә көткән нәтиҗәләрне бирми.

Нәкъ шушы чорда алдынгы Европа илләрендә атаклы революционерлар Карл Маркс һәм Фридрих Энгельс хезмәтләрен өйрәнү башлана. Алар капиталистик тәртипләрне бары тик пролетариат революциясе нәтиҗәсендә генә юкка чыгарырга мөмкин дип уйлыйлар, капитализмга алмашка гадел җәмгыять — коммунизм киләчәген исбат итәргә тырышалар. Моның өчен, дип яза алар, капиталистлар белән озакка сузылган көрәш алып барырга кирәк. Бу көрәштә төп көч эшчеләр сыйныфы булырга тиеш. Аның союзниклары булып ярлы крестьяннар — авыл пролетариаты тора. Эшчеләрнең көрәше уңышка китерсен өчен, алар берләшергә тиешләр. К. Маркс һәм Ф. Энгельс «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» — дигән өндәмә белән мөрәҗәгать итәләр.

1880—1890 елларда Казанда Карл Маркcның революцион тәгълиматен өйрәнү буенча беренче түгәрәкләр оеша. 1892 елда Алафузов эшчеләре маевка үткәрәләр, ягъни 1 нче Майны Бөтендөнья эшчеләренең бердәмлек көне рәвешендә бәйрәм итәләр.

Шушы дәвердән Россиядә революцион хәрәкәтнең тарихы В. И. Ульянов (Ленин) исеме белән бәйләнеп китә. Ул 1870 елның 22 апрелендә Сембер шәһәрендә бай гына интеллигент гаиләсендә туа. Аның әтисе, Илья Николаевич, халык мәгарифе өлкәсендә эшли, Сембер губернасы мәктәпләренең инспекторы була. Олы абыйсы Александр Петербург университетында укый. Александр Ульянов, народникларның террор юнәлешендәге төркем әгъзасы буларак, үзенең берничә иптәше белән патшаны үтерергә әзерләнә. Ләкин бу заговор ачыла. 1887 елның маенда, Володя гимназияне бетерәсе елны, аны асып үтерәләр.

Шул елның җәендә Ульяновлар гаиләсе, Сембердәге өйләрен сатып, Казанга күчеп килә. Володя университетның юридик факультетына укырга керә һәм революцион хәрәкәткә актив катнашып китә.

1887 елның 4 декабрендә Казан университетында патша тәртипләренә каршы студентларның көчле демонстрациягә әйләнгән сходкасы була. Сходканың иң актив оештыручыларын, шул исәптән Владимир Ульяновны да, полиция кулга ала. Укуларны ике ай буена туктатып торырга мәҗбүр булалар. Кулга алынган студентларны университеттан куалар һәм туган җирләренә кайтарып җибәрәләр. Сембердә бер туганы да булмагач, әнисенең үтенече буенча, Володяны берничә көннән Кокушкинога озаталар. Биредә ул әнисе һәм сеңелләре белән бергә яши, үзлегеннән белем алуын дәвам иттерә. Ун ай чамасы Кокушкинода торганнан соң, Ульяновлар Казанга кайтырга рөхсәт алалар.

Владимир Ульяновның революцион карашлары формалашуына Карл Марксның «Капитал» дигән әсәре зур йогынты ясый. Тиздән ул Николай Федосеев ачкан марксистик түгәрәккә йөри башлый.

Мария Александровна Ульянова, балаларының революцион карашларын бөтен йөрәге белән яклаcа да, полициянең яңадан эзәрлекли башлавыннан курка. Ульяновлар гаиләсе Самарага күчеп китә. Владимир Ульянов Казанда һәм Кокушкинода ике елдан кимрәк вакыт яши. Шул арада ул инанган марксист, үзенчәлекле көрәшче булып җитешә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 19 нчы гасырның икенче яртысындагы Казан шәһәрен сез ничек күз алдына китерәсез?
2. Ни өчен Казанда революцион хәрәкәт башлана?
3. Кем ул К. Маркс һәм Ф. Энгельс?
4. Владимир Ульянов ничек революционер булып китә?

42. 19 НЧЫ ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ТАТАРЛАРДА МИЛЛИ-АЗАТЛЫК ХӘРӘКӘТЕ

Россиядә капиталистик тәртипләр урнаша барган саен татар дөньясында да әкренләп уяну, җанлану процессы көчәя. Халкыбыз арасында милли тигезлеккә, азатлыкка, мәдәнияткә омтылыш үсә башлаган. Милли-азатлык хәрәкәтенең яңа көч белән башланып китүендә югары катлау кешеләре — авыл һәм шәһәр байлары, муллалар, сәүдәгәрләр, бай эшкуарлар зур роль уйнаганнар. Милләттәшләребез арасыннан завод-фабрика хуҗалары, бай сәүдәгәрләр үсеп чыга. Аларның күбесе шул чорның укымышлы, алдынгы карашлы кешеләре була. Халкыбызның аяныч язмышы, патша

хөкүмәте тарафыннан гасырлар буена изелеп һәм җәберләнеп килүе аларны битараф калдыра алмаган.

1878—1879 елларда Казан губернасының татарлар яши торган төбәкләрендә крестьяннарның бик көчле чуалышлары булып уза. Алар нидән канәгать булмаганнар, кемгә каршы һәм нәрсә өчен көрәшкәннәр?

Эш болай була. 1878 елда Казан губернасына рус чиновниклары төзегән «Авыл халкы үтәргә тиешле йөкләмәләр» исемле бер эш кәгазе (инструкция) килеп төшә. Бу күрсәтмәдә авыл халкы хисабына янгын куркынычсызлыгын көчәйтү буенча кайбер чаралар каралган була. Мәсәлән, авыл капкалары янына багана утыртып, аңа беркетелгән тактага авылның русча исемен, хуҗалыклар санын, күпме халык яшәвен язып кую, ә авыл уртасындагы колгага янгын чыга калганда кешеләр чакыру өчен чаң урнаштыру таләп ителә. Халык исә моны, руслар безне тагын чукындырырга җыеналар икән, авыл уртасына чиркәү салдырырга уйлыйлар икән, дип аңлый. Чөнки шул ук елларда чыннан да мәктәп-мәдрәсәләрдә авыл мәхәлләсе хисабына көчләп рус сыйныфлары ачарга омтылган, каршылык күрсәткән авыллардагы татар мәктәпләрен япкан булганнар. Бу исә рус патшаларының электәге төрле мәрхәмәтсезлекләрен, мәчет-мәдрәсәләрне җимертүләрен, көчләп чукындыруларны яңадан искә төшергән, халык күңеленә шом салган. Рус түрәләренең урындагы вәкилләре (старшиналар, исправниклар) үзләренең боерыклары тиешенчә үтәлмәгән очракта татарларны еш кына, сезне чукындырырга кирәк, тиздән динегезне алыштырабыз, дип куркытканнар.

Крестьян фетнәләре 1878 елның көзендә Спас өязенең татар авылларында башланып китә һәм тиздән Чистай өязенә дә тарала. Казан губернаторы, гаскәр белән бару өчен, Кама һәм Иделнең боз белән каплануын көтеп яткан арада көчле чуалышлар Казан өязенең дистәләгән авылларында җәелеп китә. Күп кенә олысларда (волостьларда) старосталарны алыштыру башлана. Старосталар итеп гадәттә авылның таза тормышлы, абруйлы кешеләрен сайлап куя торган булганнар. Хуҗалыклардан салым җыйганда, башка төрле йөкләмәләрне үтәүдә рус түрәләре шулар аша эш йөрткәннәр. Фетнәчеләр мондый старосталарны һәм аларның ярдәмчеләрен рус түрәләренә сатылуда һәм чукындырырга җыенуда гаеплән кыйнап ташлыйлар. Алар урынына үзләре арасыннан ышанычлы яңа кешеләрне сайлап куялар, идарә биналарын туздырып бетерәләр. Олы Мәңгәр, Этнә, Мәмсә олысларында фетнәчеләр бигрәк тә активлык күрсәтәләр. Нәтиҗәдә Казан өязенең шактый

зур өлешендә (мәсәлән, Мәмсә олысында гына да 20 ләп авылда) татарларның милли крестьян үзидарәләре оеша. Спас өязенең Тигәнәле авылы крестьяннары ел буена үзләренә хөкүмәт чиновникларын үткәрмичә, бөтен эшләрен авыл җыенында хәл итеп яшиләр.

Ирек алу, рус түрәләрен куу турындагы хәбәрләр яшен тизлеге белән тирә-юньгә тарала. Күрше өязләрдән һәм губерналардан бу якларга халык агыла. Эшнең торган саен хәтәр төс ала барганлыгын аңлап, Казан губернаторы, үзенең гаскәре белән, фетнәчеләрне бастырырга дип, баш күтәргән авылларга юнәлә. Солдатлар һәм аларга ярдәмгә җибәрелгән рус крестьяннары татарлардан каты үч алалар. Йөзләгән кешене чыбык белән суктыралар, аларның бер өлешен кулга алалар, төрмәләргә утырталар, ерак Себергә каторга хезмәтенә сөрәләр.

Татар крестьяннарының 1878—1879 еллардагы баш күтәрүе — милли-азатлык хәрәкәтендә олы бер вакыйга. Зур-зур төбәкләрдә халыкның хакимиятне тулысы белән үз кулына алуы Россиядә һичкайчан күрелмәгән хәл була. Яңа гына күтәрелеп килүче алдынгы карашлы татар буржуазиясе вәкилләре, гади халыкның шушындый кыю эшләре белән рухланып, милләтебезнең язмышын җиңеләйтү максатында тәвәккәлрәк адымнар ясый башлыйлар.

Татар зыялыларының милли мәгарифне үстерү өчен көрәшен дә шундый кыюлыкларның берсе дип карарга кирәк. Россия империясенең законнары буенча мөселман уку йортларына, мәктәп-мәдрәсәләргә дәүләт казнасыннан бер тиен дә акча бирелмәгән. Мәгърифәтсез, томана халыкны буйсындыру, коллыкта тоту җиңелрәк бит. Мәктәпләр бары тик байлар һәм мәхәллә халкы хисабына гына яши алганнар. Халыкның аң-белемгә омтылышын күреп, татар байлары яңа мәктәп-мәдрәсә ачу өчен акча кызганмаганнар. Бу мәктәпләрдә дин белеменнән тыш сәүдә һәм промышленностьны үстерүгә ярдәм итәрлек, тормыш өчен кирәкле дөньяви фәннәрне дә (математика, физика, химия, география, тарих, чит телләр) укытканнар. Дин әһелләренең күпчелеге ихлас күңелдән халыкка хезмәт итәргә, төпле аң-белем бирергә омтылган.

Халкыбызны аң-белемле итүдә Казанда татарча китап басу эшенең алга китүе дә зур роль уйнаган. Патша цензурасы һәм рус чиновниклары тарафыннан күп кенә тоткарлыклар тудырылуга карамастан, 19 нчы гасырның икенче яртысында татар нәширләре барысы 25 миллион данәдә 3400 гә якын китап бастырып чыгаруга ирешәләр. Китап басу өлкәсендә Казан Россия шәһәрләре арасында иң алдынгы урынны тоткан. Татар китапларының күп өлешен, әлбәттә, дини әсәрләр тәшкил

иткән. Шулай да шәкертләр өчен дәреслекләр, матур әдәбият әсәрләре, мөселман халыкларының тарихына багышланган язмалар һәм халык авыз иҗаты хәзинәләре дә күпләп басылган. Матур әдәбият әсәрләре арасында Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла», Заһир Бигиевның «Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә», «Гөнаһы кәбаир», Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз», Риза Фәхретдиновның «Әсма яки гамәл вә җәза» исемле романнарын һәм драмаларын күрәбез.

Татар телендә көндәлек матбугат — газета чыгару мәсьәләсе 19 нчы йөздә берничә мәртәбә кузгатыла. Атаклы мәгърифәтче Каюм Насыйри һәм Мөхәммәтвәли Яхин «Таң йолдызы», Шаһбазгәрәй Әхмәров «Казан» исемле газеталар чыгарырга ниятлиләр. Тик бу ниятләрнең берсе дә тормышка ашмый. Милли-азатлык хәрәкәтенең яңа көч белән күтәрелеп китүеннән курыккан патша түрәләре татар зыялыларының мондый омтылышларына теш-тырнаклары белән каршы торганнар.

* * *

Татар халкының милли аңы уянуда **вәисовчылар хәрәкәте** үзенчәлекле урын алып тора. 1862 елда башланып киткән бу хәрәкәткә нигез салучы Зөя өязенең (хәзерге Зеленодол районы) Мулла иле авылы кешесе, язучы һәм шагыйрь Баһаветдин Вәисов була. Вәисовчылар бөтен халык өчен Гаделлек патшалыгы төзү турында хыялланалар. Бу патшалыкта яшәүче мөселманнар, алла полкларына берләшеп, авыл хуҗалыгында эшләргә тиеш булалар. Б. Вәисов милләттәшләренең сәүдә һәм промышленность белән шөгыльләнүләрен өнәмәгән, чөнки алар кешене бозык юлга кертәләр дип санаган. Ул патшаның үзеннән башка беринди хакимияткә дә буйсынмаска, дәүләткә салымнар түләмәскә, хәрби хезмәткә рекрутлар бирмәскә өндәгән. Аның фикеренчә, байлар да, ярлылар да булмаган җәмгыятьтә кешеләрнең барча мөлкәте уртак булырга тиеш. Шундый гадел тәртипләр, имеш, борынгы Болгар илендә хөкем сөргән. Вәисовчылар халыкны татар дип атауга каршы көрәшергә чакыралар. Алар үзләрен болгар мөселманнары дип саныйлар һәм ярым ай белән йолдыз төшерелгән яшел байракны азатлык өчен көрәш билгесе итеп күтәрәләр.

1880 еллар башында татар крестьяннары арасында вәисовчылар хәрәкәте активлаша. Б. Вәисов үзенең уй-фикерләрен армыйталмый пропагандалый, листовкалар яза, китаплар бастырып тарата. Ул дөньяны каплап алган явызлыкларны бетерү чараларын эзли.

Вәисовчыларның җирле хакимияткә каршы чыгулары, төрле салымнар түләүдән баш тартулары түрәләрнең ачуын чыгара. Поли-

Ш. Мәрҗани.

ция аларга каршы крестьяннарны котырта. Казан һәм Зөя өязләрендә каты гына бәрелешләр булып ала. Ахыр чиктә 300 дән артык крестьян гаиләсе Себергә озатыла. Тиздән Баһаветдин Вәисовның үзен дә кулга алалар.

Шулай итеп, 19 гасырның икенче яртысында татарлар арасында милли-азатлык хәрәкәте яңадан җанлана башлый. Бу хәрәкәттә, гади халык массалары белән беррәттән, патша хөкүмәтенә каршы булган милли буржуазия вәкилләре һәм алдынгы карашлы татар зыялылары да катнашкан.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 1878—1879 елларда булып үткән татар крестьяннарының чыгышлары турында сөйләгез. Крестьяннар ни өчен көрәшкәннәр?
2. Алдынгы карашлы татар зыялылары милли-азатлык хәрәкәтендә нинди роль уйнаганнар? Ул вакытларда татарларда мәгърифәт, китап басу эше ничек торган?
3. Вәисовчылар кемнәр алар һәм нәрсә өчен көрәшкәннәр?

43. МӘРҖАНИ ҺӘМ БАШКАЛАР

XIX йөзнең икенче яртысында да Казан университеты Россиянең бөтен көнчыгышында иң алдынгы фән һәм мәдәният учагы булуын дәвам итә. Анда әһәмиятле фәнни ачышлар ясала.

Әгәр сез Казан университетының ишек алды аша узсагыз, ике катлы бина янында тукталмыйча китә алмассыз. Сезнең игътибарны бу йортның төзеклегеннән, матурлыгыннан бигрәк стенасындагы мәрмәр такталар кызыксындырыр. Шулкадәр күп сандагы истәлекле такталар куелган йортны тагын кайда күрә алырсыз икән. К. К. Клаус, Н. И. Зинин, А. М. Бутлеров, В. В. Марковников, А. М. Зайцев, Ф. М. Флавицкий, А. Е. Арбузов, Б. А. Арбузов. Һәрберсе

А. М. Бутлеров.

дөньякүләм билгеле исем. Бу бинага урнашкан химия институты А. М. Бутлеров исемен йөртә.

А. М. Бутлеров (1828—1886) Чистай өязендә туа. Ул яшьтән үк табигатьне ярата, һәрнәрсәнең серенә төшенергә тели. Аны гимназиягә әзерләү өчен, Казан мәктәбенә укырга кертәләр. Көннәрдән бер көнне мәктәп подвалында нәрсәдер шартлый. Аннан өсте-башы корымга баткан Александр килеп чыга. Ул анда химик «тәҗрибә» ясаган икән. Усал тәрбияче, балаларны җыеп, Сашаның муенына деген белән «Бөек химик» дип язылган такта аса. Тәрбиячёнең күрәзәлеге хак булып чыга. Чыннан да А. М. Бутлеров Казан университетын тәмамлый, бөек химикка әверелә. Ул органик химиягә нигез сала, органик матдәләрнең төзелеш серен ача. Моннан тыш, ул тере табигать белән дә кызыксына. Күбәләкләр, умарта кортлары турында хезмәтләр язган. Гомеренең соңгы елларын әтисенең хәзерге Алексеевск районындагы Бутлеровка авылында урнашкан утарында үткәрә һәм шунда үлә.

Бу чорда Казан тарихы күренекле татар мәгърифәтчеләре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәезхановлар эшчәнлеге белән нык байый.

Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818—1889) — атаклы галим, тарихчы, зур фикер иясе. Ул, Бохарада белем алып кайткач, Казандагы беренче мәчетнең имамы һәм шул мәчет каршындагы мәдрәсәнең мөдәррисе итеп билгеләнә. Ул яңача укытуны яклый, наданлыкка, торгынлыкка каршы чыга. Тарих, философия, әдәбиятка багышлап 30 га якын хезмәт яза. Алар арасында Болгар һәм Казан тарихына багышланган хезмәт аеруча зур әһәмияткә ия. Казан шәһәренең Кабан күле буендагы мәчет хәзер дә Ш. Мәрҗани исемен йөртә.

Ш. Мәрҗанинең шәкерте, хезмәттәше Хөсәен Фәезханов (1828—1866) гарәп, фарсы, төрек, һәм рус телләрен әйбәт белгән. Шуңа күрә ул 1857 елда Санкт-

Х. Фәезханов.

К. Насыйри.

Петербург университетына укырга чакырыла. Ул күп кенә дәреслекләр, фәнни хезмәтләр яза. Болгар кабер ташлары язмаларын уку серен ача. Х. Фәезханов үз халкының мәгърифәте хакында бик борчыла. Алдынгы Европа мәктәпләренә охшаш татар мәктәпләре, университетта татар бүлеге ачу, татарча «Чулпан» исемле газета чыгару турында хыяллана. Әмма матур хыяллар кәгазьдә генә кала. Руслаштыруны алга сөргән патша хөкүмәте аның планнарын кире кага.

Галим, укытучы, мәгърифәтче Каюм Насыйри (1825—1902) университетта зур галимнәрнең лекцияләрен тыңлап йөри. Ул күп кенә фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр яза. Аның борынгы бөек галимгә багышланган «Әбугалисина кыйссасы» исемле әсәре бүген дә кызыксынып укыла. Ул татарлар өчен тарих, география, математика дәреслекләре яза. 1871 елдан күп кенә мәгълүматлар туплаган календарьлар чыгарып килә. К. Насыйри, рус телендә хезмәтләр язып, рус укучыларын татар халкының мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныштыра.

Безнең якларда бөек рәссамнар да туган.

«Нарат урманы», «Нарат урманында иртә», «Имән урманы яң-

Ф. И. Шаляпин.

гырдан соң», «Арыш басуы» дигән рәсемнәрне кем генә белми һәм, аларга карап, кем генә сокланмый икән. Нинди табигыйлек аларда! Рәсемнәрдә ясалган урманнарга үзең кереп китәрдәй буласың. Алар безнең як урманнары шул. Бу — бөек рус рәссамы Иван Иванович Шишкин (1832—1898) картиналары. И. И. Шишкин тирә-ягы куе нарат урманы белән дан тоткан Алабуга шәһәрендә туа. Алабуга тирәсендәге нарат урманнары һаман шулай шаулый. Алар үзләренә сокланган бөек рассамны бүген дә сагыналар кебек.

Алабугада И. И. Шишкинның йорт-музее ачылды.

Ел саен февраль аенда Казан шәһәренең Ирек мәйданында урнашкан Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт академия опера һәм балет театры бинасы үзенә бер бәйрәм төсе ала. Монда бөек рус җырчысы Федор Иванович Шаляпин истәлегенә багышланган фестиваль башлана. Төрле шәһәрләрдән, ерак илләрдән танылган җырчылар җыела бирегә.

Ф. И. Шаляпин 1873 елның 13 февралендә Казан шәһәрендә ярлы гына гаиләдә туа. Әтисе еш кына исереп кайтып, малае Федяны кыйный. Ул чиркәү җырларын тыңлап юана. Бервакыт аңа билет табып театрга керергә насыйп була. Андагы күренешләр Федяны таң калдыра. Ул театр турында гына уйлап яши башлый. Федя, бер театр төркеменә ялланып, шәһәрдән-шәһәргә җырлап йөрергә чыгып китә. 1895 елны башкалага — Санкт-Петербургка килә. Аның беренче чыгышлары ук кешеләрне сокландыра. Ул зур театрда җырлый. Опера җырчысы яшь Ф. Шаляпин турында хәбәр күп шәһәрләргә барып җитә. Аны Италиянең Милан шәһәрендәге дөньяның иң атаклы «Ла Скала» театрына чакыралар. Ф. И. Шаляпин бик күп атаклы җырчыларны күргән миланлыларны да шаккатыра. Ф. И. Шаляпинның даны бөтен дөньяга тарала.

Ф. И. Шаляпин Казанда, туган шәһәрендә, берничә мәртәбә була. Аннан 1922 елны чит илгә ки-

тә. Ул һәрчак Казанны сагынып искә ала. Атаклы якташыбыз 1938 елны Парижда үлә.

Менә без XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән кайбер бөек якташларыбыз: галимнәр, мәгърифәтчеләр, рәссам, җырчылар турында ишетеп белдек. Безнең яклар борын-борыннан талантларга бай булган.

Сораулар һәм биремнәр:

1. XIX гасырның икенче яртысында безнең якларда яшәгән нинди бөек шәхесләр турында белдегез?
2. Аларның барысына да нинди сыйфатлар хас?
3. К. Насыйриның «Әбугалисина кыйссасы» исемле китабын укыгыз.

44. БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНДӘ ТАТАРЛАР (1905—1907 еллар)

19 нчы гасырның ахырында — 20 нче гасырның башында Россиядә, шул исәптән Казан губернасында һәм татарлар яши торган башка төбәкләрдә, капитализм ныклап урнаша. Шул чор өчен алдынгы техника белән җиһазландырылган завод-фабрикалар саны бермә-бер арта, тимер юллар челтәре киңәя. Бу завод-фабрикаларның бер өлеше татар байлары кулында була. Татар сәүдәгәрләре үзләренең эшчәнлекләрен Идел буе, Урал, Себер, Ерак Көнчыгыш һәм Урта Азиянең күп кенә төбәкләренә җәелдерәләр. Татар сәүдә-промышленность буржуазиясенең корольләре саналган Акчуриннарның Сембер губернасында текстиль фабрикалары, Рәмиевләрнең Уралдагы алтын приисклары, Хөсәеновларның Оренбургтагы һәм Казахстандагы чимал эшкәртү заводлары, Яушев, Арсланов, Сәйдәшев, Субаев һәм Үтәмешев кебек байларның башка төрле эреэре фирмалары иң мәшһүрләрдән саналган.

Татар җәмгыятенең сан ягыннан иң күп өлешен, әлбәттә, крестьяннар һәм эшчеләр тәшкил иткән. Рус революциясенең беренче дулкыннары кузгала башлаган дәвердә татар крестьяннары мал-мөлкәт иясе булу ягыннан да бер төрле түгел иде инде. Алар арасында бай катлау — кулаклар, үз хуҗалыгы белән тырышып-тырмашып көн күреп ятучы урта кул крестьяннар һәм җирсезлектән авыл кулагында яки рус алпавытында интегүче батраклар була. Кулак хуҗалыкларында яңа техника — тимер сабаннар, уру-чабу, сугу, җилгәрү машиналары кулланыла. Бу исә аларның җир биләмәләрен тагын да киңәйтү өчен мөмкинлекләр тудыра. Яллы хезмәт кулланып, игеннәрне тиз генә чәчеп һәм урып-җыеп алганнан

соң, кулаклар икмәкләтә, акчалата түләүләр бәрабәренә авылдашларына да үзләренең техникасын биреп торганнар. Кулланудан калган ашлыкны базарга чыгарып сатканнар.

Беренче рус революциясе алдыннан авыл ярлылары үзләренең хәерче тормышларына түзә алмыйча, бәхет эзләп, Россиянең төрле төбәкләренә күпләп таралган булалар. Тәтеш, Лаеш, Зөя, Буа якларыннан күбесенчә Мәскәү, Донбасс якларына чыгып киткәннәр. Бөгелмә, Минзәлә тирәләре — Уралга, бигрәк тә Златоуст, Чиләбе кебек шәһәрләргә, Пенза, Тамбов, Түбән Новгород губерналарындагы татарларның күбесе Мәскәү һәм Петербург предприятиеләренә, Вятка һәм Пермь татарлары Бондюг, Иж заводларына тартылганнар. Бу халыкның байтагы, шул якларда төпләнеп калып, үсеп килүче яшь татар пролетариаты сафларына кушылган. Моннан тыш Казанның үзендә, Себер һәм Донбасс шахталарында, Бакуның нефть промыселларында һәм Россиянең башка җирләрендә элегрәк күчеп утырган татар эшчеләренең саны да аз булмаган.

20 нче гасыр башында бөтен Россиядә җәелеп киткән эшчеләр һәм крестьяннар хәрәкәте татар халкын да үзенең көчле дулкыннары эченә ала. Ләкин, күргәнебезчә, татар җәмгыяте төрле сыйнфый катлаулардан торган. Бу хәрәкәттә катнашучы катлауларның һәрберсе үз алдына аерым максат куя, бер-берсеннән аермалы көрәш ысулын сайлый. Бер яктан, эшчеләр белән капиталистлар, кулаклар белән ярлы крестьяннар арасындагы сыйнфый каршылыклар, икенче яктан, аларның иске самодержавие тәртипләренә һәм милли изүгә каршы бердәм чыгышлары бу көрәшне тагын да кискенләштерә һәм катлауландыра.

Эшчеләр әкренләп үзләренең капиталистларга, самодержавиегә каршы зур көч булуларын аңлый башлыйлар. Бердәм һәм оешкан төстә хәрәкәт иткән очракта, бу көрәштә һичшиксез җиңәчәкләренә ышаналар. Моның өчен завод-фабрикаларда, армиядә, флотта, авылларда — эшчеләр һәм крестьяннар, солдатлар һәм матрослар арасында — бер-берсе белән үзара тыгыз бәйләнештә торган, теләсә кайсы моментта бер үзәкнең чакыруы буенча көрәшкә күтәрелергә әзер торучы кешеләрнең махсус оешмасын — революцион партия төзергә кирәк була.

В. И. Ленин һәм аның көрәштәшләре үзләре чыгара торган «Искра» газетасы аша Россиядә барлыкка килгән эшче оешмалары белән даими бәйләнештә торалар. 1903 елда шушы оешмалардан вәкил булып килгән революционерлар үзләренең съездларына җыелалар. Бу съездда эшчеләр исеменнән аерым партия төзелә. Партиянең төп максаты итеп Россия эшчеләрен һәм крестьянна-

рын бергә туплап, патша самодержавиесен бәреп төшерү, социалистик революция ясап, илдә гадел җәмгыять, эшче-крестьяннар хакимияте урнаштыру бурычы куела. Съезд делегатларының күпчелеге алда торган бурычларны тикшергәндә Ленинны һәм аның фикердәшләрен яклап чыга. Шуннан бирле бу күпчелекне — большевиклар, ә азчылыкны — меньшевиклар дип атый башлыйлар. Ленин һәм большевиклар партиясе халыкны революцион көрәшкә әзерлиләр. Бик матур вәгъдәләр бирәләр.

Беренче рус революциясе 1905 елның 9 гыйнварендa, якшәмбе көнне, Санкт-Петербургта булып үткән канлы вакыйгалар белән башлана. Бу көнне Путилов заводы эшчеләре үзләренең аяныч язмышын аңлатып язган үтенечне (петицияне) патшага тапшырырга дип Кышкы сарайга юнәләләр. Аларның бу ниятен большевиклар һич тә якламыйлар. «Ирекне җиңел генә, петицияләр язып кына алып булмый,— диләр алар.— Ирекне кулга корал тотып даулыйлар. Дошманыбыз алдында үзебезне түбәнсетеп, ялварып түгел, бәлки патшаны тәхетеннән бәреп төшереп кенә ирек яулап була».

Патша генераллары Кышкы сарай каршындагы мәйданга җыелган халыкны атарга боерык бирәләр. Меңнән артык кеше үтерелә, биш меңгә якыны каты яралана. Эшчеләрнең патшага булган ышанычы челпәрәмә килә. Хәтта иртә белән патша янына барырга өндәгәннәре дә хәзер: «Моннан соң безнең патшабыз юк! Бетсен самодержавие!» — дип кычкыралар.

Канлы якшәмбе бөтен илне тетрәтә, миллионлаган кешеләрдә самодержавиегә каршы көчле нәфрәт тудыра. Россияне революцион көрәш ялкыны чолгап ала. Эшчеләр һәм аларны яклап чыккан крестьяннар үзләренең изүчеләренә каршы күтәреләләр. Башка милләт эшчеләренә кушылып, алар белән бер сафта торып, яшь татар пролетариаты да самодержавиегә каршы сугыша.

Казан большевиклары, 9 гыйнвар вакыйгаларын аңлатып, эшчеләрне забастовкага чакыралар. Бу чакыруга беренчеләрдән булып Алафузов заводы эшчеләре кушыла. Алар эш сәгатен киметүне, эш хакын арттыруны, тормыш шартларын яхшыртуны таләп итәләр. Тиздән Бишбалтадагы Свешников заводында һәм башка күп кенә предприятиеләрдә эш туктала. Шәһәрдә митинглар дулкыны кузгала. Беренче тапкыр «Бетсен самодержавие! Бетсен патша! Сигез сәгатьлек эш көне!» дигән революцион лозунглар яңгырый. Пролетариатның көчле чыгышларыннан куркып калган фабрикантлар, завод хуҗалары эш көнен 10 сәгатькә кадәр киметеп, эш хакын да бераз арттырырга мәҗбүр

булалар. Моны күреп, Крестовников заводы эшчеләре, приказчиклар, трамвай йөртүчеләр, типографиядә хәреф җыючылар, икмәк пешерүчеләр баш күтәрәләр. Университет һәм ветеринария институты студентларының сходкасы башлана. Югары уку йортларын берничә атнага ябып тотырга мәҗбүр булалар.

Большевиклар, революцион күтәрелештән файдаланып, халык арасында активрак эшли башлыйлар. Татар эшчеләре арасында Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов, Сибгать Гафуров, Садыйк Сәгыев исемнәре еш телгә алына. Беренче татар большевигы, оста оештыручы, тыйнак һәм сабыр холыклы Хөсәен Ямашев татар телендә листовкалар, прокламацияләр язып тарата, яшерен түгәрәкләрдә чыгыш ясый, сәләтле яшьләрне революцион хәрәкәткә тарта.

Патша жандармериясенең һәм полициянең тырышлыкларына карамастан, яз-җәй айларында да забастовкалар дулкыны тынып тормый. Казанның әле бер, әле икенче урамында кызыл байраклар җилферди. Революцион җырлар җырлап демонстрантлар үтәләр. Кайбер көннәрне полиция һәм забастовкачылар арасында бәрелешләр булып ала.

Авылда да хәл тыныч тормый. Спас, Чистай, Бөгелмә, Минзәлә өязләрендә алпавытларның утарларын яндыралар, җирләрен таратып алалар, урманнарын кисәләр. «Җир һәм ирек!» — крестьяннарның төп таләбе әнә шундый була.

Октябрь башында бөтен илне куәтле стачкалар дулкыны басып китә. Казан эшчеләре һәм студентлары бу революцион чыгышларны дәррәү күтәреп алалар. 16—17 октябрьдә университет каршында гаять зур демонстрация җыела. Атлы полиция демонстрациячеләрне куып таратмакчы була. Баш күтәргән шәһәр халкы һәм меңләгән полиция, солдатлар арасында канлы бәрелешләр китә. Кырыктан артык кеше үтерелә һәм яралана.

Шул ук көнне, патша, халыкка кайбер «ирекләр һәм азатлык» вәгъдә итеп, манифест (указ) чыгара. Бу, әлбәттә, революцион халыкның җиңүе була. Ләкин большевиклар һәм Ленин эшчеләрне алданмаска өндиләр. 17 октябрь манифесты — патшаның хәйләсе генә, дип аңлаталар алар һәм халыкны коралллы восстаниегә чакыралар. Бу чакыруны эшчеләр хуплап каршы алалар. Алафузовчылар, полицияне коралсызландырып, сугышчан дружиналар төзиләр.

Эшләр шулай кызып барганда гына полиция һәм жандармерия Казан большевиклары оешмасын тулысынча диярлек кулга алалар. Эшчеләр коралллы восстаниене башлап җибәрә алмыйлар. Революция дулкыны әкренләп кими башлый. Шулай да эшчеләрнең

һәм крестьяннарның аерым чыгышлары 1907 елга кадәр дәвам итә әле.

1905—1907 елгы беренче рус революциясе халыкларның барлык катлауларын бердәм кузгатып җибәрә. Татар буржуазиясе үзен милләтнең юлбашчысы итеп күрергә тели. Иске самодержавие строен бәреп төшерүдә, төрле демократик ирекләр яулап алуда милли буржуазия белән гади халыкның мәнфәгатьләре чыннан да уртак була. Шуннан файдаланып, революция кызган көннәрдә, 1905 елның җәендә, бер төркем татар байлары Түбән Новгородта үзләренең съездларын үткәрәләр һәм «Мөселман иттифакы» («Мөселман берлеге») дигән партия төзиләр. Бу партиянең эшчәнлегендә татар милли буржуазиясенең һәм зыялыларының күренекле вәкилләреннән Йосыф Акчура, Сәетгәрәй Алкин, Рәшит Ибраһимов, Садри Максудов, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди һәм башкалар актив катнашалар. Иттифакчылар бөтен Россия мөселманнарының һәм шул исәптән татарларның милли-азатлык хәрәкәтен буржуазия мәнфәгатьләренә буйсындырырга тырышалар. Алар мәдәният һәм җирле хакимият өлкәсендә кайбер реформалар үткәрүне сорап патшага мөрәҗәгать итәләр. Мөрәҗәгатьтә татар руханиларының хокукларын русларныкы белән тигезләү, халык өчен китапханәләр, төрле клублар, театрлар ачу, теләгән кадәр газета-журналлар бастыру, мәктәп-мәдрәсәләрне патша администрациясе карамагыннан чыгару кирәклеге турында язылган була. Бу гадел таләпләр эшче-крестьяннарның таләпләре белән чагыштырганда йомшаграк булсалар да, халыкның милли аңын уятуда зур роль уйныйлар.

Йосыф Акчура (1876—1935).

Беренче рус революциясе елларында изелгән халыкларның милли-азатлык хәрәкәте моңарчы һич кайчан күрелмәгән дәрәҗәгә күтәрелә. Халык уяна. Революция дулкыннары милләтләр үсешендәге күп кенә киртәләрне җимереп ташлый. 17 октябрь манифестыннан соң, ниһаять, туган телдә беренче газета-журналлар ачу мөмкинлеге туа. 1905—1907 еллар дәвамында Россиянең төрле шәһәрләрендә — Казанда, Оренбургта,

Әстерханда, Уральскида, Петербургта, Мәскәүдә һәм Уфада — татарча 33 газета-журнал басыла. 1906 елда беренче татар театры эшли башлый. Яңадан-яңа милли җәмгыятьләр, мәдәният оешмалары барлыкка килә, дистәләгән мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Боларның барысы да халкыбызның беренче рус революциясендә актив катнашуы нәтиҗәсендә яуланган уңышлар була.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 1905—1907 елгы революция алдыннан татар җәмгыяте нинди сыйнфый катлаулардан торган? Революцион көрәштә бу катлауларның үз алларына куйган максатлары нидән гыйбарәт булган?
2. «Казан беренче рус революциясе елларында» дигән темага хикәя төзегез.
3. Иттифакчылар кемнәр алар? Аларның эшчәнлеген сез ничек бәялəр идегез?
4. Татар халкының 1905—1907 еллардагы милли-азатлык көрәше нинди нәтиҗәләргә китергән?

45. БЕЗ БИШЕНЧЕ ЕЛНЫ... УЯНДЫК ТАҢ БЕЛӘН

Г. Тукай.

Шагыйрьләр Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд (Закир Рәмиев), Мәҗит Гафури; әдипләр Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал; драматурглар Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Гафур Коләхметов; артистлар Габдулла Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская; композиторлар, музыкантлар Заһидулла Яруллин, Солтан Габәши... Бу данлы исемнәрне кемнәр генә белми.

Монда саналганнар һәм әле санап курелмәгән бик күпләрнең иҗаты халкыбыз мәдәнияте, әдәбияты, сәнгатьнең алтын фонды, йөзек кашы булып тора.

Шунысы кызык, алар барысы да бер чорда, бер-берсе белән аралашып, бер-берсенең иҗатына, эшенә сокланып, ярдәм итешеп, булышып яшәгәннәр, иҗат иткәннәр, көрәшкәннәр. Бу татар мәдәниятенең бөек чоры — XX йөз башы.

1905—1907 елгы революция татар халкы өчен күптән көтелгән милли изүдән, сыйнфый изүдән котылу, күп гасырга сузылган бик ямьсез озын төннән, тирән йокыдан уяну кебек була.

«Без Бишенче елны бер көнне
уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте [1] безне кемдер
изге нам [2] белән.

[1] Дәгъвәт итте — чакырды.
[2] Нам — исем.

Г. Тукай.

Дәрдемәнд.

дип язган бөек халык шагыйре Г. Тукай.

«Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән һәм калыкты,
Уян, шәкерт, уян инде,
Уяныргга вакыт җитте»,—

дип эндәшәләр татар шәкертләре, укымышлылары бер-берсенә, җиң сызганып, «Әйдә, халыкка хезмәткә» дип күп гасырга сузылган йокыны — артталыкны бетерү эшенә керешәләр.

* * *

Ике төрле татар мәдрәсәләре булган: яңача укытканнарын җәдиди, искечә укытканнарын кадими мәдрәсәләр дип йөрткәннәр. Соңгы вакытта җәдиди мәдрәсәләр күбрәк булган. Алар арасында аеруча Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия» мәдрәсәләре алдынгы була.

Әгерҗе районының Буби авылындагы мәдрәсә як-ягыннан су белән әйләндереп алынган утраучыкта, төрле агачлар утыртылган ямьле бакча эчендә утыра. Аның даны еракларга таралган. Россиянең бөтен тарафларыннан: Казан, Мәскәү, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Чиләбе, Урта Азия, Себер, хәтта Польшадан да Иж-Буби авылы-

Г. Исхакый.

Исмәгыйль Гаспралы.

Иж-Буби мәдрәсәсе.



Р. Фәхретдинов.

Ф. Әмирхан.

на белемгә омтылучы яшьләр укырга килгән. Монда татарлардан тыш башкортлар, казакълар, кыргызлар һәм башка төрки халык вәкилләре укыган.

Буби мәдрәсәсендә ел саен 500 шәкерт белем алган. Уку, яшәү, ял итү кебек мәсьәләләрне шәкертләр үз оешмаларында хәл иткәннәр. Анда көнчыгыш телләреннән тыш немец, француз телләре дә, тарих, политэкономия, математика, геология, география, физика, астрономия кебек дөньяви фәннәр дә укытылган. Бүлмәләр уңайлы итеп җиһазланган. Мәдрәсәдә атна саен әдәби, фәнни бәхәс кичәләре уздырылып торган. Аның бай китапханәсе булган. Уку елы ахырында зур бер бәйрәм рәвешендә имтиханнар уздырылган.

Әмма мондагы алдынгы фикергә нигезләнгән тәртипләр патша хөкүмәтенә бер дә ошамаган. Ул татарларның югары белемле, азат фикерле булуыннан курыккан. 1911 елны Иж-Буби мәдрәсәсе тар-мар китерелгән, туздырылган.

Алдынгы татар мәдрәсәләре халкыбызның күренекле улларын, кызларын тәрбияләп чыгарган. Бөек татар язучылары, шагыйрьләре Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Г. Камал, М. Гафури; композитор Солтан Габәши; скульптор,

рәссам Бакый Урманче; революцион көрәшчеләр Хөсәен Ямашев, М. Дулат-Али, К. Туйбактин һәм башка бик күп фән, мәдәният, сәнгать эшлекләләре татар мәдрәсәләрендә укыганнар.

Татар халкының аң-белемгә омтылышы инде XVIII гасырдан ук рус кешеләрен генә түгел, чит ил сәяхәтчеләрен дә шаккатырган. Алар татарларның укый-яза белүдә руслардан алда барулары, һәр авылда мәктәп-мәдрәсә булуы, хатын-кызларның да укый-яза белүе хакында сокланып язалар.

Билгеле, бу вакытта искечә укытыла торган мәктәп-мәдрәсәләр дә аз булмаган. Анда дөньяви фәннәр укытылмаган, динне, дини китапларны аңламыйча гына ятлатканнар. Г. Тукай «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» исемле шигырендә:

«Күп яттык без
Мәдрәсәдә
Аңламадык
Бер нәрсә дә»,—

дип нәкъ шундый мәдрәсәләр хакында язган.

* * *

Татарча газета-журнал чыгару өчен көрәш XIX гасырның башыннан ук үзен сиздертә. Әмма бу көрәш бик озак, гаять авыр шартларда бара. Беренче газетаны чыгаруга ирешү өчен даулашырга 100 еллап вакыт китә. Менә чыга, менә дөнья күрә дигәндә, исемнәре игълан ителгән газеталарны да патша хөкүмәте, кара көчләр тагын ябалар. Беренче татар газетасын булдыру өчен тырышлыкка, татарлар белән бергә, алдынгы карашлы рус кешеләре дә күп көч куя.

1883 елда Кырым татарларының күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм гомумән төрки халыкларның мәнфәгатен яклап көрәшүче Исмәгыйль би Гаспралы Бакчасарайда «Тәрҗеман» газетасына нигез сала. Бу газета 20 ел дәвамында төрки халыкларга хезмәт иткән бердәнбер матбугат органы була.

Беренче татар газетасы, демократик революция башлангач, 1905 елның 2 сентябрендә генә дөнья күрә. Ул Петербургта басыла. Исеме «Нур» дип атала. Ә Казанда беренче татар газетасы «Казан мөхбире» (Казан хәбәрчесе) исеме белән шул елның 29 октябрендә чыга. Аннары, шифалы яңгырдан соң кузгалган шытымнар кебек, бер-бер артлы яңа газета-журналлар чыга башлый. Февраль революциясенә кадәр аларның саны 63 исемгә җитә. Казанда «Азат» («Азат халык»), «Йолдыз», «Әл-Ислах» (Реформа), Уральскида «Фикер», «Әл-гасрел-җәдид» (Яңа гасыр), «Уклар», Оренбургта «Вакыт», «Урал», «Шура», Әстерханда «Туп», Петербургта «Нур», «Дума» һәм баш-

Казанда Печән базары мәчете.

ка бик күп исемдә газета-журналлар чыга.

Балалар өчен «Балалар тәрбиясе», «Ак юл» дигән журналлар басыла. «Ак юл»ның редакторы язучы Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиев (1887—1938) була.

Әмма газета-журналларның унлабы гына дәвамлы рәвештә эзлекле чыгып килә. Башкаларын патша хөкүмәте бик тиз яба.

Вакытлы матбугат халыкны милләт буларак бергә туплауда, сыйнфый һәм милли изүгә каршы көрәштә әйдәп баруда, татарлар тормышының бик күп якларын яктыртуда зур эш башкара.

* * *

Китапның да үз тарихы бар. Халыкның никадәр күп һәм төрле китабы булса, ул шулкадәр югарылыктагы аң-белемгә, мәдәнияткә ия. 1722 елда басылып чыккан татар милли китабы хакында без алдагы дәресләрнең берсендә сүз алып бардык инде. Казанда беренче басма татар китабы 1800 елны отставкадагы офицер Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев тарафыннан чыгарыла. Бу укырга өйрәнү өчен милли әлифба рәвешендә була.

Ә XX йөз башында татарлар китап басу буенча бөтен Россиядә беренче урынга чыгалар. Бер Казанда гына да 20 дән артык татар басмаханәсе эшли. Моннан тыш татар басмаханәләре Мәскәүдә, Петербургта, Әстерханда, Оренбургта, Себердә, Уфа һәм башка шәһәрләрдә була. Бу китапларны татарлар гына түгел, бөтен Идел буенда, Кавказда, Урта Азиядә, Себердә дә яратып укыйлар. Татар китаплары ерак Кытайга, Япониягә, Һиндстанга, Мисырга барып җитә.

Татар басмаханәләрендә башка төрки халыклар өчен дә беренче әлифбалар, дәреслекләр, китаплар басыла башлый. 1913 елда татар басмаханәләрендә 539 исемдә китап дөнья күрә.

Монда дини китаплардан тыш бик күп татар, рус басмалары, Г. Гейне, Ф. Шиллер, М. Твен, Г.-Х. Андерсен, А. Конан-Дойль кебек чит ил язучыларының да китаплары татарчага тәрҗемә итеп басыла. Медицина, география, авыл хуҗалыгы, табигать белеме, тарих буенча да китаплар күпләп чыгарыла.

Шулай итеп, халкыбыз мәдәни артталыктан котылу теләге белән бик күп изге эшләр башкара. Россия халыклары арасында ул алдан бара.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен 1905—1907 еллар татар халкы өчен йокыдан уяну кебек булган?
2. Нинди татар мәдрәсәләрен беләсез?

3. Бу елларда нинди татар газета, журналлары чыккан?
4. Беренче татар балалар журналының һәм редакторының исеме ничек?

46. ТЕАТР — ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ...

Г. Тукай.

1906 елның 22 декабре. Хәмзә бай өендә ыгы-зыгы. Хәер, аларда гына түгел, бөтен Казан болгана. Петербургтан халык алдында беренче татар театрын уйнар өчен рөхсәт язуы алып кайтканнар. Бүген «Яшьләр» түгәрәге егетләре һәм кызлары Яңа клубта (хәзерге Горький урамындагы 3 нче йорт) Г. Камал тәрҗемә иткән «Кызганыч бала» драмасы һәм «Гыйшык бәласе» комедиясе уйнала икән. Хәмзә бай мәчет картлары белән күпме көрәшеп карады театрны куйдырмас өчен. Юлдан язган яшьләрне куркытып та, хәтта җае чыкканда кыйнап та карадылар. Язмаган җирләре калмады. Юк, яшьләр үзләренекен иттеләр — бүген күпләгән халык алдында театр уйныйлар. Хатын-кыз артистлары җитми, ди. Аларын хатын-кыз киемен киеп егетләр уйный икән. Хәмзә бай, өенә кайтышлый, башка таныш-белешләренә дә керде, урамда да театрга үзегез дә бармагыз, балаларыгызны да җибәрмәгез, дип үгет бирде. Янады, куркытты. Тузынып, әлсерәп өенә кайтып керсә, ни күрсен — үзенең уллары, киленнәре, кызлары, кияүләре — берәве дә калмый театрга киткәннәр.

Г. Камал.

Өйдә театрны, «төятер» дип аңлаучы аңлы-миңле бер асрау кыз — Биби генә утырып калган. Артларыннан куып җитеп кире борып та булмый инде: театр башланган.

Менә шул вакыйга хакында сөйләнелә татар театрларын оештыручыларның берсе, үзе дә бу эшкә турыдан-туры артист-режиссер бу-

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе.

лып китнашкан Галиәсгар Камалның (1879—1933) «Беренче театр» дигән комедиясендә.

Ә ике йөздән артык кешене сыйдырган Яңа клуб кәләпүшле ирләр, калфаклы хатын-кызлар белән шыгрым тулы булып, залда, милли рух бөркелеп тора. Спектакль алдыннан уйнаучыларга кызыл тасмалы букетлар бүләк итәләр. Театрның халкыбыз өчен бик әһәмиятле, зарури булуы хакында нотыклар сөйлиләр. Пәрдә ачыла — театр башланып китә. «Кызганыч бала» исемле драманы караганда күпләр елыйлар. Ә «Гыйшык бәласе» комедиясен караганда рәхәтләнеп көләләр. Ни генә булмасын, бу уйналган театрда тамашачылар үзләренең тормышын күргән кебек булалар. Наданлыктан, артталыктан көлеп, көенеп утыралар. Ә тапкырлыкка, уңганлыкка сөенәләр.

Тәнәфес вакытында төрле музыка коралларында уйналган татар

«Сәйяр» театр труппасы.

көйләре Яңа клубта яңа рух кабыза. Уен ахырында да сөйләүчеләр, котлаулар күп була. Соңыннан бию һәм уеннар оештырыла. Тамашачылар, бик канәгать булуларын белдереп, милли сәхнә сәнгатенең киләчәгенә зур өметләр белән өйләренә таралалар.

Шул рәвешчә 1906 елның 22 декабрендә татар профессиональ театры дөньяга килә.

Әмма бу көнгә зур авырлыклар үтеп озак килгәннәр. Казан Россиядә мәшһүр театр шәһәрләреннән саналса да, анда бик күп еллар татар театрына урын булмаган. Алдынгы татар укымышлылары, татар яшьләре, тыелса да, рус театрларына йөргәннәр. Театрның нинди көчкә ия икәнен аңлап, XIX гасыр ахрында Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди, Гаяз Исхакый беренче пьесаларын язалар. Татар драматургиясенең нигезен салучы булып хаклы рәвештә Галиәсгар Камал хисаплана.

Татар театры бик катлаулы юл үтә. Шартлары булмагач, аерым гаилә кешеләре, яшьләр кача-поса гына өйләрдә театр уйныйлар. Аннары кешеләр алдында яшьләрнең кайбер клубларында уйнап карыйлар. Бу юнәлештә Казанның иң абруйлы уку йортларыннан берсе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре кыю адымнар ясыйлар. Алар театр турында озак-озак сөйләшүләрдән соң Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын уйнарга булалар. Бу эшкә башлап Татар укытучылар мәктәбендәге русча спектакльләргә йөргән шәкертләр керешә. Алар шәһәрнең бер кунакханәсендә яшерен репетицияләр үткәрәләр һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уйнарга булалар. Спектакль 1903 елның 30 декабрендә мәдрәсәнең өченче катында аулак бер вакытта бик яшерен рәвештә күрсәтелә. Ышанычлы егермеләп шәкерт тамашачы итеп чакырыла. Әмма саклык белән генә оештырылса да, бу вакыйга мәдрәсәнең хуҗасы Галимҗан хәзрәт Барудига мәгълүм булып, театр күрсәтүчеләргә каты шелтә эләгә.

1906 елның 22 декабреннән соң Казанда гына түгел, татарлар яшәгән күп шәһәрләрдә театр уйный башлыйлар. Казанда «Сәйяр» (Күчмә, сәяхәт итеп йөрүче), Уфада «Нур», Оренбургта «Ширкәт» (Берлек) исемендәге татар труппалары оеша. Алар, туктаусыз хәрәкәттә булып, Идел буе, Урал, Себер, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Казахстан һәм башка якларда яшәгән татар, төрки халыкларын театр сәнгате белән таныштыралар. Казан, Петербург, Мәскәү, Троицк, Уральск, Сембер, Самара, Чиләбе, Кустанай, Алма-Ата, Баку, Ташкент, Бохара, Хива һ. б. шәһәрләрдә татар драма коллективлары эшли.

Татар театры башкорт, казах, кыргыз, төрекмән, үзбәк һәм башка халыкларның театрларын тудыруга да йогынты ясый.

Габдулла Кариев (1886—1920), Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1892—1974) чын мәгънәсендә татар профессиональ театрын оештыручылар булалар. Г. Тукай үзенең «Ике кояш» дигән шигърендә 17 яшьлек Сәхипҗамалның уйнавына сокланып болай дип яза:

Күр: ничек, иртә кояш чыкса,
җиһанга нур тула,—
Һәр күңелләр нурланадыр,
чыкса Гыйззәтуллина.

Бу икәүгә тәңре биргән
бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә,
берсе уйный сәхнәдә.

Мәдәниятле халык иң кыен вакытларда да театр уйнавын ташламаган.

1914 ел. Германия белән Россия арасында сугыш бара. Берлиннан ерак түгел лагерьда 20 меңләп әсир татарлар була. Алар кешеләргә рух бирү, җыелган акча-

Г. Кариев. С. Гыйззәтуллина-Волжская.

га авыру, фәкыйрьләргә ярдәм оештыру өчен театр уйнарга исәплиләр. Бу спектакльләрне карарга хәтта Берлиннан немецлар үзләренең гаиләләре белән киләләр. Театр уйнап кергән акчага концлагерь өчен китапханә сатып алалар. Германиядә үлгән татар әсирләренә һәйкәл салдыралар.

Тарих белә, татар халкының сәхнә сәнгате ярата торган көчле рухы 30 елдан соң, тагын Германиядә фашистлар концлагеренда, зур яңгыраш таба. Бу юлы анда

герой шагыйрь Муса Җәлил җитәкчелегендәге татар әсирләре, үлем куркынычына бирешмичә, көлешеп-елмаешып театр уйнаганнар.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Беренче профессиональ татар театры кайда һәм кайчан уйнала?
2. Ни өчен искелеккә ябышып ятучы кешеләр театрга каршы булалар?
3. Нәрсә ул театр, спектакль, драма, комедия, трагедия, пьеса?
4. Сез нинди театр артистларын беләсез?
5. Сыйныфыгыз белән җыелышып берәр театр карарга барыгыз.

БИШЕНЧЕ
БҮЛЕК

ТАТАРСТАН СОВЕТ ХАКИМИЯТЕ ЧОРЫНДА

47. САМОДЕРЖАВИЕНЕ БӘРЕП ТӨШЕРҮ

Өч елга якын инде канкойгыч беренче бөтендөнья сугышы бара. Ни өчен бөтендөнья сугышы? Чөнки дөньяның бик күп илләре, ике төркемгә бүленеп, үзара сугышалар. Бер якта — Бөек Британия, Франция, Сербия, Россия. Икенче төркемдә — Германия, Австро-Венгрия, Болгария, Төркия. Соңрак аларга Америка, Япония һ. б. килеп кушыла. Ни өчен сугышалар соң бу илләр? Үзләренә яңа җирләр басып алып, ул илләрне талар өчен сугышалар империалистлар. Бу сугышта миллионлаган кешеләр катнаша. Беренче мәртәбә шушы сугышта кешеләрне күпләп үтерә торган кораллар, машиналар кулланыла: танклар, су асты көймәләре, самолетлар, агулаучы газлар... Бу сугышта елга булып кан ага, йөз меңләгән кешеләр үлә.

Россиядә дә күп завод-фабрикалар корал, сугыш кирәк-яраклары җитештерә. Хуҗалары сугыш белән мәшгуль булгач, басуларда, кырларда иген урынына чүп үсә. Илдә ачлык, ялангачлык башлана.

Гади халык сугышны туктатуны таләп итеп көрәшкә чыга. Тылда гына түгел, фронтта да солдатлар боерыкларга буйсынудан баш тарталар, күпләп фронттан качып кайталар.

Эшчеләр эш ташлыйлар, крестьян чыгышлары ешая. Кайбер шәһәрләрдә чират торып җәфа чиккән халык икмәк кибетләрен талый, җимерә башлый. Һәркайда кешеләр ярсып-ярсып хөкүмәтне сүгәләр. Патша изүеннән интеккән халык 1917 елның февраль ахырларында илнең башкаласы Петроградта эш ташлый, демонстрацияләргә чыга. Каршылыкларга түзә алмыйча, патша Николай II тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр була. Хакимлек Вакытлы хөкүмәткә тапшырыла.

Петроградта революциянең җиңүе турындагы хәбәр Казанга да килеп җитә. Эшчеләр, студентлар, солдатлар мәйданнарда, урам чатларында җыелалар.

Шулай итеп, советлар кан коймыйча гына хакимлекне үз кулларына алалар. Ике хакимлелек урнаша. Берсе — эре алпавытлар һәм фабрикантларны кайгыртучы Вакытлы хөкүмәт. Икенчесе — халык яклы советлар.

Халыкның тормышы тагын да начарлана. Вакытлы хөкүмәтнең тормыш барышын үзгәртергә тәвәккәллеге җитми. Социалистлардан торган Вакытлы хөкүмәт, советлар белән бергә килешеп, кискен мәсьәләләрне хәл итәр өчен Оештыру җыены (Учредительное собрание) җыярга булалар. Әмма моңа большевиклар каршы киләләр. Алар Россия белән Германия арасында үзара килешүгә ярдәм итмәкче булалар. Дошман ил булган Германиягә ярдәм итәргә тырыша дип, Ленин партиясе — большевиклар — эшчәнлеге тыела. Оештыру җыенына күбрәк социалистлар, социал-демократлар — меньшевиклар сайлана. Казан губернасыннан М. Вахитов, И. Алкин, Н. Хәлфин кебек күренекле кешеләр делегат булып җибәрелә.

Татар милли хәрәкәте дә илне демократияләштерүдә нык катнаша. 1917 елның июлендә Россия мөселманнары җыенында Милли мәҗлескә сайлаулар үткәрү турында карар кабул ителә. Аның беренче җыелышы 22 ноябрьдә үтә. Аның рәисе итеп Садри Максуди, урынбасары итеп Ибнеәмин Әхтәмов сайлана. Җитәкчеләр арасында шулай ук Галимҗан Баруди, Ризаэтдин Фәхретдинов, Гаяз Исхакый, Галимҗан Шәрәф кебек мөхтәрәм кешеләр була.

Садри Максуди.

Садри Максуди 1880 елда Казан артындагы Ташсу авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне Казанда һәм Кырымда Бакчасарайда ала. Укуын Төркиядә дәвам иттерә. Аннары Париждагы Сорбонна университетын тәмамлый. Юрист була. 1906 елда Казанга кайта һәм бөтен гомерен халкының азатлыгы өчен көрәшкә багышлый. Ике мәртәбә Россиянең Дәүләт думасына сайлана. Татар халкына корал күтәргән карагруһчыларга каршы көрәшә. Февраль революциясеннән соң ул татар халкының Милли мәҗлесен оештыру өчен тырыша. Большевиклар җиңгәч, С. Максуди чит илгә китә. Төркиядә күренекле дәүләт эшлеклесенә әверелә, аның парламентына сайлана. Чит илдә булуга карамастан, ул татар халкының азатлыгы өчен көрәшүен дәвам иттерә.

13 ч-279

Казанда совет хакимлеген игълан итү. *Л. Фәттахов рәсеме.*

Милли мәҗлес җыенында «Идел-Урал штаты» дигән суверен дәүләт төзү турында карар кабул ителә. Аның җитәкчесе итеп С. Максудины сайлау күздә тотыла.

Әмма шул чакны хәлләр бөтенләй икенче юнәлеш ала. 1917 елның 7 ноябрендә В. И. Ленин һәм Л. Д. Троцкий җитәкчелегендә большевиклар көрәшсез диярлек Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшерәләр. Икенче көнне үк советларның II җыены җир турында, үлем җәзасын бетерү турында декретлар кабул итә. Хакимлек большевиклар хөкүмәтенә күчә. Бу хөкүмәт Россия халыкларының хокуклары турында да декларация кабул итә. Анда һәр халыкның үзбилгеләнү хокукы, ягъни һәр халык үз дәүләтенең ничек булуын үзе билгели алуы хакында да әйтелә. 1918 елның 17 гыйнварында Ленин мөселман эшләре буенча комиссариат (министрлык) төзи. Бу комиссариат Милли мәҗлескә капма-каршы итеп куела.

Ниһаять, 1918 елның 5 ноябрендә большевиклар Оештыру җыенын үткәрергә рөхсәт итәргә булалар. Петроград тирәсенә гаскәрләр

туплана. Оештыру җыенын яклап урамга чыккан кешеләр куып таратыла яки аттырыла. Җыен үзе дә, хакимлекне даулый башлагач, куып таратыла.

Шушы вакыттан башлап, большевиклар хакимлекне ныклап торып үз кулларына алалар. Власть корал белән идарә итүгә күчә.

Большевиклар халыкка якты, матур тормыш төзергә вәгъдә итәләр. Ләкин бу вәгъдәнең ничек үтәлүе бүген билгеле инде. Көч кулланып эш итү, закон белән санлашмау бик күңелсез нәтиҗәләргә китерергә мөмкин икән.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 1917 ел башында Россиядә нинди вакыйгалар була?
2. Милли мәҗлес һәм милли хәрәкәт турында сөйләгез.
3. Большевиклар Оештыру җыенын ничек куып тараталар?
4. Кем ул Садри Максуди?
5. Тарихи сүзлеккә «Вакытлы хөкүмәт», «Оештыру җыены», «Милли мәҗлес», «карагруһчылар», «самодержавие» төшенчәләрен аңлатып языгыз.

48. КЕШЕЛӘР СУГЫША, КАН КОЯ...

Оештыру җыены куып таратылгач, ил халкы бер-берсенә капма-каршы булган ике төркемгә аерыла. Хакимият мәсьәләсен демократия нигезендә хәл итүгә юлларябыла. Коралга тотыну, сугышу котылгысызга әверелә. Буржуйлар һәм алпавытлар үзләренең элеккеге, патша вакытындагы хакимлекләрен, мал-мөлкәтләрен кире кайтарып алырга телиләр. Ә большевиклар илдә бар нәрсәне җәмәгатьләштерергә, гомуми итәргә, революция утын бөтен дөньяга җәелдерергә телиләр.

Бу шартларда татар демократларына аеруча авырга туры килә. Алар большевиклар белән дә, аларның дошманнары белән дә үзара сугышка чыгарга теләмиләр. Татар демократларының максаты изге була. Ул — татар халкын яңадан тергезү, аның мәдәниятен, телен, гореф-гадәтләрен саклап калу һәм яшәтү өчен кирәкле шартлар тудыру. Алар барлык халыкларга да тигезлек бирәчәк «Идел-Урал штаты» исемле милли дәүләт төзергә ниятлиләр.

1918 елның февралендә Казанда бу фикерне тормышка ашыру чаралары күрелә. Аларны оештыручылардан Ильяс Алкин һәм Галимҗан Шәрәф халыклар туганлыгы булдырырга чакырып мөрәҗәгать белән чыгалар. Әмма тыныч юл белән барырга насыйп булмый. Большевиклар милли хәрәкәтне икегә аералар. Мөселман комиссариаты җитәкчеләре боль-

Гражданнар сугышы чорындагы плакат.

шевиклар хакимиятен ныгыту өчен көрәшәләр.

Большевиклар үз чорында вәисовчылар хәрәкәте дип халык арасына киң таралган милли азатлык хәрәкәтен дә үз максатларында файдаланырга тырышалар.

Бу чорда көрәш башына Баһаветдиннең улы Гайнан (көрәштәшләре арасында кушаматы Сардар) баса. Вәисовчылар үз максатларын тормышка ашыруны социализм белән бәйлиләр. Шул җирлектә алар большевикларга якынаялар. Большевиклар милли хәрәкәтне таркату өчен аларны кораллландыралар. Вәисовчылар тиздән зур бер көчкә әверелә. 1918 елның март башында «Идел-Урал штатлары» тарафдарлары — Милли шурачылар — үгетләү нияте белән Казанда вәисовчыларның Яшел гвардия штабына юнәләләр. Корал куллануны булдырмау өчен Гайнан Вәисов үзе шурачылар каршысына чыгып баса. Ләкин аның үгетләренә колак салмыйлар. Бер төркем шурачылар аңа ташлана. Ул үтерелә. Вәисовны күмеп бәхилләшү залпы яңгыраганда, Сөембикә манарасына куелган ярым айдан да яртыма төшерелә. Бу — Сөембикә манарасына ай кую вәисовчылар-

ның изге эшләреннән берсе була.

Шуннан соң большевиклар Казанның татарлар яшәгән төбәкләренә гаскәр кертәләр. «Идел-Урал штаты» җитәкчеләре арасында кулга алулар башлана. Бу чынлыкта гражданнар сугышының башлануы була.

Шул вакытта Идел, Урал буе халыкларын үз якларына аудару өчен, большевиклар 1918 елның мартында Татар-башкорт Совет Социалистик республикасы төзү турында декрет кабул итәләр. Җирле халыкларның күпчелеге моны яклый. Әмма бу декрет тә тормышка ашмый кала. Фикер төрлелеге эшне тоткарлый. Гражданнар сугышының башлануы да моңа комачаулык итә.

Бу вакытта Россиянең үзәгендә гражданнар сугышы көчәеп китә. Ул чит ил басып алучылары боҗрасында кала. 1918 елның язында һәм җәендә Америка, Англия, Франция, Япония гаскәрләре Россиянең төньяк төбәкләренә, Ерак Көнчыгышка, Урта Азия һәм Бакуга басып керәләр. Германия көнбатыш җирләрне басып ала. Совет власте Балтик буе, Украина, Белоруссия һәм Донбассның зур төбәкләрен бирү бәрабәренә Брест шәһәрендә Германия белән солых төзи.

Большевиклар барлык промышленность предприятиеләрен хуҗаларыннан тартып алалар. Әмма чимал һәм транспорт белән тәэмин итә алмау аркасында аларның эше җайга салынмый. Эш хакы түләүдә тигезләү тәртибе тәҗрибәле эшчеләр һәм белгечләр арасында ризасызлык тудыра. Авылда да бөтен өстенлек ярлыларга күчә. Арткан икмәкне сатарга рөхсәт ителми, түләүсез җыеп алына.

Илдә икътисади киеренкелек башлангач, Идел буенда чех һәм словак хәрби әсирләреннән оештырылган полклар баш күтәрәләр. Алар Самарадан алып Читага кадәр булган җирләрне басып алалар. 1918 елның июнендә куып таратылган Оештыру җыенының шушы төбәктәге әгъзалары үз комитетларын төзиләр. Бу комитет үзен илдә бердәнбер законлы хакимият дип игълан итә. Аның эшенә татар демократлары да кушыла. Бу комитет русча, кыскартылып, Комуч дип йөртелә. Ул татар халкының үзбилгеләнү хокукын яклый. Комуч, шактый зур халык армиясен җыеп, Казан аша Мәскәүгә һөҗүм башларга җыена. Ә Казан — Россия үзәкләренә һәм Себергә илтә торган зур тимер юл үзәге һәм елга порты. Анда әре хәрби заводлар, хәрби кирәк-яраклар саклаанган складлар урнашкан була. Иң мөһиме Казан банкында Россиянең төп алтын запасы саклана. Казанның әһәмиятен аңлатып, В. И. Ленин барлык көчләрне туплап шәһәрне саклап калырга боера. Монда бөтен Көнчыгыш фронтының штабы урнаша.

Кызыл гаскәрләр арасында тәр-



Югары Ослан өчен көрәш. *Н. Язынин рәсеме.*

тип җитмәү, үзара килешеп хәрәкәт итмәү авыр җиңелүләргә китерә. Кызыллар Тәтеш һәм Буа янында тар-мар ителәләр.

5 августта Казан шәһәрен саклау башлана. Бу көнне акгвардиячеләрнең пароходлары Казан янына ук якынлашалар. Аны туп-ка тоталар, пристаньга десант төшерәләр. Бер батальоны татар-башкортлардан гына торган кызыллар полкы аларны шәһәрдән бәреп чыгара. Яр буеннан утка тотып, кызыллар дошманның бер судносын батыралар. Аклар, моңа җавап итеп, Югары Ослан ягындагы тауга урнашкан кызылларның бер батареясен юкка чыгаралар.

6 августа акгвардиячеләр Казан янындагы Олы Отар авылы янында зур десант төшерәләр һәм шәһәргә хәлиткеч һөҗүм башлыйлар. Кызыллар шәһәрне саклауны оештыра алмыйлар. Аклар көн уртасында ук Иске Татар бистәсе урамнарына бәреп керәләр. Монда латыш полкы белән татар батальоны дошманга батырларча каршылык күрсәтәләр.

Берүк вакытта көчле артиллерия һәм пулемет уты ачып, акларның икенче десанты Адмиралтейский бистәсенә килеп төшә. Бу — шәһәр эчендә яшеренеп яткан офицерларның фетнә күтәрүләренә сигнал була. Алар түбә чардакларыннан, тәрәзәләрдән ут яудыра. Шәһәрне саклаучылар бу хәлдән каушап калалар.

Көн ахырына кызыл полкларның бер өлеше Зөягә (Свияжск),

икенчесе Арчага чигенә. Комуч гаскәре зур җиңүгә ирешә. Казан яулап алына. 7 августта шәһәр идарәсе оештырыла. Идарә завод-фабрикаларны элекке хуҗаларына кайтарып бирә башлый. Каршылыктан куркып шәһәрдә хәрби хәл кертелә.

Шәһәрдән китәргә өлгерми калган кызылармеецлар һәм партия хезмәткәрләре кулга алына һәм атып үтерелә. Алар арасында Россия коммунистлар (большевиклар) партиясе губерна комитеты рәисе Я. С. Шейнкман, Үзәк мөселман комиссариаты рәисе М. М. Вахитов һәм башка бик күпләр була. Казан кремле диварларына куелган истәлек тактасыннан байтак фамилияләрне укырга мөмкин.

Шулай да кызылларның ныклы каршылык күрсәтүе гаскәрләрнең Казаннан ерак түгел Зөя янында ныгып калуына мөмкинлек туды-ра. Хәлиткеч зур сугышка әзерлек башлана. Совет властен ныклап урнаштыру өчен көрәш дәвам итә.

Мулланур Вахитов.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Большевиклар Оештыру җыенын куып тараткач, илдә нинди хәл барлыкка килә?
2. Большевиклар нинди юллар белән татар милли хәрәкәтен таркаталар?
3. Аклар тарафыннан Казанның алынуы хакында сөйләгез.
4. Гражданнар сугышы елларында сез яшәгән якларда нинди вакыйгалар булган? Бу хакта олылардан сорашып, язып килегез.
5. «Тарихи сүзлеккә» «гражданнар сугышы» «Идел-Урал штаты», «Татар-башкорт Совет Социалистик республикасы» төшенчәләрен аңлатып языгыз.

49. КАЗАН ӨЧЕН СУГЫШ. КОЛЧАК АРМИЯСЕНӘ КАРШЫ КӨРӘШ

Казан янында җиңелгәч, Совет хөкүмәтенең хәле нык авырая. Идел буе элек-электән Россияне икмәк белән туендырып торучы бер төбәк була. Украина ул вакытта немецлар кулында. Идел буеның дошман кулында калуы Россияне Урта Азиядән, Себердән аера. Россия үзәгендә ачлык, ялангачлык, җимереклек хөкем сөрә. Бу бәлаләрдән котылу өчен Россия республикасында хәрби хәл игълан ителә. Барлык көч илне саклауга юнәлдерелә. Авылда крестьяннардан шәһәр һәм армия өчен мәҗбүри төстә азык-төлек җыялар. Эшкә аяк чалучылар һәм контрреволюционерлар белән көрәшү өчен гадәттән тыш комиссияләр төзелә. Аларны ЧК дип (русча «чрезвычайные комиссии» дигән сүзнең баш хәрефләре) йөрткәннәр, ә анда хезмәт итүчеләрне чекистлар дип атаганнар.

1918 елның августында Казан тирәсендә бөтен Совет Россиясенең язмышы сынау астына куела. Россиягә каршы сугышкан бөтен илләрнең күз карашы Казанга төбәлә. Аклар Казанны алса, илнең башкаласы Мәскәүгә дә юл ачыла дигән сүз! Хәлнең мөшкеллеген аңлаган В. И. Ленин Көнчыгыш фронтка иң яхшы полкларны, сугыш кирәк-яракларын җибәрә. Казан бирелү белән хәрби һәм диңгез эшләре халык комиссары Л. Д. Троцкий үзе килә. Казаннан ерак түгел, Зөя шәһәрендәге штабка килеп, ул яңа армия төзи башлый. Буйсынмаган, тәртип бозган солдатларны аттыра. Әмма аның белән генә эш тизләнми, сугыш озакка сузыла. Казан янына тагын Мәскәүдән, Петроградтан яңа көчләр җибәрелә. Гражданнар сугышы герое В. М. Азин командалыгындагы җирле халыклардан төзелгән 2 нче армия Казаннан төньяк-көнчыгышта дошманга каршы хәрәкәт итә. Зөя көчле хәрби лагерьга әверелә.

Кызылларның җанланганын күреп, аклар яңадан һөҗүм башлыйлар. 29 августның төнендә алар ике яклап һөҗүмгә күчәләр. Берсе Түрләмә, икенчесе Обсерватория аша Зөягә һөҗүм итә. Максатлары Идел аша салынган күперне кулга төшерү була. Оста оештырылган һәм кинәт башкарылган бу һөҗүм нәтиҗәсендә аклар Зөя янына ук килеп җитәләр. Монда бик каты сугышлар башлана. Сугышчылар, патроннарын атып бетергәч, кул сугышына күчәләр. Күп кан коела. Шулай да аклар уңышка ирешә алмыйлар, чигенергә мәҗбүр булалар.

Кызыллар тиз йөрешле хәрби корабларда Казанга һөҗүм итәләр. Елга портында дошман батареясен юк итәләр, бер пароходны, баржаны батыралар. Хәрби корабларның берсендә Л. Д. Троцкий үзе командалык итә.

Казан өчен көрәш кызганнан кыза бара. 5 сентябрьдә кызыл гаскәрләр Казанга өч яктан һөҗүм башлыйлар. Аларга Идел хәрби флотилиясе ярдәмгә килә. Аның башында Балтик флоты морягы Н. Г. Маркин тора. Арча ягыннан В. М. Азин командалыгындагы армия һөҗүм итә.

Кызыллар Югары һәм Түбән Осланны штурмлап шәһәр янындагы биек урыннарны кулга төшерәләр, шуннан артиллерия белән Казанны утка тота башлыйлар. Моннан файдаланып, комиссар Н. Г. Маркин җитәкчелегендәге десант Яңа Татар бистәсенә бәреп керә. Алар артыннан башкаларга да юл ачыла.

Бер үк вакытта Юдино ягыннан кызыл полклар атакага ташлана. Аларга очучылар, хәрби кораблар, бронепоездлар булышлык итә. Тимер юллар кисешкән урында сугыш аеруча каты була. Ул берничә тапкыр кулдан кулга күчә. Ниһаять, аклар түзә алмый чигенәләр. 1918 елның 10 сентябрендә Казан акгвардиячеләрдән һәм интервентлардан азат ителә.

Казан алынганнан соң бөтен Көнчыгыш фронты һөҗүмгә күчә. 12 сентябрьдә Сембер азат ителә. Аклар Урал буена чигенә.

Кызыл полклар Казанга килеп кергәч, Комуч хакимлеген яклаган бөтен кешеләр эзәрлекләнәләр. Большевикларга каршы көрәшкән кешеләр судсыз-нисез җәзалап үтерелә. Күп байлар, зыялылар юк ителә. Алар арасында танылган рус шагыйренең оныгы — Казан шәһәренең күренекле җәмәгать эшлеклесе, үз вакытында эшчеләр өчен бушлай берничә шифаханә ачкан кеше — А. Н. Боратынский да була.

Завод-фабрикаларда хәрби тәртип кертү көчәя. Моннан риза булмаган эшчеләр кайбер заводларда большевикларга каршы баш күтәрәләр. Авылда да хәлләр мөшкелләнә. Хәерчеләнгән крестьяннардан азык-төлек тартып алу дәвам итә. Бу халыкның ризасызлыгын тагын көчәйтә.

Шушы хәлдән акгвардиячеләр оста файдаланалар. 1919 елда Омскида адмирал Колчак үзен Россиянең хакиме дип игълан итә. Ул бөтен фронт буенча һөҗүмгә күчә. Аңа бай крестьяннар да, эшчеләрнең бер өлеше дә ярдәм итә. Хәтта аның кулы астында Ижевск заводы эшчеләреннән тулы бер армия дә оеша.

Илнең бер өлеш алтын запасын кулга төшереп, Колчак зур армияне коралландыра һәм аны Мәскәүгә каршы күтәрә. Тагын Совет Россиясенә үлем куркынычы яный. В. И. Ленин бар кешене Колчак белән көрәшкә чакыра. Колчак яулары Казан губернасының көньяк-көнчыгыш районнарын басып алалар.

Казанда яңа полклар оеша. Беренче татар бригадасы Оренбург янында һәм ары көньякта Колчак-

ка каршы батырларча сугыша. Колчакка каршы көрәшүче армиянең күп дивизияләрендә кызылармеецларның яртысы татарлар була.

Агыйдел елгасында Колчак гаскәрләре туктатыла. 4 майда Чистай, 13 майда Бөгелмә, 29 майда Алабуга шәһәрләре, 1 июньдә Әгерҗе тимер юл станциясе азат ителә. Бу сугышларда М. Н. Тухачевский, В. М. Азин, В. И. Чуйков кебек командирлар геройлык күрсәтә. 1919 елның 1 июнендә Татарстан җире тулысынча Колчак яуларыннан азат ителә. Беренче Идел буе татар укчы бригадасында көрәшкән Х. Мәүлетов, Я. Чанышев, Г. Касыймов кебек сугышчылар зур батырлыклары белән танылалар.

Сугыш бетә. Әмма аның авыр нәтиҗәләре, зур йөк булып, халык җилкәсенә төшә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. 1918 елда Казан янында, Идел буенда Совет Россиясенең язмышы хәл ителүне сез ничек аңлыйсыз?
2. Кызыл Армия Казан янындагы сугышка ничек әзерләнә?
3. Бу сугышлар турында сөйләгез.
4. «Тарихи сүзлеккә» «Хәрби хәл», «Контрреволюция», «Чекистлар», «Хәрби лагерь», «Көнчыгыш фронт» дигән төшенчәләрне аңлатып языгыз.

50. КРЕСТЬЯННАРНЫ ТАЛАУ. ИДЕЛ БУЕНДА АЧЛЫК

Идел буеннан акларны куып җибәрү белән генә җиңел тормыш башланмый. Киресенчә, крестьяннарның хәле авырлашканнан авырлаша. Фронт чигенгәч, большевикларга иркенлек ачыла. Илнең матди хәлен җайлау өчен, алар крестьяннарга ябырылалар һәм авылда «хәрби коммунизм» дип аталган тәртип урнаштыра башлыйлар. Барысы да бушлай, һәр нәрсә уртак, янәсе.

1919 елны тагын азык-төлек җитми башлый. Большевиклар, коралланган отрядлар төзеп, крестьяннардан ашлык җыю өчен авылда чын сугыш ачалар. Бу отрядлар кайбер урыннарда шулкадәр тырышалар ки, хәтта җыелган ашлыкны куярга амбарлар җитми. Крестьяннарга тоз, керосин, сабын вәгъдә итәләр. Әмма боларның берсе дә гамәлгә ашмый. Моннан тыш крестьяннарны бушлай төрле эшкә тарталар. Хәрби йөкләрне ташыттыралар. Авыл кешеләрен, җирдән аерып, ак генералларга каршы сугышка алып китәләр. Аеруча яңа власть кешеләре каты куллылык күрсәтә.

Баш күтәргән крестьяннарга каршы.

Авыл кешеләренә яңадан-яңа салымнар уйлап табалар, аларны бер гаепсезгә хөкемгә тарталар. Хәтта Көнчыгыш фронтның революцион советы да урындагы бу властьны талаучылар, юлбасарлар дип атый.

Халыкның түземлеге соңгы чиккә җитә. 1919 елның мартында крестьяннар баш күтәрәләр. Восстание тиз арада Идел буен чолгап ала. Анда 200 меңнән артык кеше катнаша. Коралсыз крестьяннар Кызыл Армиянең җәза отрядларына каршы батырларча көрәшәләр.

Баш күтәрүләрнең кабатлануыннан куркып, Совет хөкүмәте бераз йомшара. Хәер, крестьяннар үзләре дә Колчак һәм Деникин гаскәрләре белән бергә элекке алпавытларның кайтуын теләмиләр. 1919 елның җәенә таба Идел буенда беразга тынлык урнаша.

Ел ахырында яңадан икмәк җыю башлана. Казан губернасы 20 мең пот ашлык тапшырырга тиеш була. Ләкин туктаусыз сугыш, талаулар, салымнар белән йончыган халык бу кадәр икмәкне бирә алмый. Ашлыкны бушка тартып аласыларын аңлаган халык чәчүлекләрне кечерәйтә, я булмаса малга дип, солы гына чәчә башлый. Күпләр урып алган ашлыгын яшерергә тырыша. Хө-

күмәт, моңа җавап итеп, кешеләрне төрмәгә утырта, мөлкәтләрен тартып ала.

Крестьяннарга бушлай җир бирү хакындагы декрет игълан ителгәнгә өченче ел бара. Крестьянның гасырлар буена җиргә хуҗа булырга хыялы һаман тормышка ашмый кала бирә. Алай гына түгел, крестьян җилкәсенә сугыш җимереклекләрен бетерү мәшәкатьләре дә өелә.

Бу хәлләргә түзә алмыйча, Троицк волостенең Яңа Елать авылы кешеләре үзләренең җыеннарында салымнарны киметү турында карар чыгаралар. Моңа җавап итеп, авыл башлыгы бер төркем кешене кулга алырга боера. Алар арасында хатын-кызлар да була. Моңа ачуы чыккан авыл кешеләре солдатларны куып җибәрәләр. Алар күрше-тирә авылларны да баш күтәрергә чакыралар. Халык хәрәкәте кыска вакыт эчендә Казан һәм Уфа губерналарының күпчелек төбәкләрендә таралып өлгерә. Бу хәрәкәтнең төп оештыручысы булмый. Мылтыклар җитми. Шуңа күрә алар сәнәкләр белән коралланалар. Үзләрен «сәнәклеләр» дип атыйлар. Крестьяннар: «Бетсен коммунистлар һәм гражданнар сугышы! Яшәсен Совет власте!» — дип чыгалар.

1920 елның февралендә восстаниене бастыру өчен Кызыл Армиянең яхшы коралланган гаскәрләре җибәрелә. Губерналарда хәрби хәл кертелә. Ягъни сугыштагы кебек тәртип куела: кешеләр рөхсәтсез бер кая да бара алмыйлар, җыелышлар, митинглар үткәрү һәм төнлә йөрүләр тыела. Боерыкка буйсынмаган кешеләр шундук атып үтерелә. Солдатларга каршылык күрсәткән авылларны тупка тотарга кушыла. Баш күтәрүчеләрнең гаиләләрендә 18 яшькә җиткән һәр кешесен кулга алалар. Баш күтәрү дәвам итсә, барысын да аталар. Идел буенда баш күтәрүчеләрне ябар өчен лагерьлар төзелә. Казан янында салынган лагерьда 500 ләп кеше тотыла. Кешелек тарихында беренче тапкыр концлагерьлар чит ил тоткыннары өчен түгел, үз халыклары өчен корыла. Солдатлар авылларда дошман ил кешеләре белән эш иткән кебек рәхимсезлек күрсәтәләр.

Яхшы коралланган гаскәр халыкның баш күтәрүен бастыра. Аерым урыннарда гына каршылык күрсәтү озак дәвам итә. Россиянең 36 губернасында хәрби хәл шактый озак саклана. Бу сугышта йөз меңнәрчә крестьян хөкем ителә, лагерьларга озатыла, атып үтерелә. Йөзләгән авыллар яндырыла. Меңләгән хуҗалыклар бөлә. Хуҗасыз калган җирләрдә ашлык урынына алабута котырып үсә.

Идел буена корылык килә. Иген уңмый. 1921 елның җәендә Идел буеның бик күп җирләрендә тарихта күрелмәгән ачлык афәте

башлана. 30 миллион кеше ачлыктан интегә. Бу — ул вакыттагы Россия халкының биштән бере дигән сүз. Кешеләр агач кайрысы һәм тамыры, үлән ашыйлар, иске тиреләрне пешереп карыйлар. Үлгән һәм тере кешеләрне ашау очраклары була. Кешеләр авылы-авылы белән кырылалар. Бу елларда татар халкының ярты миллионнан артык кешесе үлә.

Бөтен дөнья һәм шул исәптән Россиянең атаклы кешеләре ач кешеләргә ярдәм кулы сузарга телиләр. В. Г. Короленко, М. О. Осоргин, Е. Д. Кускова, А. В. Чаянов һәм башка күпләр Бөтенроссия ярдәм комитеты төзиләр. Бу комитет, кешеләрдән әйбер, азык-төлек җыеп, ачыгучыларга ярдәм оештыра. Бу эш чит илләрдә дә киң колач ала.

Америка хөкүмәте, Герберт Гувер җитәкчелегендә, Россиянең ачлыктан интегүчеләренә булышлык оештыра. Ул Россиягә меңнәрчә тонна ашлык алып килә. Авылларда һәм шәһәрләрдә бушлай ашатулар оештырыла, балалар йортларына ашыгыч ярдәм чаралары күрелә. Әмма большевиклар хөкүмәте бу ярдәмгә бары бер тиешенчә әһәмият бирми. Ярдәмне бүлү өчен оештырылган комитетларга комачаулык итәлә. Ә соңрак аларның эшләре бөтенләй туктатыла.

Ачыгучыларга акча җыю сылтавы белән илнең үзендә дә меңләгән мәчет, чиркәүләрдән кыйммәтле мөлкәт җыела. Музейлардан бәһасез затлы әйберләр, картиналар сатыла. Әмма бу сатудан килгән акчаның бер өлеше генә ачларга барып җитә. Шушы ук акчалар чит ил коммунистлар партияләренә дә ярдәмгә җибәрелә.

Гражданнар сугышы, авыл халкыннан салымнар җыю һәм аннары ачлык Татарстан халкының да матди хәлен нык авырайта. Милли-азатлык хәрәкәте сүнә. Татар халкы тормышында тагын михнәтле авыр чор башлана.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Ни өчен крестьяннар баш күтәрәләр?
2. Кызыл Армия баш күтәрүчеләрне ничек бастыра?
3. Идел буендагы ачлыкны җиңеләйтеп була идеме?
4. Ачларга кем ничек ярдәм итә?

51. ТАТАРСТАН АССРның ОЕШУЫ

1552 елда татар халкының мөстәкыйль дәүләте юк ителде. Шул елдан алып, татар халкы үзенең дәүләтен яңадан тергезү теләге белән яши. 1920 елны татар халкы азатлыкка тагын якынлаша.

Колчакка каршы көрәш вакытында Совет хөкүмәте башкорт

милли хәрәкәте җитәкчесе Зәки Вәлиди белән килешү төзи. В. И. Ленин, ак гаскәрләр камалышында калгач башкорт атлы сугышчыларының ярдәменә өмет тотып, башка әһәмиятле тәкъдимнәрне исәпкә алмыйча, Башкортстан автономияле республикасын танырга була. Бу республикага гел татарлар гына яши торган бик күп җирләр дә кертелә.

Большевиклар татарларга да автономия бирергә вәгъдә итәләр. Автономия — ул, бер дәүләт эчендә яшәп, кайбер хокукларга ия булган хәлдә территория аерымлануы, дигән сүз. Башкортстан автономиясе төзелгәч, татарлар бу мәсьәләне тизрәк хәл итүне сорыйлар. Бу хакта 1920 елның январенда карар кабул ителә. Әмма автономия төзү эше һаман сузыла. Татарстанның чикләре хакында аеруча кызу бәхәс бара. Аңа бүгенге Татарстан җиреннән тыш Башкортстан ягында татарлар гына яши торган җирләрне дә кертергә булалар. Әмма моңа В. И. Ленин һәм Совет хөкүмәте кискен рәвештә каршы чыгалар. Алар Башкортстанның инде аерымланган чикләрен шул килеш калдырырга хәл итәләр. Башкортстанның кайбер татар районнарында гына халык теләгән белү кирәклеге әйтелә. Ләкин бу төбәкләрдә дә халык теләгән ачыклау өчен референдум үткәрелми. Зур Татарстан Республикасы төзүдән большевиклар куркалар һәм халыкны икегә бүлгән килеш калдыралар.

Крестьяннарның туктаусыз баш күтәрүләре һәм каты ачлык автономия төзүдә зур торткарлыклар китереп чыгара. Ниһаять, 1920 елның май башында автономия төзү буенча комиссиянең эше тәмамлана. В. И. Ленин «Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы турындагы» декретка кул куя. Бу татар халкының гасырлар буена килгән хыялын тормышка ашыруда, киң вәкаләтле дәүләт автономиясен булдыруда бер адым була. Ләкин Мәскәү хөкемдарлары, автономия хакында сүз йөрткән булып, яшь республиканы күбрәк үзләренә буйсындырып тоту турында уйлыйлар. Бу омтылыш вәгъдә ителгән мөскәкыйльлекнең юкка чыгуына китерә.

Көтелмәгәндә, республиканың башкаласы хакында мәсьәлә калкып чыга. Җитәкчеләрнең бер өлеше Казанның Татарстан республикасына кушылуына каршы чыгалар. Янәсе, Казанда татарлар аз яши. Патша вакытында бу шәһәрдән торып татарларга каршы колониаль сәясәт алып барылды, дип үз фикерләрен акламакчы булалар алар. Моңа М. Солтангалиев һәм башкалар кискен каршы чыгалар. Алар Казанның борынгыдан алып татар халкының сәяси һәм мәдәни үзәге булуын исбат итәләр. Бу ныклы карашка Ленин да ризалык бирә. Шулай

итеп, Казан автономияле Татарстанның башкаласына әверелә.

Декретка кул куелу турындагы хәбәр тиз арада бөтен республикага тарала. Халык Казан шәһәрендә тантана итәргә урамнарга, мәйданнарга ашыга.

Республика төзелү көнен рәсми рәвештә 1920 елның 25 июнендә үткәрергә булалар. Бу кояшлы җәйге көнне казанлылар өмәгә чыгалар. Аннары гарнизон сугышчыларының парадын карыйлар. Кич белән совет һәм партия җитәкчеләре җыела. С. Сәетгалиев, җыелышта чыгыш ясап, яңа республика хөкүмәтенең максаты бар халыкның тормыш-көнкүрешен яхшырту, мәдәниятен күтәрү икәнлеген әйтә.

26 сентябрьдә Татарстан АССР Советларының I съездында республиканың хөкүмәте төзелә. Республика советы һәм башкарма комитетының җитәкчесе итеп Б. Мансуров, хөкүмәт башлыгы итеп С. Сәетгалиев сайлана.

М. Солтангалиев үзенең көрәштәше Фирдәвес белән.

Республиканың мөстәкыйльлеге, милләтләр тигезлеге, үз билгеләнү хокукы мәсьәләләре СССРны — Совет Социалистик Республикалары Союзын төзегәндә яңадан калкып чыга. СССР төзелү турындагы килешүгә 1922 елның 30 декабрендә кул куела. Анда Татарстан да катнаша. Ләкин Татарстан башка республикалар белән бер дәрәҗәдә хокуклы була алмый. Өстенлек Союз республикасы дип аталганнарына гына бирелә. Автономияле республикалар икенче дәрәҗәле булып калалар. Моңа ризасызлык белдерүчеләр, халыклар тигезлеге хакында сүз алып баручы кешеләр милли сәясәткә каршы дип игълан ителәләр. Аларга «милләтче» дигән исем тагалар һәм андый кешеләрне эшләреннән алалар.

Беренчеләр рәтендә М. Солтангалиев шундый язмышка дучар була. Ул халыкларга күбрәк икътисади һәм мәдәни ирек бирү өчен

көрәшә. 1923 елда ук аңар «дөнья империализмы вәкиле» дигән исем тагылып, ул эш урыннарыннан алына, партиядән чыгарыла. М. Солтангалиев Сталин төрмәсендә явыз ният белән үтерелә.

Автономияле республикаларга бирелгән ярым-йорты хокуклар да 1937 елны кабул ителгән СССР конституциясендә кызыл сүзләр белән генә алыштырылдылар.

Республикада ике теллелек юкка чыгарылды. Рус теле интернациональ тел, бөек тел дип игълан ителде. Татар теле дәүләт теле булудан туктады һәм үл бетүгә дучар ителде. Коммунистлар җитәкчелегендә зур авырлыклар белән яулап алынган хокуклар һәм тигезлек бик азга барды. Элекке милли бәйлелек, буйсынып яшәү тәртибе яңадан кайтты.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Татарстан АССР нинди шартларда төзелә?
2. Кемнәр алар «милләтчеләр»?
3. Халыкларның тигез хокуклылыгын сез ничек аңлыйсыз?
4. «Тарихи сүзлеккә» «милләтләр тигезлеге», «милләтләрнең үз билгеләнүе», «милләтче», «референдум», «башкарма комитет», «гарнизон» дигән төшенчәләрне аңлатып языгыз.

52. БЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫКЛАРДА ПРОМЫШЛЕННОСТЬ

Беренче бөтендөнья, аннары гражданнар сугышы һәм чит илләрнең хәрби интервенциясе, 1921 елгы ачлык аркасында Татарстан да авыр газаплар кичерә. Хуҗалык тәмам таркала. Элекке, бар булган завод-фабрикалар да чимал һәм ягулык җитмәгәнлектән туктап калалар. 1926 елның язында Идел ташып, моңарчы күрелмәгән су басу Казанга зур зыян китерә. Меңләгән йортларны, завод-фабрикаларны, тимер юлларны су баса.

Хезмәт ияләренең тырышлыгы белән Татарстан промышленносте яңадан тергезелә башлый. Беренчеләрдән булып, элекке Алафузовларның күн-тукыма эшләү фабрикалары җанланып китә.

М. Вахитов исемендәге сабын кайнату комбинатында да чимал җитешми. Элек 50 ел буе Крестовниковлар кулында булган бу заводның идәненнән 4000 поттан артык майлы балчыкны, кырып алып, сабын ясау өчен эшкәртәләр.

Пыяла, силикат кирпеч, Печищедагы известь заводы, «Кызыл Октябрь» фанера фабрикасы һәм башка предприятиеләр продукция эшләп чыгара башлыйлар.

Шәһәр хуҗалыгы да әкренләп торгызыла. 1922 елда Казанда яңадан трамвайлар кузгала. Ил



Егерменче еллар плакаты.

коточкыч җимереклектән, ачлыктан котылуга юл ала.

Совет илендә хуҗалык эшләре баштан ук план белән алып барыла. 1929 елдан илне чын-чынлап индустрияләштерү башлана. Планнарны, алга таба нәрсәләр эшләнәсен бишәр еллык срокка атап төзиләр. Шуңа күрә дә аларны бишьеллыклар дип йөртәләр. Ватан сугышына кадәр ил өч бишьеллыкны үтә.

Беренче бишьеллыкларда татарстанлылар нәрсәләр төзегән-

нәр, нинди хезмәт казанышларына ирешкәннәр соң? Бераз гына күз алдына китереп карыйк: электр юк икән, ут та юк, җылылык та юк, дигән сүз. Зур-зур машиналарың да тик тора. Шуңа күрә сугыш вакытында җимерелгән элекке станцияләр торгызыла. Әмма бу кечкенә станцияләр генә алда торган зур бурычларны үтәргә ярдәм итә алмый. 1929 елда Казанда беренче җылылык электр үзәген төзергә керешәләр. 1933 елның 17 январенда ул инде эшләп китә. 1938 елда яңа, икенче станция энергия бирә. Шулай итеп, промышленность куәтле энергиягә ия була. Шәһәрләрдә электр утлары кабына. Ленин җитәкчелегендә төзегән электрлаштыру планын тормышка ашыру гамәле буларак, аларны Ильич лампалары дип атыйлар.

Беренче бишьеллыкта (1929—1933 еллар) Татарстанда 20 дән артык яңа зур завод-фабрика сафка кертелә. Казан «Пишмаш» («пишущая машина» дигән сүздән) заводында илдә беренче язу машиналары җыела. СССР да берләнбер кетгут заводы продукция эшләп чыгара башлый. Казан суыткычы, Идел буе фанера заводы, теш дәвалау кораллары, химия-дару ясау заводлары сафка баса. М. Вахитов исемендәге сабын кайнату, «Спартак» күн аяк киемнәре, Ленин исемендәге җитен комбинатлары, «Урак-чүкеч», Бондюг (хәзер Менделеевск шәһәре) химия заводлары яңартыла, киңәйтелә.

1930 елда тагын бер зур вакыйга була. Казанның Арча кырында аэростанция төзелә. Озаклямый, пассажирлар утыртып, Казаннан төрле төбәкләргә даими рәвештә самолетлар оча башлый.

Беренче бишьеллык чорында ук Татарстан индустриаль-аграр республикага әверелә.

Икенче бишьеллыкта (1933—1937 елларда) эреле-ваклы 400 гә якын предприятие төзелә. Шул елларда СССР күләмендә иң зур предприятиеләрдән саналган кино тасмасы фабрикасы бөтен ил көче белән сафка бастырыла. Бик авыр шартларда төзелә бу завод. Ул үзенең беренче продукциясен 1935 елда ук эшләп чыгара. Бу тасмаларга беренче революцион совет фильмнарыннан «Без — Кронштадтан» дигән фильм төшерелә.

1932 елда самолет ясау заводы төзелә башлый. 30 нчы еллар ахырына Казан илнең авиация төзелеше буенча зур бер үзәге була. Нәкъ шушында киләчәк сугышта фашистларның котларын алырлык самолетлар эшләнә.

Казанның элекке Кәҗә бистәсе ягында авиация заводы эшчеләре өчен үзе бер шәһәрчек — «Социалистик шәһәр» (Соцгород) төзелә. Шунда Казанның иң зур — Ленин районы үсеп чыга.

Республикабыз башкаласында күп заводлар төзелә. Алар ара-

сында иң әһәмиятлеләреннән берсе — синтетик каучук заводы. Каучуктан 50 меңгә якын төрдәге әйберләр ясап була. Шулар арасында замана өчен иң кирәклесе — резина әйберләре, шиннар. Завод 1936 елда инде эшли дә башлый. Мондый завод Германиядә ике, Америкада алты елдан соң гына төзелә.

Күн, мех эшкәртү, киез аяк киемнәре җитештерү тагын да алга китә. Илдәге мех әйберләрнең яртысы, фетр аяк киемнәренең барысы да диярлек Татарстанда эшләп чыгарыла. Кыйммәтле тиреле җәнлекләр өчен зур-зур фермалар салына.

Өченче бишьеллыкка да (1938—1942) күп эшләр планлаштырыла. Аның беренче ике елында 84 яңа эре предприятие төзелә. Зурлары — ясалма күн, фотожелатин, кирпеч, бетон заводлары. Татарстанда аеруча химия һәм машина төзелеше промышленносте тиз үсә. Көнчыгыш районнарда нефть эзләү — «Икенче Баку» булдыру өчен кызу эшләр башлана. Казан белән беррәттән, Зеленодольскида, Чистайда, Бөгелмәдә, Юдинода, Васильевода промышленность предприятиеләре төзелә.

Эшчеләр һәм хезмәткәрләр таң калырлык хезмәт батырлыклары күрсәтәләр. Бик күп кешеләр, ударниклар, стахановчылар хәрәкәтенә катнашып, хезмәт нормаларын әлләни кадәр арттырып үтиләр. Ләкин Татарстанның үзендә зур төзелешләр булса да, меңләгән эшче көчләр, аеруча татарлар яши торган авыллардан, Урал, Донбасс, Мәскәү, Ленинград, Себер, Украина, Урта Азия һәм Ерак Көнчыгыш кебек төбәкләргә җибәрелә. Аларның күбесе шунда төпләнеп кала. Татарстандагы төзелешләргә, киресенчә, илнең күп җирләреннән, башка милләт кешеләреннән эшчеләр китерелә. Бу татар халкының республикада кимүенә китерә.

Менә шул рәвешчә завод-фабрикалар күпләп төзелә, тик эшчеләрнең батыр эшләренә бәрабәр бай, матур тормыш төзелми. Эшчеләр, хезмәткәрләр аеруча беренче бишьеллыкта землянкаларда, палаткаларда, вакытлы баракларда яшиләр. Еш кына ашарларына, эчәрләренә дә җитми. Эш хаклары да бик түбән була. Аның да шактый өлешен мәҗбүри төстә «Илне индустрияләштерү заемына» тотарга тиеш булалар. Зур-зур заводфабрикалар сафка басса да, эшчеләрнең тормыш-көнкүрешен яхшыртырлык җиңел промышленность предприятиеләре бик аз корыла. Авыл хуҗалыгы, көнкүреш хезмәте күрсәтү тармаклары бик артта кала. Халыкның сәламәтлеген, табигатьне саклау, мәдәниятне үстерү өчен бик аз акча бирелә.

Бу елларда Сталинның тоталитар режимы хакимлек итә. Промышленность белән идарә итү тулысынча үзәктән боерык бирү

юлына күчерелә. Күп кенә талантлы хуҗалык җитәкчеләрен, белгечләрне, нахак бәлаләр тагып, юк итәләр.

Беренче бишьеллыкта ирешкән уңышлар, Татарстанның гына түгел, бөтен илнең алдагы язмышы өчен дә гаять зур әһәмияткә ия булды. Бу казанышлар Ватан сугышы елларында көчле дошманны җиңеп чыгарга ярдәм иттеләр. Беренче бишьеллыкларда төзелгән завод-фабрикалар, Татарстан карамагына күчеп, бүген дә аның икътисади көченең нигезен тәшкил итәләр.

Сораулар:

1. Беренче бишьеллыкларда Казанда нинди завод, фабрикалар төзелә?
2. Ни өчен халыкның тормышы ныклап яхшырмады?

53. БАРЫН ДА — КОЛХОЗГА!

Гомер-гомергә крестьян үзенә җир булдыру турында хыялланган. Ләкин Россиядә крепостной тәртипләр хөкем сөргәндә дә, капитализм чорында да җирләрнең күп һәм уңдырышлы өлеше алпавытлар һәм кулаклар кулында булган. Крестьяннарга исә аз җир тигән, тормыш итәр өчен аннан алынган уңыш кына җитмәгән. Шуңа күрә алар гомер буе авыл байларының җирләрендә бил бөгеп эшләгәннәр. Шунлыктан алар җир иреге алу өчен патшага һәм шул байларга каршы көрәшкәннәр.

Октябрь революциясе җиңгәч тә, советларның икенче җыенында «Җир турында декрет» кабул ителә. Алпавытларның җирләрен шул декрет нигезендә крестьяннарга өләшәләр. Крестьян, бөтен тырышлыгын куеп, үз җирендә эшли башлый. Ләкин бу ирек озакка бармый. Гражданнар сугышы башлангач, хөкүмәт, хәрби коммунизм игълан итеп, иген уңышын крестьяннардан бушлай җыеп алып бара. Тик НЭП (яңа экономик политика) игълан ителгәч кенә крестьяннарга тагын ирек бирелә. Ашлык амбарлары тиз арада икмәк белән тула. 20 нче еллар урталарында инде иген уңышы җыеп алу революциягә кадәрге дәрәҗәгә күтәрелә. Икмәк крестьяннарның үзләре өчен дә, шәһәр халкы өчен дә, хәтта чит илләргә чыгару өчен дә җитә. Үз җирендә тәм табып эшләүче чын хуҗалар — ирекле крестьяннар барлыкка килә.

Әмма хәлләр тиздән тагын үзгәрә. Совет хөкүмәте илне индустрияләштерү планы эшли. Аны тормышка ашыру өчен гаять зур чыгымнар сорала. Промышленность товарлары бик аз чыгарылганга

Чистай трактор колоннасы Яуширмә авылында язгы кыр эшләренә чыгарга әзер. 1929 ел.

күрә ул чорда акчаны бары тик чит илгә икмәк сату исәбенә генә табарга мөмкин була. Шуның өчен хөкүмәт үзенең төп игътибарын авылга туплый. Большевиклар, авыл халкыннан күбрәк һәм арзан хакка икмәк алу өчен иң кулай юл — күмәк хуҗалыклар (колхозлар) оештыру, дигән фикергә киләләр.

Большевикларның бу планы беренче карашка әйбәт сыман күренә. Җирләрне, мал-туарларны берләштереп, күмәк хуҗалыклар ясагач, эшләр күпкә җиңеләер, машина-трактор сатып алыр өчен дә мөмкинлекләр ачылыр, муллык артыр, дип уйланыла. Ярлылар һәм байлар булмас, һәркем тигез булыр, дип исәпләнелә. 1929 елда илдә колхозларны күпләп оештыру башлана.

Ләкин авыл кешеләренең күбесе моны якламый, каршы килә. Атсыз-җирсез крестьяннар гына тизрәк колхоз төзергә ризалык бирәләр. Колхозлаштыру һәр җирдә янаулар, куркытулар белән алып барыла. Колхозга кермәгән кешеләрне кулаклар, совет хакимияте-

нең дошманы дип игълан итәләр. Андыйларны, миллионнарча кешеләрне, бар булган мөлкәтен тартып алып, төрмәләргә ябалар, Урал, Себер, Казахстан якларына сөрәләр.

Колхозга кермәс өчен крестьяннарниләр генә эшләмиләр: ашлыкларын яшерәләр, терлекләрен суялар, мал-мөлкәтләрен юк итәләр, югары оешмаларга шикаятьләр язалар, хәтта кайбер урыннарда корал тотып баш күтәрүгә кадәр барып җитәләр. Билгеле, халыкның нәфрәте беренче чиратта колхозларны оештырып йөрүчеләргә төшә. Байтак колхозларның рәисләре үзләренең авылдашлары кулыннан һәлак булалар. Хөкүмәт хәлне бераз йомшартырга мәҗбүр була: кош-кортларны, йорт әйберләрен күмәкләштерү тыела, крестьяннарга йорт тирәсендә 15—20 сотый җир мәйданы бирелә.

1932 елда авылда колхозлар төзү тәмамлана. Шулай итеп, крестьяннарның гасырлар буе килгән яшәү рәвеше үзгәрә. Алар хәзер уртак басуларда, терлекчелек фермаларында барысы бергә эшли. Хезмәт хакын акчалата түгел, ә эшләгән көн санына карап, ашлыклата түлиләр. Ел саен юк кына бәягә фәлән кадәр икмәк һәм башка авыл хуҗалыгы продуктларын сатарга дип, аларга хөкүмәттән зур-зур планнар җиткерелә.

Әмма ләкин күмәк хуҗалыклар оештырып кына авылда эшләр көйләнми. Киресенчә, уңыш елдан ел түбәнәя бара. Мал-туарларның баш саны берничә мәртәбә кими. Ә шәһәр халкын, армияне туйдырырга дип, ашлыкны ел саен күбрәк таләп итәләр. Күп кенә төбәкләрдә колхозларны соңгы чәчүлек орлыкларына кадәр тапшырып бетерергә мәҗбүр итәләр. Нәтиҗәдә 1932—1933 еллар кышында илдә коточкыч ачлык башлана. Алты миллионлап кеше ачтан үлә. Крестьяннарның тормышы патша вакытындагы белән чагыштырганда да начарлана.

Менә И. Сталинга җибәрелгән хатларның берсеннән өзекләр укып карагыз. Аны Апас районының Шонгаты авылыннан Я. Н. Крупов дигән кеше язган.

Иосиф Виссарионович Сталинга хат.

Ип. Сталин! Партиягезнең икмәк әзерләү программасын ялгыз хуҗалыкчы белән колхозчыны ач калдырмыйча гына хәл итәсе иде. Һәркемгә яңа уңышка кадәр җитәрлек икмәк калдырылырга тиеш... Бу бит, «икмәк әзерләү» дигән булып, халыкны талау. Безнең урыннардагы властьларыбыз крестьяннарны каты ачлыкка һәм әшсезлеккә дучар иттеләр. Бу кешеләр минем 120 пот кына икмәк җыеп алуыма карамастан, 200 пот салым салдылар. Әгәр дә әйтелгән көнгә үз теләгем белән шуны илтеп тапшырмасам,

миңа тагын 50 сум штраф салалар. Авылда 5 сум табуы да кыен, ә бернәрсәне дә сатарга рөхсәт итмиләр. Өйгә киләләр дә, сорапнитеп тормыйча, урын-җирне, самоварны һәм барлык кием-салымны төяп алып чыгып китәләр...

Тагын бер тапкыр үтенәм, ип. Сталин, нинди дә булса чара күрегез. Гаиләләребезнең ачлыктан һәлак булуына юл куймагыз. Авылдагы элекке 3250 кешедән 500 е генә калды. 500 баш аттан 50 се исән. Безнең гаиләләребезгә икмәк һәм кием бирегез, берүк ачтан үтермәгез.

Я. Н. Крупов.

Мондый хатларны Казаннан ары җибәрә алмаганнар, әлбәттә. Бу җәберләрне оештыручы кеше Сталин үзе була.

Көчләү һәм мәҗбүр итү юлы белән генә уңышка ирешеп булмый шул. Колхозлар илдә азыктөлек муллыгы булдыра алмадылар. Колхозлаштыру социализм төзү идеясенә туры килмәвен тулысы белән гамәли раслады.

Сораулар:

1. Ни өчен колхозлар оештыру башлана?
2. Аларны оештыру нинди юллар белән бара?
3. Колхозлаштыру нәтиҗәсендә нинди хәлләр килеп чыга?
4. Сез ничек уйлыйсыз: авыл хуҗалыгын үстерү өчен башка юллар бар идеме?

54. МӘДӘНИЯТТӘ ДӘ РЕВОЛЮЦИЯ БУЛАМЫНИ?

1914 елда башланган герман сугышы, 1917 елгы революция, аннан соң гражданнар сугышы, миллионнарча кеше гомерен өзгән 1921 елгы ачлык яшәп килгән мәгарифне, мәдәниятне чыгырыннан чыгара.

Шундый афәтләргә карамастан, озак та үтми, совет хөкүмәте наданлыкны, артта калуны бетерү өчен әһәмиятле эшләр башлап җибәрә.

Наданлыкны бетерү өчен махсус мәктәпләр ачыла. Анда балалар гына түгел, эштән соңгы вакытта зурлар — эти-әниләр, абыйапалар укырга-язарга өйрәнәләр. Татарстанда яшәгән халыкларга үз телләрендә белем алырга мөмкинлек ачыла.

Фән һәм югары белем бирү тиз үсә башлый. 1925 елда Татарстанда 5 югары уку йорты һәм берничә техникум булса, 1940 елда 14 югары уку йорты һәм 12 техникум эшли. 1922 елда ачылган Татар коммунистик университеты кадрлар әзерләү үзәгенә әверелә.

Наданлыкны бетерү дәресләре.

20—30 елларда Татарстанда күп кенә күренекле галимнәр яши һәм эшли. Татарстанда туган күренекле химик А. Арбузов (1877—1968) фосфор-органик кушылмалар өлкәсендә ачышлар ясый. Электрокардиографиягә нигез салучы А. Самойлов хезмәтләре дөнья күләмендә танылa. Мәшһүр хирург А. Вишневский Казанда авыруларны дәвалаганда новокаин блокадасы куллану ысулын нигезли. Без ул ясаган «Вишневский маен» кирәк очракларда хәзер дә кулланабыз. Тел белемендә В. Богородицкий, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, тарих өлкәсендә М. Худяков, Г. Гобәйдуллин нәтиҗәле эшлиләр.

Революциягә кадәр үк танылган язучылар Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш яңа революцион рухлы әсәрләр иҗат итәләр. Әдәбиятка талантлы яшь яңа буын шагыйрьләр, язучылар килә. Һади Такташ, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, Шамил Усманов, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Муса Җәлил югары рухлы әсәрләр тудыралар.

1920 елда Татар дәүләт академия театры оеша. Анда Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» спектакльләре зур уңыш лар белән бара. Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов, Шакир Шамильский, Гөлсем Болгарская, Фатыйма Ильская, Нәгыймә Таҗдарова, Хөсәен Уразиков, Мохтар Мутин, Камаллар кебек артистлар

аеруча оста уйный. Зур рус драма театрында да А. Царев, М. Жаров, Н. Якушенко, Е. Жилина кебек атаклы артистлар күп була.

1935 елда рус яшь тамашачылар театры ачыла.

1926 елда В. Виноградов, С. Габәши һәм Г. Әлмөхәммәдов иҗат иткән беренче татар операсы «Сания» куела.

1939 елның 17 июнендә Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән Татар дәүләт опера һәм балет театры ишекләрен ачып җибәрә.

Ул елларны татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы — күренекле композитор Салих Сәйдәшев (1900—1954) берсеннән-берсе халыкчан рухлы, аһәңле музыкаль әсәрләр яза. Аның «Совет армиясе маршы», «Әдрән диңгез», «Шәрык биюе» һәм күп кенә башка көйләре бүген генә язылган өр-яңа әсәрләр кебек яңгырый.

1937 елда Татар дәүләт филармониясе оеша.

1927 елда республика тормышында зур вакыйга була. Беренче мәртәбә Казаннан даими радиотапшырулар башлана. Әле ул вакытта радиоалгычлар сирәк, шуңа күрә кешеләр аны бергә җыелып тыңлаганнар.

1941 елда Фәрит Яруллин (1914—1944) бүген дә бик яратып карала торган «Шүрәле» балеты музыкасын иҗат итә. Ул соңга таба илебез сәхнәләрендә генә түгел, чит илләрдә дә ярату казана.

А. Арбузов.

1927 елда татарларның Е. Пугачев җитәкчелегендә крестьяннар сугышында катнашуы хакында «Булат батыр» исемле кино төшерелә. Татарлар тормышыннан «Койрыклы йолдыз» исемле икенче фильм 1929 елны Казанда төшерелә.

1934 елда Казанда курчак театры ачыла.

Күренекле рәссамнардан Казанда туган Н. Фешин (1881—1955) һәм П. Беньков (1879—1949) матур картиналар иҗат иттеләр. Бе-

Һ. Такташ.

С. Сәйдәшев.

ренче татар профессиональ рәссамы Б. Урманче (1897—1990) ул елларда ук талантлы картиналар ясый.

20—30 елларны Казанның тышкы йөзенә дә шактый үзгәреш керә. Күп кенә торак йортлар, мәдәният биналары төзелә. «Родина» кинотеатры, Матбугат йорты, Химия-технология институты бинаклары шундыйлардан була.

Ләкин шушы чорда Татарстанда фән, мәгариф, мәдәният өлкәсендәге уңышлар белән бер рәттән, мәдәни мираска кагылышлы бик зарарлы эшләр дә эшләнә. 1926 елгы халык санын алу нәтиҗәләренә караганда, укый-яза белү буенча татар халкы СССРның барлык халыклары арасында беренче урында була. Әмма мең ел буе татарлар өчен мәдәниятнең нигезе булып хезмәт иткән гарәп әлифбасы дин, искелек калдыгы дип игълан ителә. 1928 елда ул латин графикасы белән алыштырыла. Халык гарәп әлифбасы нигезендә барлыкка килгән мең еллык мәдәнияттән аерыла. Бу халык өчен, аның мәдәнияте өчен чын афәт була. Яңа әлифба нигезендә укырга-язарга өйрәнеп килгәндә бәла яңадан кабатлана. 1939—1940 елларны латин әлифбасы рус хәрефенә (кириллицага) алыштырыла.

К. Тинчурин.

С. Габәши.

Совет елларында һәртөрле дингә, мәчет, мәдрәсәләргә, чиркәүләргә һәм башка гыйбадәтханәләргә каршы сугыш игълан ителә. Мәчетләр ябыла, манаралары кисеп аударыла. Элек һәр татар авылында диярлек бер һәм берничә мәчет булса, шундый афәттән соң ул бик сирәк күренешкә әверелә. Алдау, куркыту, көч куллану кебек төрле юллар белән халыкның иң изге хисләре мәсхәрәләнә, иманы, дине тартып алына. Алай гына да түгел, гарәп әлифбасында язылган китаплар җыеп алына, яндырыла, аларны саклаган кешеләр төрмәләргә ябыла. Шул рәвешчә халык үзенең мең еллык мәдәниятеннән мәхрүм кала.

Сугыш алды елларында Сталин һәм аның булышчыларының ерткычлыгы аеруча көчәя. Иң күренекле язучылар, татар зыялылары төрмәләргә ябыла, аттырыла, Себер, Колыма лагерьларына сөрелә, интектереп үтерелә. Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Мохтар Мутин, Кәрим Тинчурин... Алар күпләр, бик күпләр.

Димәк, мәдәнияттә революция дигән нәрсә бик аяныч хәлләр дә китереп чыгара икән.



Рәссам Н. Фешин. *В. Адоратская портреты.*

Сораулар һәм биремнәр:

1. Татар профессиональ музыкасына нигез салучы популяр композитор кем, аның нинди әсәрләре бар?
2. Беренче татар операсын кем язган? Аның исеме ничек?
3. Гарәп әлифбасын алыштыру нинди нәтиҗәләргә китерә?
4. Бу дәрестә телгә алынган берәр язучы яисә рәссам, артист хакында укып килегез.

АЛТЫНЧЫ
БҮЛЕК

ТАТАРСТАН БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА (1941—1945)

55. БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ БАШЛАНУ. «БАРЫСЫ ДА ФРОНТ ӨЧЕН!»

1941 елның 22 июне. Якшәмбе көн. Алсу таң атып килә. Кояш чыгарга иртәрәк әле. Кешеләр тыныч йокыда, эшкә барасы юк — ял көне булгач, озаграк йокларга да ярый. Бөтен табигать сихри тынлыкка чумган. Кайдадыр еракта чут-чут итеп сандугач сайравы гына ишетелә.

Шушы сихри тынлыкны бозып, кинәт көнбатыштан самолетлар гөрелтесе ишетелә. Шомлы үкерү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара, кешеләр ни булганын аңлап бетергәнче йөзләгән, меңләгән хәрби самолетлар тыныч шәһәрләр һәм авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый. Күпкатлы йортлар гөрселдәп авалар, күккә тузан болыты күтәрелә, коточкыч янгын башлана. Дөньяның асты өскә килгәндәй була. Урамнарда, юлда очраган бөтен нәрсәне вата-сыта килүче свастикалы танклар, бала-чаганың, аналарның ачынып елаган тавышлары, кан, үлем...

Тиздән радио туган илебезгә фашистлар Германиясенең хыянәтчел һөҗүме турында куркыныч хәбәр тарата. Бөек Ватан сугышы менә шулай башланып китә.

Капиталистик дәүләтләр Советлар Союзына күптән инде һөҗүм ясарга җыенып йөриләр. Тыныч кына социализм төзеп ятучы халыкның уңышлары ошамый аларга. Дөньяның беренче социалистик дәүләтен алар дошман күрәләр, үзләрендә дә революция булып, коммунистлар хакимияте урнашудан куркалар. Сталинның һәм Коммунистлар партиясенең әле һаман да бөтендөнья социалистик революциясе турында хыялланып йөрүләре сугышның башлануын тизләтә генә.

Башында Адольф Гитлер торган фашистлар Германиясе бөтен дөньяны үзенә буйсындырырга омтыла. 1939 елда сугыш башлап, гитлерчылар Польшаны, Чехословакияне, Францияне һәм башка күп кенә илләрне басып алалар. Европа илләрен зур көч түкмичә, ансат кына яулап алу Гитлер генералларының башларын әйләндерә. Алар Советлар Союзын «яшен тизлегендә тар-мар итү» өчен чик буенда күп итеп гаскәр һәм сугыш

техникасы туплыйлар. Барлыгы 8 миллион 500 мең кешелек армия, 11 меңләп танк һәм артиллерия, шулкадәр үк хәрби самолетлар... Әйе, бу кадәр көчкә каршы тору җиңел булмый. Ватаныбыз яшәү белән үлем арасында кала.

Советлар Союзының бөтен милләт халыклары бердәм рәвештә изге Ватанны сакларга күтәреләләр. Кичәге эшчеләр, колхозчылар, инженерлар, укытучылар, врачлар, язучылар, студентлар, урта мәктәпне яңа гына тәмамлап чыккан яшүсмерләр үзләрен, хәрәкәттәге Кызыл Армия сафларына тизрәк алуларын сорап, военкоматларга мөрәҗәгать итәләр. Тиз арада Татарстан җирендә төрле милләт вәкилләрен берләштергән хәрби дивизияләр оештырыла. Завод-фабрикалардан, колхозлардан фронтка киткән ирләргә алмашка картлар, аналар, энеләр-сеңелләр, балалар эш урынына баса. Татарстан «Барысы да фронт өчен! Барысы да җиңү өчен!» дигән изге омтылыш белән яши башлый.

* * *

Промышленность тулысынча диярлек сугыш кирәк-яраклары җитештерүгә көйләнә. Мәсәлән, Казанның кино тасмасы фабрикасы тиз арада самолеттан дошман объектларын фотога төшерү өчен яңа төр продукция эшләп чыгаруны үзләштерә. Бик күп предприятиеләр миналар, гранаталар, автоматлар, бомбалар һәм башка төрле сугыш кораллары ясарга яраклаштырылалар.

Сугыш барган җирләрдән Казанга, Чистайга һәм башка шәһәрләргә йөзләгән завод-фабриканы күчереп урнаштырырга туры килә. Яхшы гына эшләп утырган заводларны сүтеп, меңләгән тонналы җиһазларны тимер юл составлары белән көнчыгышка озату, аларны яңа җирдә яңадан торгызу һәм эшләтеп җибәрү гаять катлаулы, искиткеч фидакарьлек сорый. Тыл кешеләре авырлыклар алдында югалып калмыйлар. Казан авиация заводы Мәскәүдән күчеп килгән С. П. Горбунов исемендәге авиация заводын үз канаты астына ала. Тиздән биредә Кызыл Армиянең горурлыгы булган Пе-2 бомбардировщиклары ясап чыгара башлыйлар. Сәгатенә 480 километр тизлектә оча торган өч урынлы бу самолет бортына 3 тоннага якын бомба ала торган була.

Ленинградтан күчеп килгән авиация заводы нигезендә Казанда тагын бер яңа завод үсеп чыга (хәзерге вертолет заводы). Биредә төнлә оча торган По-2 бомбардировщиклары эшләнә. Атаклы Чистай сәгать заводы да дәһшәтле сугыш елларында Мәскәүнең 2 нче сәгать заводы нигезендә барлыкка килә.

Татарстан хезмәт ияләренең тырышлыгы нәтиҗәсендә промышленность предприятиеләре туктаусыз эшләп тора. Завод-фабрика-

лардан сугыш кырына берәзлексез корал, кием-салым, медицина приборлары, сугыш кирәк-яраклары озатыла.

Колхозчылар фронтны азык-төлек белән тәэмин итеп торалар. Алар илгә һәм армиягә миллионнарча пот ашлык, меңләгән тонна ит, сөт, йомырка, башка продуктлар бирәләр. Колхоздагы барлык тракторлар, машиналар, хәтта атлар да фронтка җибәрелә. Язын басуларны сөргәндә, чәчкәндә, көзен игеннәрне урып-җыйганда ат урынына күп вакыт үгез-сыер җигеп эшләргә туры килә. Бөтен авырлык хатын-кыз, карт-коры, мәктәп балалары җилкәсенә төшә.

* * *

Фронттан өчпочмаклы солдат хатлары килә тора. Көн саен үлем хәбәре. Көн саен фаҗига. Җиңелү ачысы, ачлык михнәте. Ни генә булмасын, халкыбыз бирешми. Казан госпитальләрендә эшләүче шәфкать туташлары әллә никадәр яралы сугышчыларны үлемнән коткаралар, терелгәннәрен яңадан фронтка озата торалар. Сугыш барган яклардан бер әйберсез күченеп килгән йөз меңнәрчә кешеләрне киң күңел белән каршы алалар, фатирга урнаштыралар, соңгы икмәк телемнәренә кадәр бүлешәләр.

Татарстан халкы, бердәм гаилә булып, Ватаныбыз иминлеге өчен батырларча көрәшә. Ленинград фронтындагы татар сугышчылары, үзләренең тылдагы туганнарына һәм дусларына мөрәҗәгать итеп, болай дип язалар: «Немец илбасарларына карата безнең нәфрәтебез чиксез. Без тормышны сөйгәнгә, бәхетле Ватаныбызны сөйгәнгә, гаиләбезне, балаларыбызны, туган Татарстаныбызны сөйгәнгә күрә немец илбасарлары безнең өчен дошман. Без Идел-Кама тугайларын, басу-далаларыбызны, урман-болыннарыбызны, туган Казаныбызны яратабыз. Бөек анабыз — Туган илебез өчен татар егетләре аяусыз һәм куркусыз сугышалар!»

Икенче бер хатта безнең сугышчыларыбыз тылда хезмәт итүче батыр якташларына болай дип мөрәҗәгать итәләр: «Халык бәхете өчен гитлер ерткычларына каршы көрәштә каныбызны да, көчебезне дә, үзебезне дә кызганмаска ант итәбез. Газаплап үтерелгән гаепсез хатын-кызларның, карт-карчыкларның, балаларның күз яшьләре өчен, безнең шәһәр һәм авылларыбызны җимергән өчен, үзләренең барлык явызлыклары өчен, немец оккупантлары тулы җәзасын алырлар».

Татарстан солдатлары Җиңү көнен якынайту өчен үз-үзләрен аямыйча сугышалар, якташлары алдындагы изге антларын намус белән үтиләр.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Бөек Ватан сугышы ничек башланып китә? Фашистлар Германиясенең максаты нинди була?
2. Татарстан хезмәт ияләре, эшчеләр һәм колхозчылар җиңү өчен ниләр эшлиләр?
3. Әти-әниләрдән, әби-бабаларыгыздан сорашып белегез: сезнең авыл кешеләре сугыш вакытында ничек яшәгәннәр, фронтка ничек итеп ярдәм иткәннәр?

56. БЕЗ СУГЫШТА ЮЛБАРЫСТАН КӨЧЛЕБЕЗ...

Г. Тукай.

Канга — кан, үлемгә — үлем! Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Кызыл Армия сугышчылары шундай девиз белән көрәшкә чыгалар. Туган илебезне коллыкка төшүдән саклап калырга! Татарстан җиреннән киткән сугышчылар, бөтен совет халкы белән берлектә, дошман явына каршы калкан булып күтәреләләр. Безнең якташларыбыз сынатмыйлар, һәрчак алгы сафларда булып, батырлыклары белән танылалар. Турыдан-туры сугышларда катнашкан 200 дән артык якташыбызга Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелә. Аларның батырлыгын без беркайчан да онытмаска тиешбез.

...Немец фашистлары иң беренче ударны Белоруссия чигендә урнашкан Брест крепостена юнәлтәләр. Бик күп чик сакчылары һәм аларның командирлары, гарнизондагы хатын-кызлар һәм балалар сугышның беренче минутларында ук һәлак булалар. Исән калганнар да бер адым чигенмиләр, соңгы тамчы каннарына кадәр сугышалар.

Брест крепостен саклаучылар арасында халкыбызның батыр улы, Питрәч егете, полк командиры Петр Михайлович Гаврилов та була. Аның солдатлары крепостьның иң мөһим участокларын саклыйлар. Гарнизонда су һәм азык-төлек запасы бетә. Хатын-кызлар һәм балалар ачлыктан, су юклыктан интегәләр. Сугышчыларның патроннары, гранаталары һәм снарядлары калмый. Әмма дошманга бирелү турында уйлап та карамыйлар.

Бирешмәс крепостьны чолганышта калдырып, фашистлар йөзләрчә чакрым алга үтеп китәләр, тизрәк Мәскәүгә таба омтылалар. Брест өчен көн-төн дәвам иткән сугыш айдан артыкка сузыла. Дошман көненә унар тапкыр һөҗүм итеп карый, бер өзлексез туптан атып торалар, бомбалар яудыралар. Чик сакчылары көрәшне дәвам иттерәләр. Тик аларның саны көннән-көн кими. Ни-

15 ч-279

һаять, соңгы бәрелештән соң Гаврилов үзе генә исән кала. Ачлыктан һәм су булмаудан тәмам хәлсезләнгән батыр егет дошманга каршы үзе генә көрәшә. Сугыш башлануның утыз икенче көнендә генә яраланып һәм хәлсезләнеп аңын югалткан майорны гитлерчылар эсирлеккә төшерәләр. Эсирләр лагеренда батыр йөрәкле, тез чүкмәс совет командирын күрергә дип немец офицерлары махсус киләләр. Петр Гавриловның батырлыгы хәтта дошманнарны да сокланырга мәҗбүр итә! *

Сугышның иң дәһшәтле беренче айларында ук Кара диңгездән алып Төньяк диңгезенә кадәр сузылган бөтен фронтта Татарстан егетләре чын геройлык үрнәкләре күрсәтәләр. Түбән Кама районының Прости авылыннан Никита Кайманов, Казаннан Федор Баталов, Фәрит Фәткуллин беренчеләрдән булып Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар.

Фәрит Фәткуллин сугышка кадәр Казан кондитер фабрикасында эшли, аннан соң очучылар мәктәбен бетерә. Сугыш башлангач, ул истребительләр полкының командиры итеп билгеләнә. Катлаулы шартларда һава сугышларында ул фашистларның берничә самолетын бәреп төшерә. Аның батырлыгы турында газеталарда язып чыгалар, фоторәсемен бастырып, совет сугышчылары арасында листовкалар тараталар. 1941 елның ноябрендә ул Алтын йолдыз медале белән бүләкләнә. 1942 елның июлендә Сталинград өчен барган каты бәрелешнең берсендә дошман истребителен таранлап бәреп төшергәндә батыр егет һәлак була**.

1941 елның 8 августы. Ватаныбыз ут эчендә. Фашистлар туктаусыз алга ыргылалар. Немец халкын, Советлар Союзы бүген булмаса иртәгә бетәчәк, большевиклар җиңеләчәк, дип ышандыралар. Һич көтмәгәндә, шушы алдауларга ышанып яшәгән немецларның күңеленә шом салып, Германиянең башкаласы Берлин күгендә кызыл йолдызлы совет бомбардировщиклары күренә. Алар Берлинны бомбага тоталар. Бу һава һөҗүмендә Ульяновск өлкәсендә туып үскән татар егете очучы-штурман Гали Борһан да катнаша. Нәкъ бер айдан соң, 8 сентябрьдә, Берлинга икенче тапкыр һава һөҗүме оештырыла. Бу юлы хәрби һәм промышленность объектларын бомбага тоталар. Һөҗүмчеләр арасында Әлмәттә туып-үскән хәрби очучы Габделхай Галиуллинның самолеты исән-сау йөреп кайта. Искитәрлек бу вакыйгалар немец фашистлары-

---

* Сугыштан соң Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов Питрәч районының Әлбәдән (Альвидино) авылында гади колхозчы булып эшли. 1979 елда Краснодар шәһәрендә вафат була. Аның гәүдәсен Брест крепостена илтеп күмәләр.

** Хәзер Казанның Идел буе районындагы бер урам Советлар Союзы Герое Ф. Фәткуллин исемен йөртә.

Алга!

ның уйдырмаларына ышанмау тудыралар, совет халкының күңелен киләчәк җиңүләргә өметләндерәләр.

1941 елның көзендә гитлерчылар Мәскәүгә зур һөҗүм әзерлиләр. Моңарчы бер җиңелү ачы сын татымаган дошманның бик кәпәренгән көннәре була бу. Октябрь — ноябрь айларында Мәскәү тирәсендә рәхимсез каты сугышлар башлана.

Күп көч белән Мәскәүгә омтылган генерал Гудериан танклары белән бәрелештә Казандагы 81 нче мәктәпнең элекке укучысы Виктор Григорьев үзен куркусыз сугышчы итеп таныта. Дошманга каршы ут ачып, ул бер-бер артлы ике танкны чәлпәрәмә китерә. Аның үзенең танкына төрле яклап снарядлар ява. Батыр егет яралана, ә танкның тубы хәрәкәтсез кала. «Таранга барам!» — дип әйтә ул командирга һәм машинасының тизлеген арттыра. Берничә дошман танкын бәрдереп юлдан чыгара, авыл читеннән атып тор-

Немец фельдмаршалы Паулюс әсирлектә.

ган туплар өстенә ташланып, аларны да сытып үтә, авыл уртасында очраган автоколоннаның унике машинасын изеп-җимерә. Кызыл армиянең контрһөҗүме уңышлы тәгәлләнә. Күрсәткән батырлыгы өчен, Виктор Григорьевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Гитлерчылар Мәскәүдән алып ташлана. 1942 елның көзендә дошманның иң зур көчләре Сталинградка юнәлтелә. Илебез язмышы хәл ителгән бу сугышларда да Татарстан егетләре катнаша.

Шәһәрне саклау мәшһүр генерал В. И. Чуйков командалыгындагы армиягә йөкләнә. Сталинградның һәр урамы, һәр йорты өчен каты көрәш бара. Өч ай буе шәһәрдә бомбалар ява, снарядлар, миналар шартлый, пулеметлар, автоматлар атып тора. Шәһәр өстендә янгын шәүләләре уйный, кара төтен ургыла. Кайбер көннәрдә безнең сугышчылар дошманның 20—25 әр атакасын кире кайтаралар. Фашистлар трактор заводына килеп җитәләр. Әмма заводта эш тукталмый, ремонттан чыккан танклар турыдан-туры сугышка кереп китәләр.

Менә стенасы дошман пулялары белән тишкәләнеп беткән атаклы «Павлов йорты». Аның турында ишетмәгән кеше бармы икән? Шәһәрнең 9 январь мәйданында урнашкан бу йортны сержант Яков Павлов сугышчылары ике ай буе диярлек дошманнан саклыйлар. Павловчылар арасында безнең якташларыбыз Ф. Рамазанов белән Н. Шкуратов та була. Аларга элеккеге Казан эшчесе А. Чехов һәм Лаеш районы колхозчысы Г. Волков ярдәмгә киләләр. Сталинград өчен барган сугышларда А. Чехов 265, ә Г. Волков 163 фашистны теге дөньяга озата.

Атаклы якташыбыз полковник (соңыннан генерал-лейтенант) Гани Сафиуллин дивизиясе Сталинградны азат итүдә актив катнаша. Бу дивизия дошманның йөзләгән танкын, меңләгән автомашинасын, артиллериясен юк итә. Гани Сафиуллин солдатлары сугыш



Курск янындагы сугыш.

барышында, иң беренчеләрдән булып, немецларның ике генералын әсир итәләр. Әсирлеккә алынган солдат һәм офицерларның саны 18 меңгә җитә. Дошманның 68 танкын, 22 самолетын, 3 бронепоездын, 400 ләп туп һәм минометларын, 700 ләп автомашинасын кулга төшерәләр.

Сталинград сугышы 1943 елның февралендә җиңү белән тәмамлана. Фашистларның камалышта калган гаять зур армиясе тәмам тар-мар ителә.

1943 елның җәендә немецлар Сталинград өчен үч алмакчы булалар. Алар, Орел һәм Белгород шәһәренә һөҗүм ясап, Курск районында 900 меңләп солдат, 3 меңгә якын танк, 10 мең орудие, 2 меңнән артык самолет туплыйлар. Шунда һич кайчан күрелмәгән конкойгыч бәрелешләр башланып китә. Прохоровка авылы янында булган иң зур сугышта һәр яктан 1200 ләп танк катнаша. Сугыш кыры коточкыч күренешне хәтерләтә. Бронетанк гаскәрләре маршалы П. А. Ротмистров соңыннан болай дип яза: «Мин күп кенә сугышларда катнаштым, әмма мондый хәлне күргәнем булмады. Танк белән танк капма-каршы килеп бәрелешә. Алар өстен-

нән утлы эз калдырып снарядлар оча. Корычка корыч бәрелгән авазлар чыңлап тора, моторлар үкерә. Барысы да куе төтен һәм тузан эчендә калган. Кайда нәрсә булганын һич абайлар хәл юк. Бик хәтәр танк һөҗүме булды бу. Безнең танклар сугыша-сугыша сигез чакрым эчкә үттеләр. Көн азагына яу кыры безнең кулда калды. Бу инде безнең җиңү иде».

Курск дугасында барган сугышларда Татарстан халкының шәхси акчаларына төзелгән 200 ләп танк һәм 100 дән артык Пе-2 самолетлары катнаша. Батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган якташларыбыз Зәки Шәймәрдәнов (Балык Бистәсе районыннан), Михаил Фомин (Бондюгтан, хәзерге Менделеев шәһәре), Хәмзә Мөхәммәдиев, Замир Хәсәнов һәм башкалар җиңүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

1943 елның икенче яртысында Бөек Ватан сугышында тамырдан борылыш туа: көчләр чагыштырмасы Советлар Союзы файдасына үзгәрә, Кызыл Армия бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчә. Илебезнең шактый өлеше дошманнардан азат ителә. 1944 елның кышында Ленинград, Волхов һәм Балтик буе фронтлары һөҗүм башлый. Безнең солдатларыбыз бу көннәрдә дә каһарманнарча сугышалар.

Бөгелмә районы егете Газинур Гафиятуллин Псков өлкәсенең Овсищево авылы өчен барган сугышларда тиңдәшсез батырлык күрсәтә. Ул, беренчеләрдән булып, дошманның танкка каршы торучы батареясына гранаталар ташлый, андагы фашистларны юк итә, берсен әсирлеккә ала. Шуннан соң безнең сугышчылар атакага күтәреләләр. Ләкин якындагы дзоттан өзлексез пулемет атып тора, баш күтәрергә дә ирек бирми. Бер кулына автоматын, икенчесенә гранат тоткан сержант Гафиятуллин дзотка таба шуыша, бераз якынайгач, аңа төбәп гранатасын ыргыта, аннан сикереп торып, үз гәүдәсе белән дзот амбразурасын каплый. Пулемет тынып кала. Шушы мәлдән файдаланып, сугышчылар яңадан атакага күтәреләләр. Дошман җиңелә.

Бер ел элегрәк, 1943 елның кышында, нәкъ шушындый ук батырлыкны Александр Матросов күрсәткән була. Аны озак вакытлар буе рус милләтеннән булган дип киләләр. Чынлыкта исә аның чын исеме — Шакир Мөхәммәтҗанов, Башкортстанда туып, балалар йортында тәрбияләнеп үскән татар егете булып чыкты.

Дошман дзотын күкрәкләре белән каплап, Александр Матросов батырлыгын кабатлаган якташларыбызның саны егермегә якын. Алар арасында Барый Шәвәлиев, Хафиз Зарипов, Нух Идрисов, Габдулла Сәлимов, Миңгали Гобәйдуллин, Мансур Вәлиуллин, Әхмәт Мөхәммәтов, Сәләхетдин Вә-

лиуллин һәм башкаларның исемнәре бар.

Советлар Союзы Маршалы Р. Я. Малиновский, халкыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларын искә төшереп, болай дип яза: «Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем. Һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә, корычтай ихтыярлы булуларына һәрвакыт сокланам. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барылган бөек көрәштә татар халкы үзенең чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды».

Сораулар һәм биремнәр:

1. Бөек Ватан сугышында катнашкан татарлар арасында ничә Советлар Союзы Герое бар?
2. «Без сугышта юлбарыстан көчлебез...» дигән хикәяне укып, сез үзегезгә моңа тикле билгеле булмаган нинди геройлар турында белдегез? Аларның батырлыклары турында сөйләгез.
3. Сезнең шәһәрдән, районнан яки авылыгыздан киткән сугышчылар арасында нинди геройлар бар? Өлкәннәрдән сорашып, алар турында күбрәк белергә тырышыгыз.

57. ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘР

Татар халкының күренекле шагыйре, җәмәгать эшлеклесе Муса Җәлил 1942 елда Волхов фронтында вакытта нык яраланып, аңын югалтып фашистлар тылында кала. Аңына килеп күзен ачканда, аны инде фашистлар уратып алган була.

Муса Җәлил, хурлыклы әсирлеккә эләккәнче үлгәнең артык дип, пистолетына тотына. Әмма һәрчак тугры булган, үзенә төзәлгән пистолет бу юлы «хыянәт итә» — атмый.

Муса Җәлил килеп эләккән фашистлар концлагерында хәлләр коточкыч була. Качу турында уйлап та карарга мөмкин булмый. Берничә кат әйләндереп алган стеналар өстеннән электр тогы җибәрелгән чәнечкеле кат-кат тимер чыбыклар үтә. Һәр почмакта, чатта бар нәрсә дә уч төбендәгедәй күренерлек вышкалар, аларда коралл сакчылар. Этләр белән фашистлар йөреп тора. Аз гына ялгыш атласаң да үлем көтә, котырынып этләр ташлана. Монда ачлыктан, салкыннан, чирдән көн саен йөзләгән кешеләр үлә. Фашистлар әсирләрне, куркытып тору өчен, җәзалыйлар, кыйныйлар, мәсхәрәлиләр. Аларда җиңүгә ышанычны, туган илләренә мәхәббәтне бетерергә телиләр.

Муса Җәлил, җай чыккан саен,

Муса Җәлил.

яшеренеп татар әсирләре алдында үзенең җиңүгә ышаныч, туган илгә мәхәббәт тулы шигырьләрен укый, көрәшкә чакыра. Әсирләрнең күзләре очкынлана, фашистларга каршы нәфрәт белән йодрыклары йомарлана.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре тирәсенә фашистларга каршы көрәшү өчен яшерен оешма туплана. Аңа бик сыналган, ышанычлы кешеләрне генә алалар. Очраклы бер генә кеше эләксә дә бөтен эшне харап итәргә, күпме кешене үлемгә дучар итәргә мөмкин бит. Яшерен оешмага кергән һәр кеше ант итә. «Яшерен оешмага керү белән, мин явыз дошманга каршы соңгы сулышыма кадәр сугышырга, Ватаныма һәрьяклап булышырга ант итәм. Кирәк икән, Туган илем иминлеге өчен тормышымны да кызганмаска сүз бирәм. Дошман кулына эләгә калсам, нинди генә җәза-җәберләргә дучар ителсәм дә, яшерен оешма турында, дусларым турында бер сүз дә әйтмәскә ант итәм. Әгәр мин шушы тантаналы антымны бозсам, мине Туган илемнең дошманы, фашистлар ялчысы дип исәпләгез».

Фашистлар бик мәкерле, явыз план коралар. Җәзалап һәм ач тотып, әсирләрне Ватанга хыянәт итәргә һәм үз илләренә каршы сугышырга мәҗбүр итмәкче булалар. Алар, моның өчен төрле милләттәге әсирләрне аерым-аерым җыйнап, милли легионнар төзи башлыйлар. Шул милләт халыклары телләрендә газеталар чыгарырга керешәләр, радиотапшырулар оештыралар, милли комитетлар төзиләр. Бу эшләргә әсирләрнең үзләрен тарталар. Татар-башкортларга ирекле «Идел-Урал» дәүләте төзибез дип вәгъдә итәләр.

Яшерен оешма кешеләре газета редакциясенә, радио студиясенә һәм башка күп кенә оешмаларга кереп урнашалар. Бу юнәлештә бигрәк тә балалар язучысы Абдулла Алиш зур эш алып бара. Яшерен оешманың төп бурычы: кораллы восстание әзерләү, күрше поляк һәм әрмән легионнары белән элемтә урнаштыру, бергәләп

хәрәкәт итү турында сөйләшеп кую, корал табу, әсирләр арасында пропаганда алып бару. Боларның барысын да бик уяу, фашистларга һәм сатлык җаннарга сиздермичә эшләргә кирәк. Якын тирәдәге завод-фабрикаларда Германиягә кол итеп куып китерелгән совет кешеләре дә күп була. Яшерен оешмадагылар алар белән дә эш алып баралар. Типографиядә, машинкада, җай табып, листовкалар басып бик саклык белән тараталар. «Кызылармеец иптәшләр! Үз этиләрегезгә, әниләрегезгә, энеләрегезгә һәм сеңелләрегезгә каршы барыр өчен, фашистлар сезне ач үлем белән куркытып алдап, легионга язылырга мәҗбүр иттеләр. Кулыгызга бирелгән шул коралны чын дошманнарыгызга — фашистларга каршы борыгыз!» — диелә анда. Аңлату эшләрен легионда оештырылган музыка-хор капелласы аша да алып баралар. Аның җитәкчесе, яшерен оешманың җитәкчеләреннән берсе Гайнан Кормаш була. Концертка әсирләр күңелендә илне ярату, үз халкыбыз, мәдәниятебез белән горурлану хисе, әсирләрне кимсеткән, алардан көлгән фашистларга карата нәфрәт уятырлык җырлар, шигырьләр сайлап алына. 1914 елдагы кебек спектакльләр дә куялар. Әмма бу юлы театр үлем белән янәшәдә уйнала.

1943 ел уртасында легионның беренче батальоны Белоруссиягә партизаннарга каршы җибәрелә. Барып җиткәч, батальон солдатлары баш күтәрә, немец офицерларын юк итеп, бөтен кораллары, кирәк-яраклары белән партизаннар ягына чыга. Аннары, партизаннар белән бергә, фашистларның зур көчләрен тар-мар итәләр. Шушы уңыштан канатланган җәлилчеләр хәрби әсирләр арасында гомуми восстание күтәрүгә һәм легиончыларның аерым группаларын качарга әзерли башлыйлар. Ә дошман беренче батальон белән булган хәлдән соң сакны бик каты көчәйтә, әсирләр арасына сатлык җаннар җибәрә. Шундыйлардан үзенең җаны турында гына уйлаган, илен, халкын саткан Мәхмүт Җамалетдинов мәкерле юллар белән җәлилчеләрнең ышанычына кереп, аларны фашистларга сата. Муса Җәлил һәм аның 10 көрәштәше кулга алынып, төрмәгә ябыла.

Ифрат авыр җәзалаулар, сорау алулар башлана. Җәлилчеләр ахыргача нык торалар. Бар эшләгән эшне үз өсләренә алып, башка беркемнең дә исемен атамыйлар. Яшерен оешманың бик күп кешеләрен үлемнән коткарып калалар.

Төп батырлык эшләнгән була инде. Фашистлар легиондагы башка батальоннарны да туган илләренә каршы сугыштыра алмыйлар. Алар я безнең гаскәрләр ягына чыгалар, я фашистлар, аларның бу эшләрен сизеп, тизрәк ки-

М. Җәлил һәйкәле.

ре Германиягә җибәрергә мәҗбүр булалар.

Җәлилчеләр үлем сәгатен озак көтәләр. Фашистлар аларны озак интектерүле үлем белән генә түгел, рухларын сындырып үтерергә теләли. Әмма коточкыч газаплар үтеп, һичшиксез үләчәкләрен белсәләр дә, җәлилчеләр көчле рухлылар булып калалар. Муса Җәлил туган илгә, көрәшкә багышланган бик күп иң әйбәт шигырьләрен үлем сәгатен көткәндә яза. Аның «Моабит дәфтәре» дигән шигырьләре ничә еллар, ничә куллар аша үтеп туган иленә кайтты. Тоткынлыкта язган бу шигырьләре өчен аңа 1957 елны Ленин премиясе, ә үзенә Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Муса Җәлилнең көрәштәшләре дә берсеннән-берсе батыр, туган илләрен берсеннән-берсе ныграк яратучы, фашистларны берсеннән-берсе ныграк күрәлмаучы кешеләр иде.

Фашистлар суды җәлилчеләрне үлемгә хөкем итә. Аларны 1944 елның 25 августында төш вакытында гильотинада җәзалап үтерәләр.

Әмма алар үлгәндә дә антларына тугры калдылар. Аларның үлеменә шаһит булган немец рухание соңыннан: «Татарлар горур үлделәр»,— дип сөйләде.

Данлы Казанның чал Кремле янында Муса Җәлил һәйкәле тора. Ул югарыга очар өчен канатларын җәйлап куйган бөркетне хәтерләтә. Ике кулы артка каерып бәйләнгән... Җилкәләрен киереп, менә-менә чылбырларын өзәр дә һавага күтәрелеп китәр кебек.

Илгә, халыкка үлемсез җыр кайтты:

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып,
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңгырар җыр булып.

Җәлилчеләрнең батырлыкларын беркайчан да онытма, яшь дустым. Аларның батырлыгын, халкың, илеңнең якты киләчәге өчен көрәшне син дәвам ит.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Фашистлар тоткынлыгында җәлилчеләр ничек көрәшәләр?
2. Сугышта һәлак булган тагын кайсы татар язучыларының, шагыйрьләренең, композиторларының, рәссамнарының исемнәрен беләсез?
3. М. Җәлилгә багышланган нинди әсәрләр укыганыгыз бар?

58. АЛГА, БЕРЛИНГА! ҖИҢҮ БАЙРАГЫН КЕМ ЭЛГӘН?

1944 елның көзендә Туган илебез фашист илбасарларыннан тулысынча азат ителә. СССРның дәүләт чикләре яңадан торгызыла.

Совет Армиясе Польшаны, Чехословакияне, Венгрияне, Болгарияне, Югославияне һәм Көнбатыш Европаның башка дәүләтләрен фашистлар коллыгыннан коткару өчен көрәш башлый. Безнең сугышчыларның ярдәме булмаса, Европа халыкларының үзләренә генә немецларга каршы сугышу гаять авырга туры килер иде. Алар безнең ярдәмгә мохтаҗ булалар. Югославиянең Милослав Отович исемле бер партизаны болай дип белдерә: «Без, дымсыз яргаланып беткән җир яңгыр өмет иткән кебек, күптән аерылышкан туганнарыбызны сагынып көткәндәй, Кызыл Армияне түземсезләнеп көтеп алдык. Менә алар, меңләгән һәм меңләгән чакрым юл үтеп талчыккан, яраларыннан кан саркып торган совет кешеләре, безгә дошманны җиңәргә һәм ирек яулашырга булышу өчен килделәр».

Каһәр төшкән сугышның соңгы айлары бара. Фашистларның көннәре санаулы. Бер-бер артлы Будапешт, Белград, Варшава шәһәрләре азат ителә. Кенигсберг һәм Прагага һөҗүм башлана. Татарстан егетләре тагын алгы сафта. Чүпрәле районыннан Зариф Алимов, Чистай районыннан Касыйм Ситдыйков, Югары Осланнан Алексей Исаев, Саба районыннан Зәки Хәбибуллин, Мамадыштан Иван Максимов, Зеленодолдан Николай Катин, Казаннан Виктор Саженов... Санап бетерерлек тә түгел безнең чын геройларны! Халкыбызның каһарман уллары һәм кызлары, Ватаныбыздан бик еракта булсалар да, элеккечә үк үз-үзләрен аямыйча сугышалар, кан түгәләр, күп корбаннар бирәләр.

Советлар Союзы Герое мәшһүр очучы Мәгубә Сыртланованың исемен сугышчылар бу көннәрдә еш искә алалар. Ул төнге бомбардировщиклар полкында эскадрилья командиры ярдәмчесе булып хезмәт итә. Төньяк Кавказда, Кырымда, Белоруссия һәм Польша җирләрендә гитлерчыларга каршы кыю сугыша. Мәгубә Сыртланова По-2 самолетында барлыгы 782 мәртәбә сугышчан очыш ясый, дошман өс-

М. Сыртланова.

тенә 140 тонналап бомба ташлый. Нинди генә сугышларда катнашырга туры килми аңа!

1945 елның 5 май төнендә булган соңгы сугыш кыю очучының хәтерендә нык уелып кала.

...Фашистлар совет гаскәрләреннән диңгез аша качып котылмакчы булалар. Безнекеләр, аларны эзәрлекләп, болытлар эченнән приборларга карап кына очалар. Максатка якынлашкач, түбән төшә башлыйлар. Биеклек —300 метр. Шул вакыт аларны дошман прожекторы «тотып» ала. Аларга зенит тупларыннан, автоматлардан атарга тотыналар. Һава дулкыны самолетны әле бер, әле икенче якка ташлый, якыннан гына снарядлар сызгырып үтә. Дошман катерлары өстенә бомбалар ява. Астан фонтан булып тетен катыш су баганасы күтәрелә. Мәгубә Сыртланова үзенең самолетын прожектор яктысыннан чыгару өчен кинәт диңгез өстенә «ташлый». Менә-менә суга чумам дигәндә генә, самолет тизлеген арттыра төшеп, югары күтәрелә һәм, фашистлар тырнагыннан ычкынып, болытлар арасына кереп югала. Аэродромга кайтып җиткәч, бөтенесе шакката — самолет дошман пулялары белән тишкәләнеп беткән була.

«Алга, Берлинга!» — Ян-якларына акбур, буяу белән шундый чакыру язылган танклар, самолетлар, автомашиналар зур тизлек белән фашистлар Германиясенең башкаласына юнәләләр. Советлар Союзына кушылып, Америка, Англия һәм Франция гаскәрләре дә хәрәкәт итә. Соңгы штурмга! Сугышчыларның күңелләре күтәренке. Алар алга ыргылалар.

Гитлер һәм аның иярченнәре соңгы көчләрен Берлинны ныгытуга туплыйлар. Шәһәрнең һәр урамын, һәр йортын оборона өчен файдаланалар. Таш биналарның түбәләренә пулеметлар урнаштырылган, йөзәрләгән снайперлар мылтыкларын тәрәзәләрдән урамга төбәгәннәр. Урам чатларына җиргә казып танклар, туплар утыртылган, бронялы капкачлары гына калкып тора. Шәһәр тирәсендә рәт-рәт окоп-траншеялар, урамнарда баррикадалар,



1945 елның мае. Берлин.

тимер-бетон коймалар. Бөтен җир миналанган — бер талпынуда гына үтеп китәрмен димә. Метро станцияләрен дә көчле итеп ныгытырга өлгергәннәр. Урамнарда тагын биеклеге 20 метрга җитәрлек алтышар катлы тимер-бетон бункерлар төзеп куелган. Аларның саны 400 гә җитә. Бу корылмаларның түбәләренә туплар, һәр каттагы махсус балконнарга дистәләгән пулеметлар тезелгән.

1945 елның 16 апрель таңында меңләгән туплар телгә киләләр, бомбардировщиклар һәм истребительләр ташкыны дошманның Берлин тирәсендәге ныгытмаларына ябырыла. Туплар аз гына тынып торган арада дошман өстенә танклар һәм җәяүле сугышчылар ташлана. Яу кырын көчле 140 прожектор яктыртып тора. Мондый ук хәлне көтмәгән гитлерчылар бөтенләй каушап калалар. Шулай да алар һәр карыш җир өчен аяусыз көрәш алып баралар. Тик озак каршылык күрсәтә алмыйлар, барыбер чигенәләр.

Совет сугышчылары Берлинны һәр яктан камап алалар һәм штурм башлыйлар. Җиде көн буе шәһәрдә көчле сугышлар бара. Шәһәр өстенә ике мең бомбардировщик ябырыла, алар тимер-бетоннан ко-

Җиңү!

рылган бункерларны, көчле ныгытмаларга әверелдерелгән биналарны бомбага тоталар. Очучылар арасында гестапо йортын дөмбәсләгән Казан егете Алексей Федоров, Советлар Союзы Герое Тамерлан Ишмөхәммәтов, әле 1941 елда ук Берлинны бомбага тоткан полковник Гали Борһан һәм башкалар дан казана.

Безнең гаскәрләр шәһәрнең үзәгенә — рейхстагка ыргылалар. Һәр урам, һәр квартал өчен канкойгыч сугышлар бара. Көннәрнең берендә Балтач егете сержант Габдулла Гарифуллинга полк һөҗүм иткән юнәлештәге бер биек башняны яулап алып, аңа полк байрагын беркетүне йөкләләр. Бу бурычны ул намус белән үтәп чыга. Башня түбәсендә Кызыл байрак җилферди башлый. Немецлар, котырынып, байракка пулеметлардан атарга тотыналар. Ул бер кырыйга янтаеп төшә. Шулчак Габдулла Гарифуллин яңадан башняга менә һәм пулялар «яңгыры» астында байракны тагын да югарырак беркетеп куя. Полк сугышчылары «Ур-ра!» кычкырып, дәртләнеп, дошман өстенә ташланалар. Бу һөҗүм вакытында безнең якташыбыз бик күп дошман объектын сафтан чыгара, 9 пулемет ноктасын, 90 лап автоматчыны юк итә. Шушы батырлыклары өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Совет сугышчылары 30 апрель иртәсендә шәһәр үзәгенә якынлашалар. Бөтен җирдә янгын котыра. Снарядлар һәм бомбалар ярыла. Алга бару гаять авырлаша. Немецлар төрле яклап, йорт подвалларыннан, чардак-түбәләрдән берөзлексез атып, кургаш «яңгыры» яудырып торалар.

Безнең гаскәрләрнең төп максаты — империя канцеляриясе урнашкан җир асты бункерын яулап алу. Анда Гитлерның ставкасы, армиянең штабы урнашкан. Аның янәшәсендә генә рейхстаг — фашистлар Германиясе парламентының бинасы.

Совет гаскәрләре соңгы, хәлиткеч сугышка әзер. Һавага кызыл ракета күтәрелә. Рейхстагны штурм-

Өйгә, җиңү белән!

лау башлана. Атака көне-төне дәвам итә. Фашизмны тез чүктерү билгесе булачак Җиңү байрагын беренче булып рейхстаг гөмбәзенә кем эләр? Гаскәрләр соңгы көчләрен куеп сугышалар. Башкортстанда туып үскән татар егете Гази Заһитов һәм аның иптәшләре, беренчеләрдән булып, алга ыргылалар. Хәзерге көнгә кадәр сакланып калган архив документларында болай язылган: «30 апрельдә рейхстагны штурмлаганда Заһитов рейхстагка беренче булып бәреп керде. Әмма шул чакта күкрәгенә үтәли яраланды, яралану вакытында партия билеты төшелде. Шуңа да карамастан, өлкән сержант Заһитов һәм сержант Минин рейхстаг бинасына менделәр, анда беренче Җиңү байрагын урнаштырдылар.

Рейхстагны штурмлаганда күрсәткән батырлыгы, кыюлыгы һәм каһарманлыгы өчен Г. К. Заһитов Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек». Бу документка алты хәрби начальник, шул исәптән дүрт генерал кул куйган.

Моңа тикле Җиңү байрагын беренчеләрдән булып грузин егете М. Кантария белән рус егете М. Егоров элгән дип исәплиләр иде. Чынлыкта исә татар сугышчысы булган. Горурланмый мөмкин түгел шундый батырларыбыз белән!

1945 елның 2 маенда Берлин алына. Берничә көннән дошман тәмам тар-мар ителә һәм бирелергә мәҗбүр була. Бөек Ватан сугышы тәмамлана. 1945 елның 9 маенда халкыбыз тантаналы төстә Җиңү көнен бәйрәм итә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Безнең Армия сугышчылары кайсы илләрне азат итүдә катнаша?
2. Сугышның соңгы айларында батырлыклар күрсәткән нинди геройларны беләсез?
3. Берлинны штурмлау турында сөйләгез. Кем ул Гази Заһитов?

ҖИДЕНЧЕ
БҮЛЕК

ТАТАРСТАН СУГЫШТАН СОҢ ҺӘМ ХӘЗЕР

16 Ч-279

59. ЯҢАДАН ТЫНЫЧ ХЕЗМӘТКӘ!

Бөек Ватан сугышы Советлар Союзы халкына әйтеп бетергесез күп кайгы-хәсрәт китерә. Сугыш кырында миллионнарча солдатларыбыз ятып кала. Ачтан үлүчеләрнең, фашист концлагерьларында һәлак булучыларның санын һаман да әле төгәл әйтеп бирә алучы юк. Элегрәк 1941—1945 еллардагы сугышта 20 миллион кеше үлгән дип язалар иде. Хәзер бу санны 40, хәтта 60 миллионга кадәр җиткерәләр. Татарстаннан сугышта 560 меңләп кеше катнашкан. Корбан булучы якташларыбыз 200 меңгә якын. Нинди фаҗига! Дәһшәтле сугыш шаукымы кагылмаган берәр гаилә бармы икән бездә?

Сугыш булып үткән җирләрдә барысы 1710 шәһәр, 70 меңләп авыл җимерелгән һәм яндырылган, меңләгән промышленность предприятиеләре эштән чыгарылган. Дөньяның бер генә иле дә мондый югалтуларга тап булмаган.

Әмма ләкин, ничек кенә булмасын, сугыш бөек Җиңү белән тәмамлана. Советлар Союзы халыкларының тарихында яңа чор — сугыш җәрәхәтләрен төзәтү, шәһәр-авылларыбызны, җимерек хуҗалыгыбызны яңадан торгызу чоры башлана. Завод-фабрикаларда һәм авылларда техника, эшче көчләр җитми. Кешеләрне промышленность товарлары, азык-төлек белән тәэмин итү кыенлаша. Сугыштан соңгы беренче елларда икмәк, ит, май, шикәр, тукымалар, аяк киемнәре һәм башка төрле әйберләрне кибетләрдән махсус карточкалар белән генә сатып алып була.

Тыныч хезмәткә сусаган халык бердәм булып илне аякка бастыру эшенә керешә. Зур кыенлыклар белән булса да, тормыш акрынлап үз җаена кайта. 1946 елда халык хуҗалыгын үстерүнең яңа бишьеллык планы кабул ителә. Кичәге фронтовиклар яңадан станоклар артына басалар, колхоз кырларында, терлекчелек фермаларында рухланып эшли башлыйлар. Бөтен җирдә хезмәт дәрте кайный.

Казан заводларының күбесе, сугыш кораллары ясаудан туктап, тыныч продукция эшләп чыгаруга керешә. Яңа завод корпуслары үсеп чыга, иске җиһазлар яңаларына алмаштырыла. Электр энергиясе

җитештерү арта. Предприятиеләрдә социалистик хезмәт ярышы оештырыла.

Нәтиҗәдә бишьеллык планны Татарстан срогыннан алда — 4 ел да 3 айда — үтәп чыга. Промышленностьның тулаем продукция эшләп чыгаруы, сугышка кадәр чор белән чагыштырганда, 3 тапкырдан күбрәккә арта. Бу инде зур хезмәт җиңүе була.

Ләкин авыл хуҗалыгын торгызу бик акрын темплар белән бара. 1946 елгы корылык игенчелеккә һәм терлекчелеккә көтелмәгән зур зыян китерә. Колхозларда тракторлар гына түгел, хәтта атлар да җитми. Шуңа күрә чәчү җирләренең мәйданы сугышка кадәрге дәрәҗәдән азая. Бишьеллыкта бөртекле ашлыкның һәр гектарыннан уртача 5,3 центнер гына уңыш алына (чагыштырып карагыз: хәзерге көндә ул 20—25 центнер тәшкил итә). Терлекчелектә дә уңышлар шәптән булмый — һәр сыердан елына 800—900 литр сөт савып алына (хәзерге көндә ул — уртача 3000 литр чамасы).

Совет хөкүмәте авылга төрлечә ярдәм итеп карый: колхозларны эреләндерәләр, булдыра алганча аларга техника, запас частьлар, минерал ашлама бирәләр. Моның нәтиҗәсе була, әлбәттә. Ләкин колхозлардан җитештерелгәнгә караганда күбрәк таләп итәләр, тир түгеп үстерелгән ашлыкны юк кына бәягә сатып алалар. Колхозчыларның эш хакы бик түбән. Шунлыктан колхоз хуҗалыгын үстерү өчен кызыксыну һич тә җитәрлек түгел. Алай да авыл сугыш җәрәхәтләреннән арына бара.

1950 нче елларда ил тормышы сизелерлек дәрәҗәдә яхшыга үзгәрә башлый. 1953 елда Сталинның үлеме тормыш барышына шактый үзгәреш кертә. Шәхес культы елларында нахак яла ягып төрмәләргә ябылган, сөргенгә сөрелгән миллионнарча кешеләрнең исән калганнары өйләренә кайталар. Промышленность һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа күтәрелеш булып ала. Казанда «Теплоконтроль» һәм компрессорлар заводы сафка баса. «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында, мех һәм җитен комбинатларында яңа җиһазлар куела. Чистай сәгать заводы куәтен елдан-ел арттыра. 1957 елда бездә җитештерелгән югары сыйфатлы промышленность әйберләре дөньяның 35 иленә чыгарыла. Брюссельдә (Бельгия) үткәрелгән Бөтендөнья күргәзмәсендә Чистайның «Восток» сәгате, «Теплоконтроль» заводында һәм мехкомбинатта эшләнгән әйберләр зур кызыксыну тудыралар.

Татарстанның халык хуҗалыгы кыска гына вакыт эчендә яңадан үзенең сугышка кадәрге дәрәҗәсенә ирешә һәм алга таба үсешен кызу адымнар белән дәвам иттерә. Тик шунысын да әйтеп китмичә ярамый: промышленностьта төп игътибарны халык куллану товарларын җитештерүгә түгел, ә төрле

станоклар, приборлар ясауга, оборона предприятиеләренең тизләтелгән үсешенә юнәлтәләр. Социализмның «Барысы да халык бәхете өчен!» дигән матур девизы тормышка ашмый.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Безнең илебезгә һәм республикабызга сугыш нинди югалтулар алып килә?
2. Сугыштан соң халык хуҗалыгын торгызу ничек бара?
3. Ни өчен авыл хуҗалыгының үсеше көткән нәтиҗәләрне бирми?
4. Хөкүмәтнең халык куллану товарларын җитештерүгә аз игътибар бирүен ни белән аңлатырга мөмкин?

60. ТАТАРСТАН — «КАРА АЛТЫН» ИЛЕ

Безнең республикабызда табигый байлыклар бик күп. Алар арасында иң кыйммәтлесе — нефть. «Кара алтын» дип йөртәләр аны. Нефть турында кайбер нәрсәләрне безнең болгар бабаларыбыз да белгән. Җир астыннан саркып чыккан куе кара майны сугыш вакытында кулланганнар (яндыргыч снарядлар ясаганнар), ягу өчен файдаланганнар. 19 нчы гасыр урталарында хәзерге Кама Тамагы районының Сөкәй авылы янында табылган нефть ятмаларын эшкәртү өчен заводлар да төзелә. Тик алар бөтен көченә эшләп китә алмыйлар, чөнки куәтле нефть ятмаларын эзләү бик акрын бара.

Совет власте елларында Татарстан җирендә нефть промышленностен булдыру өчен күп эшләр эшләнә. Академик И. М. Губкин җитәкчелегендәге геологлар, махсус тикшеренүләр үткәргәннән соң, Идел белән Урал арасында бик зур нефть ятмалары булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә киләләр. Казан университеты профессоры Е. И. Тихвинская 1934 елда ук инде шундый нефть ятмаларының иң куәтлесе Ромашкино авылы янында тупланган булуын дәлилли.

Сугыш алды еллары. Илебезнең төрле почмакларында яңадан-яңа промышленность предприятиеләре калкып чыга. Бөтен җирдә ягулык кирәк. Бөек Ватан сугышы башлангач бигрәк тә. Немец фашистлары Бакуны басып алсалар, ил нефтьсез калачак. Идел белән Урал арасында «Икенче Баку»ны тизрәк булдырырга кирәк!

Киеренке көннәр башлана. Бервакыт бораулаучылар тирән катламнан чыккан нидидер ят токымга тап булалар. Җентекләбрәк карыйлар: кара майга буялган кебек. Нефть түгелме соң бу? Суга салып тикшерәләр — су өсте зәңгәрле-шәмәхәле өре белән каплана. Арадан берәү шатланып кычкырып җибәрә:

Нефть чыккан якларда.

— Керосин исе килә бит! Нефть!

Тик иртәрәк шатланганнар икән. Татарстанда бораулангaн беренче тирән скважина буш булып чыга. Әмма ләкин кайдадыр шушы тирәдә генә һичшиксез нефть ятмасы табылачагына беркем дә шикләнми инде.

Ниһаять, күпме көтелгән вакыйга: 1943 елның 2 августында Шөгер авылы янында Гариф Хәмидуллин җитәкчелегендәге бригада бораулаган скважинадан нефть фонтаны күтәрелә! Шул ук елны бу скважина тәүлегенә 40 тонналап нефть бирә.

Бораулау эшләре республикабызның башка районнарында да нык җәелеп китә. 1946 елда Баулы нефте ачыла. 1948 елда атаклы Ромашкино нефте ташкын булып ургылып ага башлый. Татарстан тиз арада «Икенче Баку»ның үзәгенә әверелә.

Республикабыз икътисадында өр-яңа тармак — нефть промышленносте барлыкка килә. 1950 елда «Татнефть» берләшмәсе төзелә. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Баулы районнарының басулары нефть вышкалары белән тула. 1956 елда Татарстан нефть чыгару буенча (18 миллион тонна!) Советлар Союзында беренче урынга чыга. 1960 елда нефть чыгаруның күләме 46 миллион тоннага, 1970 елда исә 100 миллион тоннага җитә.

Республикабызның нефть районнары берничә дистә ел эчендә бөтенләй үзгәрә, яңа шәһәрләр, эшчеләр поселоклары барлыкка килә. Миңлебай газ эшкәртү заводы, Казан органик синтез заводы, Түбән Кама химия комбинаты, Зәй һәм Урыссу ГРЭСлары да үзләренең барлыкка килүләре белән Татарстан нефтенә бурычлы.

Сүз дә юк, республикабызның данын еракларга таратты безнең нефть. Әмма соңгы елларда шунысы да ачыкланды: үзебезнең Татарстаныбыз өчен артык файдасы булмаган икән аның. Чыннан да, үзебездән артканын юк кына бәягә Польша, Германия Демократик Республикасы, Чехословакия, Венгрия кебек «тугандаш» илләргә сатып яттык. Ул вакытларда без, Европадагы яшь социалистик илләргә ярдәм итәбез, дип чын күңелдән шатлана идек. Ә үзебездә нефть эшкәртү заводлары төзеп, чит илләргә әзер продукцияне тиешле бәясенә сатсак, никадәр отышлы булган булыр иде икән? Шушы көнгә кадәр туган җиребез куеныннан барлыгы 2 млрд тоннадан күп «кара алтын» суыртып алынган. Хәзер нефть чыгару 1970 нче еллар белән чагыштырганда күпкә кимеде. 1990 елда, мәсәлән, ул 40 миллион тонна чамасы гына, 1992 елда 30 миллионнан да кимрәк булды. Безгә хәзер булганын саклап тотарга, акыл белән файдаланырга кирәк.

Тагын бер нәрсәне әйтеп үтми ярамас: соңгы елларга кадәр Татарстан халкы үз байлыгына үзе хуҗа була алмады. Миллионлаган тонна нефтьнең бер литрын да үзебез сатарга тиеш булмадык. Мәскәү, аны бездән тартып алып, үзе теләгәнчә файдаланып килде. Хәтта авылларыбызга газ кертү дә чын проблемага әйләнде. Аның каравы миллиардларча кубометр газны чит илләргә озата тордык. Ә табигатебезгә, җир-суларыбызга китерелгән зыян-зәхмәтләрне исәпли башласаң?! Нефть чыга торган якларда басу, урманнар, күпме җирләр юкка чыкты, күпме сулыклар пычранды? Бу республикабыз өчен чын-чынлап экологик катастрофа булды. Татарстанга әллә ничә мил-

лиард сумнарга төшә торган зыян килде.

Татарстан суверен, бәйсез республика дип игълан ителгәч кенә, хөкүмәтебез, үзебездә табылган нефтьнең барысы да халкыбызга хезмәт итәргә тиеш, дигән белдерү белән чыкты. Хәзер шушы максатны гамәлгә ашыру буенча актив эш алып барыла.

Сораулар һәм биремнәр:

1. «Татарстан — «кара алтын» иле» дигән темага хикәя төзегез.
2. Ни өчен нефтьне «кара алтын» дип йөртәләр? Аннан нәрсәләр җитештерәләр?
3. Нефть чыгарудан безнең республика нинди зыян күрде? Сезнең фикерегезчә, киләчәктә нефть промышленностен ничек итеп оештырырга кирәк?

61. КамАЗ — КАМА БАТЫРЫ

Элегрәк Татарстанның көнчыгыш районнарында эре промышленность предприятиеләре күп түгел иде. Соңгы берничә дистә ел эчендә Түбән Кама, Чаллы, Зәй, Алабуга, Менделеевск шәһәрләрендә әллә никадәр эре завод-фабрикалар, куәтле электр станцияләре төзелде. Бу төбәкләр хәзер республикабызның индустриаль үзәгенә әйләнде.

Кама батыры... Илебездә генә түгел, бөтен дөньяга яхшы таныш «КамАЗ» йөк машинасын әнә шулай дип йөртәләр. КамАЗ (Кама автомобиль заводы) төзелә башлаганчы, Чаллы Татарстанның гади бер шәһәрчеге иде. Бер катлы агач йортлар, тузанлы тар урамнар...

1969 елның августында шәһәрдән ерак түгел генә бер урында, Минзәлә юлы өстендә, «Биредә Кама автобатыры булачак!», дип язылган бетон блок утыртып куела. Декабрь аенда завод корпусының беренче субайлары кагыла. 1970 елның башында эш моңарчы күрелмәгән кызу темплар белән башланып китә.

КамАЗны бөтен ил төзеште диләр. Бу чыннан да шулай. Россиянең төрле өлкәләреннән, Украинадан, Белоруссиядән, Балтик буе һәм Кавказ якларыннан меңнәрчә эшчеләр Чаллыга киләләр. Берничә ай эчендә шәһәр танымаслык булып үзгәрә. Бөтен җирдә төзелеш краннары, бульдозерлар һәм экскаваторлар. Яңа йортлар күзгә күренеп үсәләр. Причалларда эш кайный: су юлы белән илебезнең төрле почмакларыннан китерелгән төзелеш әйберләрен, завод җиһазларын бушаталар. Йөзләгән гектар җирдә урнашкан завод корпуслары көннән-көн югарырак күтәрелә. Советлар Союзының йөздән артык фәнни-тикшеренү институты завод

өчен югары сыйфатлы технологик проектлар эшли, 5 меңнән артык предприятие аның өчен җиһазлар җитештерә. Меңнәрчә тәҗрибәле төзүчеләр, инженерлар һәм конструкторлар, Америкадан, Италиядән, Франциядән һәм башка илләрдән чакырылып китерелгән белгечләр КамАЗны төзүдә катнашалар.

1976 елның 16 феврале. КамАЗның төп конвейерыннан беренче автомобиль төшә! Бөтен ил Татарстан халкын яңа хезмәт җиңүе белән кайнар тәбрик итә. Кыска вакыт эчендә шушындый гигант заводны сафка бастыру чыннан да зур батырлык була. КамАЗ үзенең эш темпын көннән-көн арттыра. 1980 елның 8 апрелендә конвейердан инде 150 меңенче автомобиль чыга!

КамАЗлар тиздән бөтен илдә популярлык казаналар. Алар куәтле һәм идарә итү өчен уңай. Шунлыктан аны чит илләрдә дә бик теләп сатып алалар.

КамАЗ — безнең горурлыгыбыз, әлбәттә. Тик «Кама батыры»ның безнең республикага, аерым алганда, татар халкына китергән зыяннарын да истән чыгармаска кирәк. Әйе, КамАЗны Татарстан нефтен саткан акчага бөтен ил төзеште. Шулай да йөкнең авыр өлеше безнең җилкәгә төште. Үзләренең туган авылларын калдырып, күпме яшьләр Чаллыга китте һәм шунда төпләнеп калды?! Бар булган байлыгыбыз шул елларны КамАЗга кереп китте, ә күпме мәктәп, балалар бакчалары, мәдәният йортлары, китапханәләр, кинотеатрлар төзергә акча җитмәде?! КамАЗ һаман да әле тулысынча Татарстан файдасына эшләми. Чаллы үсте, хәзер биредә 600 меңләп кеше яши. Төз һәм киң проспектлар, бер-берсеннән бөтенләй диярлек аерып булмый торган кварталлар, күп катлы торак йортлар. Мондый төстәге шәһәрләр Россиядә бик күп. Ә Чаллы — Татарстан шәһәре. Аның милли йөзе, милли рухы булырга тиеш иде. Икенче дәрәҗәле эш дип, үз вакытында моңа игътибар итүче булмады. Төрле республикалардан КамАЗ төзелешенә 400 меңләп чит милләт кешеләре килде. Мәскәүдәге җитәкчеләр моны юри шулай эшләделәр, чөнки ул вакытларда бөтен халыклар бергә кушылып (дөресрәге, руслар тарафыннан йотылып) бердәм совет халкы барлыкка киләчәк, дип планнар коралар һәм шуны тормышка ашырырга омтылалар иде.

Илебездә демократик үзгәртеп корулар башлангач, халкыбыз Мәскәү тарафыннан үткәрелә торган бу сәясәткә битараф караудан туктады. Кайчан гына Чаллы, Түбән Кама тирәләрендә барлыкка килгән күп санлы заводлар өстенә тагын Алабугада трактор заводы, Кама Аланы поселогы янында атом электр станциясе төзергә керешкәннәр иде. Аларны төзегәндә табигатькә гаять зур зыян килүен дә күз йомып кына үткәреп булмый иде. Моңа ирек куймадылар. Халык

КамАЗ заводы.

таләбе белән төзелешләр туктатылды.

Татарстаныбыз — нык алга киткән индустриаль республика. Безнең предприятиеләр арасында бөтен дөньяга танылганнары бар. Бездә җитештерелгән байлык беренче чиратта үзебезнең халыкка хезмәт итәргә тиеш. Бу — безнең республиканың иң мөһим икътисади максаты.

Сораулар һәм биремнәр:

1. КамАЗ ничек төзелгән? Бу турыда китаптан укып та, әти-әниләрегездән сорашып та белергә тырышыгыз.
2. Татарстан җирендә КамАЗ төзүнең нинди уңай һәм тискәре яклары булды?
3. Татарстан атом электр станциясе турында ниләр беләсез?

62. СУГЫШТАН СОҢ МӘДӘНИЯТ ҮСЕШЕ

Үзгәртеп корулар чорына кадәр безнең мәдәният катлаулы, авыр юл үтте. Бу — сугыштан соң җимереклекләрне төзәтеп, илне торгызу һәм шул ук вакытта җиңү шатлыгы кичергән еллар. Бу чорда Ста-

Г. Х. Камай.

Т. Гыйззәт.

линнның шәхес культы еллары һаман дәвам итә. Ул мәдәнияткә, әдәбияткә аеруча зарар китергән тоталитар режим (үзәктән боерып эшләтү) еллары белән алышына.

Сүз иреген, иҗат ирекен бууга карамастан, бу 40 ел (1945—1985) эчендә дә мәдәнияттә, фәндә, мәгърифәттә, әдәбиятта шактый зур уңышларга ирешелә. Илдә башта гомуми җидееллык, сигезьеллык белем бирү мәктәпләре эшли. Аннары урта белем бирүче унъеллык мәктәпләр системасына күчелә.

Югары уку йортлары, техникум, училищеларның да саны арта. Хәзер республикада 17 югары уку йорты һәм аларның филиаллары, 62 техникум бар. Аларда бик күп белгечләр укып чыга.

Казан илдә иң зур һәм данлы фән үзәкләренең берсе булып кала бирә. 1945 елда Фәннәр Академиясенең Казан филиалы төзелә. Анда фәннең күп өлкәләре буенча галимнәр эшли. Академик А. Е. Арбузов ярты гасырдан артык Н. И. Зинин, А. М. Бутлеров традицияләрен дәвам иткән химиклар мәктәбен җитәкли. Аның бу эшен улы — шулай ук академик — Б. А. Арбузов дәвам иттерә. Химия галиме, профессор Г. Х. Камай исеме дә дөньяга танылды. Ул мышьяклы кушылмалар өлкәсендә зур ачышлар ясады.

Физикада Е. К. Завойский, С. А. Альтшулер, К. Ә. Вәлиев, Б. М. Козырев, Н. С. Гарифҗанов; математика һәм механика буенча А. З. Петров, Б. М. Гагаев, А. П. Норден, Х. М. Мөштәри; биология һәм ветеринариядә И. А. Тарчевский, Н. А. Ливанов, А. П. Студенцов; медицина һәм дарулар ясауда И. В. Заиконникова, М. И. Беляева; тарих, әдәбият, тел белемендә Н. И. Воробьев, Н. Ф. Калинин, Л. Җәләй, А. Х. Халиков, И. Р. Таһиров, М. Г. Госманов, С. Х. Алишев, М. Х. Гайнуллин, М. З. Зәкиев, Ә. Г. Кәримуллин һәм башка күпләрнең хезмәтләре фәнгә зур өлеш кертте.

С. Хәким.

Татар әдәбияты милли әдәбиятлар арасында иң борынгылардан, алга киткәннәрдән санала. Соңгы елларда да күп талантлы әсәрләр язылды. Аларда Бөек Ватан сугышындагы халык батырлыгы, узган тарих һәм хәзерге тормыш сурәтләнде. Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Гомәр Бәшировның «Намус», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел», Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын Йолдыз», «Газинур», Ибраһим Газинең «Онытылмас еллар», Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Нурихан Фәттахның «Этил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Әнвәр Давыдов, Нури Арсланов, Шәрәф Мөдәрриснең шигырь, поэмалары, Таҗи Гыйззәт, Мирсәй Әмир, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйлаҗев пьесалары татар әдәбиятында күренекле урын алып торалар.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә күренекле татар, рус, чит ил драматургларының әсәрләре уйналды. Х. Әбҗәлилов, З. Солтанов, Ф. Ильская, Х. Уразиков, В. Минкина, Г. Булатова, Г. Шамуков, Ф. Халитов, Р. Җиһаншина, Ш. Биктимеров, Ш. Әсфәндиярова, Н. Гәрәева, Р. Шәрәфиев, Р. Таҗетдинов һәм башка күп артистлар сокланырлык образлар тудырдылар. Театр



Х. Туфан.

1957 елда Ленин ордены белән бүләкләнде. Баш режиссер СССР халык артисты М. Сәлимҗанов җитәкчелегендә театрның эше тагын да җанланып китте.

1978 елда элекке Татарстан дәүләт республика күчмә театры нигезендә К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры эшли башлады.

В. И. Качалов исемендәге Казан Зур рус драма театрында да әйбәт спектакльләр күрсәтелде. Е. Е. Жилина, Н. И. Якушенко, Г. П. Ардаров, И. В. Загорский, Ф. В. Григорьев, В. М. Павлова кебек артистларның даны еракларга таралды.

Минзәлә, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләрендә дә театрлар уңышлы эшләп килә.

1970 елда «Сабантуй» исемле милли цирк туды.

Музыка өлкәсендә матур әсәрләр иҗат ителде. Н. Җиһановның «Сабантуй» симфониясе, «Җәлил» операсы, М. Мозаффаровның «Галиябану», Х. Вәлиуллинның «Самат» опералары, Ә. Бакировның «Су анасы», А. Ключаревның «Тау әкияте» Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль әсәрләре, Сара Садыйкова җырлары, Р. Яхин романслары, Ф. Әхмәтов әсәрләре музыкаль мәдәниятебезнең алтын фондын тәшкил итәләр.

1956 елда Казанның Ирек мәйданында бик матур бина ишекләрен ачты. Бу — хәзер М. Җәлил исемен йөртә торган Татар дәүләт академия опера һәм балет театры. Анда Ф. Насретдинов, А. Аббасов, М. Булатова, М. Рахманкулова, З. Хисмәтуллина, З. Сөнгатуллина кебек җырчылар, Н. Юлтыева, К. Гайнуллин, Р. Садыков, И. Хәкимова кебек биючеләр тамашачылар алдында дан казандылар.

Татар дәүләт филармониясе артистларын илебезнең һәр төбәгендә көтеп алалар. Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Ринат Ибраһимов, Хәйдәр Бегичев, Вафирә Гыйззәтуллина, Римма Ибраһимова, Хәмдүнә Тимергалиева... Соңгы елларда берсеннән-берсе оста, талантлы җырчылар килә.

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, илебезнең төрле шәһәрләрендә булганнан соң, Италия, Япония, Африка илләре, Финляндия һәм башка илләрдә йөреп кайтты.

Рәссамнарга да бай безнең Татарстан. Казанның Күргәзмә залында, Сынлы сәнгать музеенда әнә Б. Урманченың «Шүрәле», «Сагыш» исемле сыннары, «Ибн Фадланның Болгарга килүе» рәсеме, К. Е. Максимовның «Нарат урманы», «Хәвефле тынлык», Х. Г. Якуповның «Көчле кешеләр», «Пролог», Л. А. Фәттахның «Ашлыклар өлгерде», «Сабантуй» картиналары һәм башка рәсемнәр.

Казан мәйданнары яңа һәйкәлләр белән бизәлде. Мәркәз шәһәребездә Г. Тукай, А. Бутлеров, М. Вахитов, М. Җәлил һәйкәлләре куелды. С. Сәйдәшев, Ф. Шаляпин, М. Солтангалиев һәйкәлләрен төзүгә әзерлек бара.

Опера һәм балет театрыннан тыш Казанда «очучы тәлинкәгә» охшаган матур цирк, Г. Камал исемендәге академия театры, Яшьләр үзәге, «Татарстан» кунакханәсе, Елга вокзалы, Химиклар һәм Төзүчеләр сарайлары биналары калкып чыкты. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә төзелешләр аеруча күп булды.

Шундый уңышларга карамастан, татар мәдәниятендә дә торгынлык күренешләре башланды. Халкыбызга гаять зур афәт килде: Казанда һәм башка шәһәрләрдә бер татар мәктәбе дә калмады диярлек. Телен, тарихын, мәдәниятен белмәүче бер буын үсеп җитте. Мәктәпләрдә туган тел — татар теле, Татарстан тарихы белән кызыксыну бетте. Моңа партия сәясәте гаепле булды.



Сәхнәдә.

Иҗат өлкәсендә дә язучылар, артистлар, рәссамнар ирекккә тиенә алмадылар. Ясалма, шапырынулы,

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле.

аерым кешеләргә, коммунистлар партиясенә дан җырлаган әсәрләр барлыкка килде.

Татарстан мөстәкыйль, үз байлыгына үзе хуҗа була алмаганлыктан аның мәгариф, мәдәнияттен үстерү өчен бик аз күләмдә генә акча биреп киленде. Без узган дәресләрдән революциягә кадәр татарларда китап басу эшендәге казанышлар белән яхшы таныш инде. Соңгы дистә елларда хәл киресенчә үзгәрде. Мәсәлән, революциягә кадәр үзбәк, казах, азәрбайҗан, Кырым татарлары, төрекмәннәр, ногайлар, кумыкларның һәммәсе чыгарган китапларына караганда татар китабы утыз тапкыр артыграк чыга. Ә 1960—1980 елларда союздаш төрки республикаларда елына 1000—2000 һәм аннан да күбрәк исемдә китап чыгарсалар, бу елларда татар китабы басу 150—200 исемнән артмады.

Татарстанга бәйсезлек кирәклеге бөтен җитдилеге белән алга килеп басты.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Татарстанда нинди югары уку йортларын беләсез?
2. Телгә алынган язучыларның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?
3. Нинди балалар язучыларын беләсез?
4. Сезнең шәһәр, авылыгызда нинди мәдәният учаклары бар? Алар турында сөйләгез?

Кичке моң. *Р. Заһидуллин картинасыннан.*

63. ҮЗГӘРТЕП КОРУ. ХӘБӘРДАРЛЫК. МИЛЛИ ЯҢАРЫШ

СССР 80 нче еллар уртасында, ниһаять, торгынлык чигенә килеп җитте. Икътисад, бер урында озак еллар таптана торгач, артка тәгәри башлады. СССР алга киткән илләрдән ныклап артка калды. Ил байлыгы үзара ярышып кораллануга китте. Дөрес, халыкның тормыш хәлен яхшырту турында күп санлы карарлар, программалар кабул ителде. Әмма, аңа карап, халыкның тормыш

дәрәҗәсе ныклап яхшырмады. Чөнки карарларның берсе дә тормышка ашмады. Алай гына түгел, азык-төлек, беренчел куллану әйберләре белән тәэмин итүдә кытлык отыры сиздерә башлады.

Ни өчен болай килеп чыкты соң? Бу — икътисадның үз законнарын санга сукмыйча, планлы хуҗалык оештырабыз дип, үзәктән торып боерыклар биреп кенә идарә итүнең нәтиҗәсе иде. Бишьеллык планнар нигездә үтәлмәде, шау-шулы, мактанулы кампанияләргә генә әверелде. Ә алга киткән илләрдә базар мөнәсәбәтләренә нигезләнгән хуҗалык үсте. Ул алга таба зур сикерешләр ясады.

Сәясәт өлкәсендә дә илдә зур торгынлык күзәтелде. Бөтен хакимлек КПСС кулында булды. Совет власте үзенең вазифаларын үти алмады. Демократия, ягъни халык власте сүздә генә калды. Илдә законсызлык галәмәтләре өстенлек итте. Партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре, өлкә, крайларның башлыклары җиңел яшәргә көйләделәр, халыктан аерылдылар. Ришвәтчелек киң таралды. Фикер төрлелегенә юл куйю бетерелде. Бу системага каршы булган кешеләр эзәрлекләнде. Әмма боерыклар, эзәрлекләүләр юлы белән генә идарә итеп булмый башлады. Тормыш ниндидер үзгәрешләр кертү кирәклеген үзе китереп куйды.

1985 елда, ниһаять, үзгәрешләр башлау өчен шартлар туды. Дәүләт башында җитәкчелек яңарды. Илдәге хәлләр партия һәм совет хөкүмәте җитәкчелеген җәмгыятьне үзгәртеп кору юнәлешендә эшли башларга мәҗбүр итте. М. С. Горбачев җитәкчелегендә илдә үзгәртеп кору сәясәте башланды. Икътисад белән идарә итүдә, сайлаулар системасында яңалыклар барлыкка килде. Хуҗалык белән идарә итүдә җирле оешмаларга мөстәкыйльлек күбрәк бирелде. Үзгәртеп кору максатларына ирешүдә хәбәрдарлык куәтле коралга әйләнде. Цензура бетерелде, газета, журнал һәм башка массакүләм информация чаралары иреккә чыктылар. Партия хакимияте елларындагы җитәкчелекнең күп җинаятьләре халык алдында фаш ителде.

Ләкин бу башлангыч адымнар гына илне афәттән коткара алмый иде әле. Үзгәртеп кору дигәннәре дә асылда бер чираттагы кампаниягә генә охшап калды. Җәмгыятьтә илне ныклап демократияләштерү, кеше хокукларын яклау турында таләпләр кискенрәк яңгырады. Ә тоталитар көчләр үз хакимлекләрен җиңел генә бирергә теләмәделәр. Үз хакимлекләрен кире кайтару өчен алар 1991 елның августында Мәскәүдә фетнә оештырдылар. Бу шомлы көннәрдә демократик көчләр җиңеп чыкты. Ил демократиягә, базар икътисадына курс алды. Коммунистлар партиясе хакимлеге бетерелде,

СССР таркалды. Бу — XX гасыр ахыры тормышындагы иң мөһим вакыйгалар булып тарихка кереп калды. Административ идарә, үзәктән боерулар системасы какшау, йомшару белән ил хуҗалыгында элекке каршылыклар кинәт шәрәләнеп ачылдылар. Элекке гаделсезлекләр кичәге СССР, бүгенге Бәйсез Дәүләтләр Берлеге (БДБ) дип аталган илләрнең күп кенә төбәкләрендә милли ризасызлыклар башлануына китерде.

Республикаларда һәм аларның аерым өлкәләрендә тирән үзгәрешләр башланды. Яңа тормышны яклаучы күп кенә оешмалар барлыкка килде. Милли республикаларда халык фронтларыннан милли яңарыш хәрәкәтләре үсеп чыкты. Аларның нигезен киң халык массаларына таянган демократик көчләр тәшкил итте. Алар халыкларның чын-чынлап тигезлеген, демократик яңарышны таләп итеп күтәрелделәр.

Татарстанда мондый хәрәкәт 1988 елда ук барлыкка килде. Аны оештыру җыены 1989 елның 17 февралендә булды. Бу хәрәкәт «Татар иҗтимагый үзәге» (ТИҮ) дип аталды. Үз халкы язмышына битараф булмаган һәр кеше бу хәрәкәткә кушылды. ТИҮ үзенең беренче көннәреннән үк Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәш башлады. Татар милләтен тергезү, икътисади мөстәкыйльлек алу көрәшнең төп максаты итеп билгеләнде. Бар булган байлыкны республика халкы тормышын яхшырту өчен, аның рухи мәдәниятен тергезү, үстерү өчен тоту, тигезләр арасында тигез булу бурычы куелды.

Милли яңарыш дулкынында Татарстанда төрле фиркаләр (партияләр) барлыкка килә башлады. Беренчеләрдән булып милли бәйсезлек яклы «Иттифак» («Берлек») оешты. Ул бәйсез татар дәүләте булдыруны беренче планга куйды. Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителгәннән соң, аны яклау һәм тормышка ашыруда халыкны оештыру өчен, «Суверенитет» комитеты төзелде. Татар халкының милли мәсьәләләрен хәл итүдә нәтиҗәле эшләүне тәэмин итү өчен 1992 елның башында Милли мәҗлес сайланды.

Татар халкының мәдәниятен, мәгърифәтен үстерергә чакыруда Ш. Мәрҗани исемендәге оешма һәм «Мәгариф» комитеты зур эшчәнлек күрсәтәләр. Халыкның тарихын өйрәнүгә игътибар артты. «Болгар әл-җәдит» (Яңа Болгар) клубы һәм «Болгар милли конгрессы», мәсәлән, үз эшчәнлекләрендә халкыбызның борынгы исемен кайтаруны беренче максат итеп куялар.

Ләкин республикада суверенитет алуга, милли иминлеккә, татар халкының тигезлеккә омтылышына каршы көчләр дә бар. Болар — Россия үзәгендә барлыкка килгән кайбер партияләрнең фи-

17 Ч-279

лиаллары. Бу — беренче чиратта Россия демократлар партиясенең Казандагы бүлеге. Алар баштагы чорда элекке системага каршы кискен көрәш алып барсалар да, милли мәсьәләдә «демократия» сүзен онытып, Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы чыгу, асылда аны Россиянең бер өлкәсе итеп калдыру өчен көрәшәләр, татар халкының милли яңарышын бөтенләй санга сукмыйлар.

Республикабыз алдында үзенең мөстәкыйльлеген тормышка ашыруда, Россия белән үзара тигез хокуклылык килешүенә ирешүдә һәм халыкның тормыш-көнкүрешен тамырдан яхшыртуда, хокукый дәүләт төзүдә зур бурычлар тора.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Нинди сәбәпләр СССРда үзгәртеп коруның зарурлыгын күрсәтте?
2. Татарстандагы милли хәрәкәтләр хакында сөйләгез.
3. «Тарихи сүзлеккә» «үзгәртеп кору», «хәбәрдарлык», «милли яңарыш», «ТИҮ», «Иттифак», «Милли мәҗлес», «БДБ» дигән сүзләрне аңлатып языгыз.

64. БЕЗНЕҢ СИМВОЛЛАР: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ БАЙРАГЫ ҺӘМ ТУГРАСЫ (ГЕРБЫ)

Дөньяда 170 тән артык бәйсез ил бар. Һәр бәйсез, мөстәкыйль ил үзенә генә хас байракка, туграга ия. Мәсәлән, Төркия байрагы кызыл төстә, аңа айның соңгы чиреге һәм йолдыз сурәте төшерелгән. Америка Кушма Штатлары байрагында ак һәм кызыл тасмалар чиратлаша. Байракның югары сул почмагындагы зәңгәр квадрат эчендә штатлар (өлкәләр) санынча йолдыз рәсемнәре. Россия Федерациясе байрагы буй-буй ак, зәңгәр, кызыл өлешләрдән тора. Ә Франция байрагында бу төсләр аркылыга урнашкан. Кайбер илләрнең байракларына тугралар (герблар) да төшерелгән.

Дәүләт байрагы — ул илнең йөзе, бәйсезлек билгесе. Шуның өчен дә әүвәл заманнардан ук дәүләт бәйсезлегенә куркыныч янаганда, бәйсезлекне яклап көрәшкә чыкканда үз илләре байракларын күтәреп барганнар. Байрак көрәшкә рухландырган. Байрак күтәреп баручы кешене дошман иң элек юк итәргә тырышкан. Байрак йөртүче егылса, байракны күтәреп алып, аның урынына икенчеләр басканнар. Иң авыр хәлләрдә дә дәүләт байрагын дошманга мәсхәрәләргә юл куймаска тырышканнар. Я кадерләп төреп, күмеп куйганнар. Я кием эченнән тәннәренә ураганнар. Байракның дошман иле өстенә эленүе ул җиңү, тантана билгесе булган. Көрәшчеләр

азатлык өчен соңгы тамчы каннарына кадәр көрәшергә, президентлар илгә, халыкка тугрылыклы булырга байрак үбеп ант иткәннәр.

Бәйрәм көнне илебез байрагын бөтен җирдә күрергә була.

Суверен Татарстан байрагы беренче мәртәбә 1991 елның декабрендә башкалабыз Казанның Ирек мәйданындагы Югары Совет бинасы өстендә җилфердәде. Аннары ул республикабызның шәһәрләре, районнары, авыллары өстенә күчте.

Нинди соң ул Ирекле Татарстан байрагы? Аның иңе буеның яртысы кадәр. Ул астан өскә таба өч өлешкә бүленгән. Өске өлеше яшел, аскы өлеше шул ук зурлыкта кызыл. Ә уртада тар ак тасма. Менә нинди күркәм безнең илебезнең байрагы.

Байрактагы һәр төс үзенә бер мәгънәгә ия.

Хәтерегездәдер, иң борынгы заманнарның рәссамнары да кызыл төсне яратканнар. Хайван сурәтләрен тау куышы стеналарына кызыл төстәге буяу белән ясаганнар. Шулай итеп, кан төсендәге буяу белән рәсемнәргә җан өрергә теләгәннәр. Кызыл төс борынгы төркиләрдә канга бәйле рәвештә куәт-дәрман һәм тормыш-яшәү билгесе булып хезмәт иткән. Моннан тыш кызыл төс — кешеләр яшәешендә бик әһәмиятле булган кояш, ут, яшен төсе дә. Ул — яшәү тантанасы, бәйрәм төсе



Татарстан Республикасы байрагы.

дә. СССР таркалганчы, аның байрагы да кызыл төстә иде.

Яз җитә, бөтен табигать җанлана, яшелгә төренә. Көз җитә, бар нәрсә саргая, кибә, кышкы йокыга әзерләнә. Яшел төс — ул җанлы табигать төсе, яшәү, яшьлек билгесе. Борынгы күчмә кабиләләр өчен яшел далалар, тугайлар чын мәгънәсендә яшәү чыганагы булган.

Уртадагы ак төс — сафлык, пакьлек һәм тынычлык-иминлек билгесе. Менә нинди олы һәм мөһим мәгънәләр салынган икән безнең байрагыбыз төсләренә.

Безнең алда — Татарстан туграсы, гербы. Анда кызыл түгәрәк кояш җирлегендә кодрәтле, канатлы ак барс сурәте. Барсның уң аягы бераз күтәрелгән. Бу башка илләр туграларында да еш очрый торган ишарә. Ул үзәк хакимиятне, аның бөеклеген, илһамлыгын аңлата. Барсның тешләре, тырнаклары үткен. Димәк, ул үзен дә һәм үз канаты астында булган кешеләрне дә яклый ала.

Барсның ян ягында түгәрәк кал-

кан. Аңа 8 таҗ яфракчалы кашкарый (астра) чәчәге рәсеме төшерелгән. Калкан сакланганлыкны, иминлекне аңлата. Ә 8 таҗ яфракчалы кашкарый чәчәге — озын гомер билгесе. Шул ук вакытта ул — кояш символы да. Болгар кабер ташларын да бизи торган бу чәчәк кешегә үлгәннән соң да мәңгелек гомер теләү турында сөйли. Кояш гомере теләү дигән сүз.

Кызыл кояш җирлегендә төшерелгән барс рәсемен башта ак бөҗра, ә аннан яшел бөҗра уратып алган. Туградагы кызыл, ак, яшел төсләр Татарстан байрагын ишарәли. Тугъраны әйләндереп алган яшел җирлеккә алтын төсендә халкыбызның яраткан орнаменты бизәге төшерелгән һәм аска «Татарстан» дип язылган. Бизәк илебез җиренең ямен, уңдырышлылыгын чагылдыра. Шундый җирне изге барс яклый.

Барс артындагы кояш илаһи мәгънәгә ия һәм, шуның белән бергә, ул аяз күкне, сафлык, яктылык һәм яхшылык төсмерләрен аңлата.

Ни өчен илебезнең тугрась үзәгендә барс рәсеме төшерелгән дисезме? Ул безнең бабаларыбыз дәүләте Бөек Болгар иленең туграсында сурәтләнгән булган. Ә ни өчен нәкъ менә барс сурәтен тугъраның нигезе итеп алганнар безнең борынгы бабаларыбыз? Еш кына кабиләнең яклаучысы — тотем — җәнлек, баба (пот, сын) сурәте борынгы кабиләнең үзенчәлекле билгесенә әверелгән. Безнең болгар бабаларыбызда шундый тотем булып барс сурәте хезмәт иткән. Дөрес, ул башта барсил (исеме дә барс иле, барс халкы дигәнне аңлата) исемле болгар кабиләсенең генә тотемы булган. Әмма барсиллар болгар кабиләләре арасында әйдәп йөрүче иң баш кабилә булып исәпләнгәннәр. Аларны «көмеш болгарлар» дип йөрткәннәр. Шушы кабиләдән болгар патшалары куелган. XII гасырдан бу баш кабилә үзенең тотемын, тамгасын бөтен болгар кабиләләренә тарата. Барс сурәте рәсми мөһерләрдә, герләрдә, тәңкәләрдә урын алган. Ягъни ул безнең бүген кабул иткән тугра төшенчәсенә якын була.

Бу якларда яшәмәгән җәнлек ни өчен болгарларның тотемы булган, аннан аларның туграсына әйләнгән соң? Барс — борынгы төркиләр, шул исәптән болгарларның бабалары яшәгән Алтай, Көньяк Себер, Урта Азия төбәкләрендә яши торган җәнлек. Гомумән, барс образы бик күп төрки халыклар сәнгатенә, мифологиясенә хас.

Борынгы чорлардан ук таралган бер риваятьтә безнең борынгы бабаларыбызның дошманнар тарафыннан кырып бетерелүе хакында сөйләнелә. Бу сугышта ун яшьлек бер бала гына исән кала. Аны да дошманнар, табып алып, уң кулын, бер аягын чабып өзеп сазлыкка ташлыйлар. Үлемгә

дучар булган бу баланы ана барс тәрбияләп үстерә. Ун елдан соң дошманнар белән бер сугышта бу егет үтерелә. Ә барс таулар белән (Алтай) әйләндереп алынган далада яшеренә һәм анда ун ир бала тудыра. Янәсе, шулардан төрки кабиләсенең тарихы башланып китә. Бу риваять сөйләнеп кенә калмаган, рәсемнәрдә, сыннарда сурәтләнгән.

Менә борынгы болгарлар ясаган барс кыяфәтендәге сурәт эшләнгән борынгы йозаклар. Барс сыннарына бер аягы, кулы чабылган гарип кеше сыннары утыртылган. Күрәсез, югарыда сөйләнгән риваять белән бу сыннар аваздаш.

Ни өчен бу йозаклар табынгыч сын — барс кыяфәтендә ясалган соң? Борынгы бабаларыбызның дөньяга карашларыннан чыгып фикер йөрткәндә, йозак астына алынган әйбернең, йорт-җирнең чын мәгънәсендә сакланышын тотем (табына торган сын) гына тәэмин итә алган. Алай гына түгел, ил-йортның да, халыкның да ышанычлы сакчысы булган тотем-барс.

Биләр шәһәреннән табылган бронза мөһердә канатлы барс сурәтен күрәбез. Болгарлар карашынча, барсның канатлы булуы аны җир тормышында гына түгел, күк, галәмдә дә хуҗа иткән.

Еш кына сыннардагы, акчалардагы рәсемнәрдә барс сыңар мөгезле. Димәк, бу — гади генә түгел, мөгезле барс. Билгеле, барслар мөгезле булмый. Бу — аерымлау билгесе. Бу — бәхет, дәрәҗә, хакимлек билгесе.

Татарстан Республикасы туграсы.

Тотем хайван исемен яңа туган балага кушу — борынгылыкта гадәти хәл. Шуның белән балага тотем көчен бирергә, аны һәр яман нәрсәдән сакларга, аны шуның яклавы астына алырга теләгәннәр. Болгарлар арасында Барс исемле кешеләр күп булган.

Гасырлар аша килгән барс образы бүген дә халык телендә. Ул байлык, мәртәбә, көчне аңлата. Бу җәһәттән бүгенге мәкаль-әйтемнәргә игътибар итик: «Барс елны бар да үсәр», «Барс елы — байлык». Шулай итеп, 12 еллык җәнлек календаренда барс елы муллык, уңыш китерә торган ел буларак аңлатыла. Ә барс сүзе белән ясалган кеше исемнәре бездә 20 дән артык булган: Айбарс, Байбарс, Илбарс, Колбарс, Янбарс һ. б.

Боларның барысы да безнең хал-

кыбызның, аның ерак бабаларының рухи тормышында: дөньяга карашында, халык авыз иҗатында, сынлы сәнгатендә барс образының күренекле урын тотуы хакында сөйли. Ул үзендәге сыйфатлар белән республикабызның тугра нигезен тәшкил итеп, халкыбызны яхшы тормышка әйдәп баруда, аның адымнарына ышаныч бирүдә, иминлегебезне, азатлыгыбызны саклауда рухи нигез булып тора.

Кояш гомерле булсын безнең ил символлары — байрагыбыз, туграбыз. Без аларны кадерләп саклыйк. Бездә аларга карата горурлык булсын!

Сораулар һәм биремнәр:

1. Байрагыбыздагы төсләр нәрсәне аңлата?
2. Ни өчен Татарстан туграсына ак барс рәсеме төшерелгән?
3. Өйдә яки хезмәт дәресендә кечкенә байрак һәм тугра рәсемен ясап килегез.

65. КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

1990 елның 30 августы. Берничә көн инде башкалабыз Казанның Ирек мәйданы халык белән тулы. Монда туктаусыз митинг бара. Консерватория бинасының биек баскычына менеп, ярсып-ярсып, Татарстанга бәйсезлек, азатлык таләп итеп сөйлиләр. Чыгышлар гел бер кодрәтле сүз — «Азатлык!» белән тәмамлана. Мәйдан бу сүзне күтәреп ала. «Азатлык! Азатлык!» дигән тавышлардан һава тетрәп тора. Татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак» фиркасе (партиясе) байраклары җилферди. Мәктәп укучысы да, яшь студент та, яше 70 тән арткан әби-бабай да, Казан кешесе дә, авыл кешесе дә, Татарстанның башка шәһәрләреннән дә — Чаллыдан да, Әлмәттән дә, Бөгелмәдән дә, Зәйдән дә — Башкортстаннан да, Үзбәкстаннан да, Кырымнан да, Балтик буеннан да вәкилләр булып кешеләр җыелганнар монда. Билгеле, Казан — Татарстанның гына башкаласы түгел, бөтен татар халкының да мәркәзе, изге үзәге бит ул.

Кичке ахшам намазы җитә. Әбибабайлар үзләре белән алып килгән намазлыкларын электәге партия өлкә комитеты бинасы баскычларына җәеп намаз укыйлар, илебезнең, халкыбызның азатлыгы өчен дога кылалар, Алладан ялваралар.

Монда сөйлиләр дә, шигырь дә укыйлар, җырлыйлар да. Барысы да азатлыкка багышланган. Әнә Вафирә Гыйззәтуллина, Гөлзадә Сафиуллина, Хәмдүнә Тимергалиева... Аларга кушылып, бар-

Ирек мәйданында митинг.

ча мәйдан җырлый: «Уян, татар, уян инде, уяныргa вакыт җитте!» Аннан халык Ирек мәйданы әйләнәсе буйлап атлый. Байраклар өскә чөелә. «Азатлык! Азатлык!»

Татарстан Югары Советы утырышы барган бина эчендә кызу бәхәсләр бара. Әмма ахырда барысы да бер фикергә килә. Татарстанның мөстәкыйльлеге, бәйсезлеге хакында Декларация кабул ителә. Зал аягүрә баса. Көчле алкышлаулар, ура кычкырулардан зал дерелдәп тора. Кичке 10 сәгать 40 минут.

Урамда бу хәбәрне зарыгып көткән халык читлектән иркенгә чыккан кош кебек була. Шатлыктан тыела алмый җилпенә, җырлый, бии, елый, бер-берсенә ягымлы сүзләр әйтә, кочаклаша. Татарстанның иң зур мәйданы куәтле җыр, бию сәхнәсенә әверелә. Гармуннар уйный, барча кеше — карты-яше бии. Әнә милиционерлар да, мәйдандагы вазифаларыннан «онытылып», биергә тотыналар. Ә нигә — җырлау, бию тәртип бозу түгел ич!

Республиканың бәйсезлеге, мөстәкыйльлеге игълан ителде. 1552 елдан бирле, 438 ел көткән изге сәгать сукты! 30 август Татарстан халкының бәйрәм көне — «Республика көне» дип игълан ителде.

Нәрсә хакында әйтелә соң бу Декларациядә?

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы Югары Советы:

1. Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итә һәм аны Татарстан Совет Социалистик Республикасы — Татарстан Республикасы итеп үзгәртә.

2. Татарстан ССР территориясендәге җир һәм аның байлыклары һәм башка ресурслары бары тик аның халкының милке булып тора.

3. Татарстан ССР үз территориясендә яшәүче барлык гражданнарга нинди милләттән булуларына, социаль чыгышлары, диннәре, политик инанулары нинди булуга һәм башка аерымлыкларга карамастан, һәр кешегә тигез хокуклар,ирекләр гарантияли. Татарстан ССРда татар һәм рус телләренең тигез хокуклы кулланылуы, башка милләтләрнең телләрен саклау һәм үстерү гарантияләнә.

...5. Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле».

Җыеп әйткәндә, бу бәйсез демократик дәүләт төзү турындагы белдерү булды. Бәйсез, чөнки моннан соң Татарстан тигезләр арасында тигез, үзебезнең табигый байлыкларыбызга һәм чималларыбызга үзебез хуҗа булырга, туган телебезне, күркәм гореф-гадәтләребезне, динебезне саклап калырга, балаларыбызны ана телендә укытырга, кешечә көн итәргә һәм башка илләр белән ирекле рәвештә аралашырга омтылу булды.

Демократик, чын халык хакимиятенә ирешү — бары тик бөтен халык мәнфәгатьләрен генә күздә тоту. Яхшы тормыш итү өчен алынган бәйсезлек — ул татар халкы өчен генә түгел, ә бәлки Татарстанда яшәгән һәр милләт кешесе өчен дә. Татарстанда, милләтенә, диненә карамыйча, һәр кешегә тигез хокук бирелә. Руска да, чувашка да, марига да, башкортка да, мордвага да, украинга да, яһүдкә дә, христианга да, мөселманга да.

Менә шундый изге теләкләр, бурычлар куелган бу Декларациядә. Ул безнең төп законыбызга әйләнде. Конституциягә «Татарстан суверен дәүләт» дип язып куелды. Әмма аны тормышка ашыру өчен җиң сызганып эшләргә кирәк иде.

Декларация кабул ителгәннән соң шактый эшләр башкарылды. Элекке Татарстан ССР исеме Татарстан Республикасы дип үзгәртелде. Республикада урнашкан күпчелек завод, фабрикалар Татарстан карамагына күчте. Бездә табылган нефтьнең дә бер өлеше Татарстан ихтыяҗларына тотыла башлады. Башка өлкәләргә караганда Татарстанда мулрак уңыш җыеп алу, завод-фабрикаларны әйбәтрәк эшләтү тәэмин ителде.

1991 елның 12 июнендә Татар-

стан халкы үзенең беренче Президентын сайлады. Бу җаваплы постка Минтимер Шәрип улы Шәймиев сайланды.

Әмма эшләр шуның белән генә ал да гөл булып башланып китте дип әйтеп булмый. Империячел үзәк Татарстанның мөстәкыйльлегенә ирек бирмәвен күрсәтте. Безнең мөстәкыйльлекне танырга теләмәде. «Суверенитетны Татарстан халкы якламый» дигән ялган хәбәр таратып карады. СССР таркалгач, империячел үзәк, Татарстанның мөстәкыйльлегенә каршы көрәш үзәге, Россиягә күчте.

Шушы шартларда Татарстанда аның язмышы, бәйсезлеге хакында референдум үткәрергә кирәк булды. Референдум 1992 елның 21 мартына билгеләнде. Бер ай буе халыкка аңлату эше алып барылды.

Империячел көчләр халыкның җиңеп чыгасын сизеп, референдумны өзәр өчен нык тырыштылар. Эш хәтта куркыту-янауга барып җитте. Россиянең Конституцион суды, Прокуратурасы, парламенты, хәтта президенты да бу эшкә җигелде. Россия президенты, куркытып-өркетеп турыдан-туры Татарстан халкына мөрәҗәгать итеп карады. Россия телевидениесе, радиосы, газета-журналлары, листовкалары — һәммәсе Татарстан турында төрле ялган хәбәрләр таратты. Барысы да халыкны референдумда Мөстәкыйльлеккә, Бәйсезлеккә, Азатлыкка каршы «юк» дип әйттерергә тырышты. Моның өчен Татарстандагы үзләрен «демократлар» дип атаган, ә чынында ялган демократлар булган кешеләр аеруча күп көч куйдылар.

Бөтен дөнья Татарстан язмышы ничек хәл ителүен зур игътибар белән күзәтеп торды. Дөньяның иң зур газеталары Татарстан турындагы хәбәрләрне беренче биткә урнаштырдылар. Карап торучылар гына түгел, безгә теләктәшлек белдереп, Татарстанның эчке эшләренә тыкшынучыларга кискен каршы чыгучылар да булды. Референдум көненә Татарстанга Берләшкән Милләтләр Оешмасыннан, дөньяның бик күп илләреннән күзәтчеләр, журналистлар килде.

21 март елның көн белән төн тигезләшкән вакыты, Нәүрүз бәйрәме иде. Көн тып-тын, чалт аяз, кояшлы иде. Кешеләр күңелендә табигатьтәге шикелле бәйрәм рухы җәйрәде. Халык иртүк сайлау урыннарына ашыкты. Иң зур күпчелек «Әйе!» дип җавап бирде. Азатлык өчен — «Әйе!», мөстәкыйльлек өчен — «Әйе!», үз җиреңә хуҗа булу өчен — «Әйе!», дуслык өчен — «Әйе!». Халык ныклы сүзен әйтеп, бүгеннән үзенең бәйсез дәүләт икәнен белдерде. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң 440 ел узгач, татар халкы үзенең дәүләтчелеген торгызу өчен хәлиткеч адым ясады. Бу шул ук вакытта республикада яшәүче халыклар-

ның гасырлар буена сакланып килгән дуслыгын тагын бер кат раслаучы ачык дәлил дә булды.

Ләкин барлык бурычлар да хәл ителеп бетмәде әле. Иң изге бурыч — үзебезнең бәйсезлегебезне, мөстәкыйльлегебезне күз карасыдай саклау. Борынгы бабаларыбыз — болгарлар, кыпчыклар үз илләрен «Гөлстан» дип йөрткәннәр. Безнең Татарстанның табигате дә, кешеләренең тормышы да Гөлстан, ягъни гөл бакчасы кебек булсын өчен зур тырышлыклар куясы бар әле.

Шушы бурычларны аңлап, 1992 елның ямьле май аенда Татарстан халыклары җыены узды. Анда катнашучылар уртак Ватаннарында һәр халыкның рухына туры килерлек дус, бай, имин тормыш өчен, мөскәкыйль Татарстан өчен көчләрен кызганмаячакларын белдерделәр.

1989 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, элекке СССРда барлыгы 6 млн. 648 мең 760 татар яшәгән. Шуның нибары 26,2% ы, ягъни чиректән аз гына артыгы Татарстанда яши. Катлаулы тарихи язмыш халкыбызны туган җирләре Идел-Урал буйларыннан дөньяның төрле төбәкләренә таратты, үз милли мәдәниятенең төп үзәкләреннән аерды. Татарлар бүген Урта Азия дәүләтләрендә миллионнан, Мәскәү, Ленинградта 300 меңнән артык, Украина, Донбасста 100 меңгә, Себердә 100 меңгә якын исәпләнә. Моннан тыш татарлар чит илләрдә дә яшиләр. Төркиядә, Финляндиядә, Болгариядә, Румыниядә, Польшада. Хәтта ерак Австралия континентында да, Америка, Канада, Япониядә дә безнең кан-кардәшләр тормыш итә. Менә шуңа күрә дә бөтендөнья татарлары өчен бүген туган телне, гореф-гадәтләрне, традицияләрне тергезү һәм үстерү, икътисади, мәдәни элемтәләрне киңәйтү һәм үстерү мәсьәләләре бик мөһим. Шушы мәсьәләләр хакында сөйләшү өчен, Казанга 1992 елның 19—22 июнендә дөньяның төрле төбәкләреннән татар халкының күренекле вәкилләре җыелды. Бөтендөнья Татар Конгрессы дөнья халыкларына, илләренә, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Мөрәҗәгать белән чыкты. Җыенда күтәрелгән мәсьәләләрне тормышка ашыру өчен һәм, милли үзәк буларак, Бөтендөнья Татар конгрессының даими халыкара комитеты төзелде. Халкыбызны бер милләт буларак саклау һәм яшәтү, мөстәкыйль дәүләтчелеген тергезү, аякка бастыру — бу комитетның иң әһәмиятле бурычларыннан берсе итеп билгеләнде.

1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителде.

* * *

Кадерле дуслар! Менә сез беренче тапкыр Туган илебез — Татарстан тарихына сәяхәт иттегез. Сез бу данлы тарихка югарырак сыйныфларда һәм аннан соң да кат-

Татарстан табигате күренеше.

кат әйләнеп кайтырсыз. Безгә үз тарихыбызны, телебезне, мәдәниятебезне сакларга, ныклап өйрәнергә кирәк. Үз тарихын, мәдәниятен, телен белгән кеше генә азат, ирекле, бәхетле була, туган илен ярата, башка халыкларга хөрмәт белән карый ала. Горур кеше беркайчан да Туган иленең хәерче, ирексез булуына юл куймый. Илебезнең бәйсезлеге, байлыгы, иминлеге өчен көрәш дәвам итә.

Сораулар һәм биремнәр:

1. Татарстанның бәйсезлеге кайчан игълан ителде? Ул көннәрдә Ирек мәйданында булган кешеләрдән бу хакта тарих түгәрәкләренә чакырып сөйләтегез.
2. Нәрсә ул референдум?

ТАРИХЫБЫЗДАГЫ ИҢ МӨҺИМ ДАТАЛАР ҺӘМ ВАКЫЙГАЛАР

Якынча 40—100 мең еллар элек	— Хәзерге Татарстан территориясенә иң беренче кешеләр килеп утыра
2700—2300 еллар элек	— Ананьино кабиләләре — элгәреге тимер коючылар — яшәгән чор
350—370 еллар	— Һуннар Көнчыгыш Европа җирләренә үтеп керәләр
552 ел	— Төрки каганлыгы барлыкка килә
632 ел	— Бөек Болгар дәүләте төзелә
650 (якынча) —965 еллар	— Хәзәр дәүләте яшәгән чор
9 гасыр ахыры — 10 гасыр башы	— Идел Болгарстаны дәүләте барлыкка килә
922 ел	— Багдад илчелегенең Болгар иленә килүе. Ибн Фадлан
1177 ел	— тарихи чыганакларда беренче тапкыр Казан шәһәренең телгә алынуы
1236 ел	— монголларның Болгар илен яулап алулары
1243 ел	— Алтын Урда дәүләте оешу
15 гасыр башлары	— Алтын Урданың таркалуы һәм татар ханлыкларының барлыкка килүе
1445 ел	— Казан ханлыгының барлыкка килүе
1552 ел, 2 (12) октябрь	— Рус гаскәрләренең Казанны басып алулары
1708 ел	— Казан губернасы төзелү
1755 ел	— Батырша восстаниесе
1804 ел	— Казан университеты ачыла
1861 ел	— Бездна восстаниесе
1905—1907 еллар	— Россиядә беренче рус революциясе
1917 ел, 25 октябрь (7 ноябрь)	— Петроградта кораллы восстаниенең җиңүе, большевикларның хакимияткә килүе
1920 ел, 27 май	— Татарстан АССР төзелү
1941—1945 еллар	— Бөек Ватан сугышы еллары
1943 ел, июль	— Шөгер нефтен чыгара башлыйлар
1985 ел	— «Үзгәртеп кору» чоры башлана
1990 ел, 30 август	— Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеген игълан итү
1991 ел, 12 июнь	— Татарстанның беренче Президенты булып М. Ш. Шәймиев сайлана
1992 ел, 6 ноябрь	— Мөстәкыйль Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителә

ЭЧТӘЛЕК

1. Татарстан минем туган илем *(Г. Дәүләтшин)* 3
2. Без тарихны ничек өйрәнәбез *(Г. Дәүләтшин)* 6

Беренче бүлек

ИДЕЛ-ЧУЛМАН БУЙЛАРЫНДА БЕРЕНЧЕ КЕШЕЛӘР. БОРЫНГЫ ТӨРКИ БАБАЛАРЫБЫЗ ЭЗЕННӘН

3. Татарстан җирендә иң борынгы кешеләр *(Ф. Хуҗин)* . . 10
4. Таштан — металлга, аучылыктан — терлекчелеккә *(Ф. Хуҗин)* 13
5. Тимер гасыры. Ананьино кабиләләре *(Ф. Хуҗин)* . . . 16
6. Боланнар кеше булган заманнарда *(Г. Дәүләтшин)* . . . 20
7. Һуннар — иң борынгы төрки бабаларыбыз *(Ф. Хуҗин)* . 23
8. Төрки каганлыгы. Бөек Болгар дәүләте *(Ф. Хуҗин)* . . . 26
9. Хәзәр каганлыгы һәм болгарлар. *(Ф. Хуҗин)* 29

Икенче бүлек

БОЛГАР ҺӘМ КЫПЧАК ИЛЛӘРЕ

10. Болгарлар Идел һәм Кама буйларында *(Г. Дәүләтшин)* . . 34
11. Болгар дәүләтенең барлыкка килүе *(Г. Дәүләтшин)* . . . 37
12. Сугышны туктаткан күн итекләр *(Г. Дәүләтшин)*. . . . 40
13. Биләр — Олуг шәһәр *(Ф. Хуҗин)* 45
14. Мәшһүр болгар шәһәрләре *(Ф. Хуҗин)* 48
15. Сәүдә эше һәм Болгар дәүләтенең башка илләр белән бәйләнеше *(Г. Дәүләтшин)* 52
16. Болгар илендә ислам дине *(Г. Дәүләтшин)*. 57
17. Болгар дәүләтенең мәдәнияте *(Г. Дәүләтшин)* 59
18. Монгол яулары һәм Болгар иле *(Ф. Хуҗин)* 64
19. Уникe йолдыз булып ... *(Г. Дәүләтшин)*. 69
20. Алтын Урда — Кыпчак-Болгар иле *(Ф. Хуҗин)* 71
21. Олуг Болгар шәһәре *(Ф. Хуҗин)* 75
22. Алтын Урда һәм болгар мәдәнияте *(Г. Дәүләтшин)* . . . 81
23. Алтын Урданың таркалуы. Идегәй *(И. Измайлов)*. . . . 86
24. Татар ханлыклары *(И. Измайлов)* 90

Өченче бүлек

КАЗАН ХАНЛЫГЫ

25. Казан ханлыгы ничек барлыкка килгән? *(И. Измайлов)* . 94
26. «Бөек һәм гүзәл ил» *(И. Измайлов)* 97
27. «Капкасы биек таш Казан» *(И. Измайлов)* 100

28. Мәскәү белән Кырым арасындагы сәясәт *(И. Измайлов)* . 105
29. Казан ханлыгы ничек яулана? *(И. Измайлов)* 109
30. Казан иленең мәдәнияте *(Г. Дәүләтшин)* 117
31. Сөембикәне сагыну *(Г. Дәүләтшин)* 122

Дүртенче бүлек

БОЛГАР-КАЗАН ҖИРЛӘРЕ РОССИЯ ИМПЕРИЯСЕ СОСТАВЫНДА

32. Рус патшаларының милли изүе һәм аңа каршы көрәш (16 нчы гасырның икенче яртысы) *(Ф. Хуҗин)* 128
33. Крепостной тәртипләр. 17 нче гасырдагы крестьян сугышларында болгар-татарлар *(Ф. Хуҗин)* 131
34. 18 нче гасырда Казан губернасы һәм аның халкы *(Ф. Хуҗин)* 136
35. Батырша восстаниесе. Пугачев яуларында болгар-татарлар *(Ф. Хуҗин)* 140
36. 1812 елгы рус-француз сугышында татарлар *(Ф. Хуҗин)* . 144
37. Крепостной тәртипләрне бетерү өчен көрәш *(Ф. Хуҗин)* . 149
38. Караңгылыктан — яктылыкка *(Г. Дәүләтшин)* 152
39. Крепостной тәртипләрнең бетерелүе. Бездна восстаниесе *(Ф. Хуҗин)* 156
40. Казан губернасында капитализмның үсүе *(Ф. Хуҗин)* . 159
41. Казан капитализм чорында. Революциягә беренче адым *(Ф. Хуҗин)* 162
42. 19 нчы гасырның икенче яртысында татарларда милли-азатлык хәрәкәте *(Ф. Хуҗин)* 165
43. Мәрҗани һәм башкалар *(Г. Дәүләтшин)* 169
44. Беренче рус революциясендә татарлар (1905—1907 еллар) *(Ф. Хуҗин)* 173
45. «Без бишенче елны... уяндык таң белән» *(Г. Дәүләтшин)* . 178
46. «Театр — яктылыкка, нурга илтә...» *(Г. Дәүләтшин)* . . 185

Бишенче бүлек

ТАТАРСТАН СОВЕТ ХАКИМИЯТЕ ЧОРЫНДА

47. Самодержавиене бәреп төшерү *(И. Измайлов)* 192
48. Кешеләр сугыша, кан коя... *(И. Измайлов)* 195
49. Казан өчен сугыш. Колчак армиясенә каршы көрәш *(И. Измайлов)* 200
50. Крестьяннарны талау. Идел буенда ачлык *(И. Измайлов)* . 202
51. Татарстан АССРның оешуы *(И. Измайлов)* 205
52. Беренче бишьеллыкларда промышленность *(Г. Дәүләтшин, И. Измайлов)* 208
53. Барын да — колхозга! *(И. Измайлов, Ф. Хуҗин)* . . . 212
54. Мәдәниятә дә революция буламыни? *(Г. Дәүләтшин)* . 215

Алтынчы бүлек

(1941—1945 еллар)

ТАТАРСТАН БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА

55. Бөек Ватан сугышы башлану. «Барысы да фронт өчен!» *(Ф. Хуҗин)* 222

56. «Без сугышта юлбарыстан көчлебез...» *(Ф. Хуҗин)* . . 225
57. Җәлил һәм җәлилчеләр *(Г. Дәүләтшин)* 231
58. Алга, Берлинга. Җиңү байрагын кем элгән? *(Ф. Хуҗин)* 235

Җиденче бүлек

ТАТАРСТАН СУГЫШТАН СОҢ ҺӘМ ХӘЗЕР

59. Яңадан тыныч хезмәткә! *(И. Измайлов, Ф. Хуҗин)* . . 242
60. Татарстан — «кара алтын» иле *(И. Измайлов, Ф. Хуҗин)* . 244
61. КамАЗ — Кама батыры *(И. Измайлов, Ф. Хуҗин)* . . . 247
62. Сугыштан соң мәдәният үсеше *(Г. Дәүләтшин)* 249
63. Үзгәртеп кору. Хәбәрдарлык. Милли яңарыш *(Г. Дәүләтшин, И. Измайлов)* 255
64. Безнең символлар: Татарстан Дәүләт байрагы һәм туграсы (гербы) *(Г. Дәүләтшин)* 258
65. Көрәш дәвам итә *(Г. Дәүләтшин)* 262

Учебное издание

Давлетшин Гамирзан Миргазянович
Хузин Фаяз Шарипович
Измайлов Искандар Леронович

РАССКАЗЫ ПО ИСТОРИИ ТАТАРСТАНА

Учебник для 5—6 классов

(на татарском языке)

Редакторы *Г. Н. Шәрәфетдинов*
Бизәлеш редакторы *Д. Н. Җәләлетдинов*
Техник редакторлары *Л. М. Тилк, Н. Х. Гомәрбаева*
Корректорлары *Д. Р. Мифтахова, Л. М. Закирова*

ИБ № 12

Җыярга тапшырылды 2.10.92. Басарга кул куелды 29.04.93. Форматы 70×90$^1/_{16}$. Офсет кәгазе № 2. Гарнитурасы «Школьная». Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,89+ форз. 0,29. Шартлы буяу-оттиск 81,33. Нәшер-хисап табагы 16,9+ форз. 0,52. Тиражы 35 000 экз. Заказ Ч-279. С-44.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

Полиграфическо-производственное объединение им. К. Якуба Министерства информации и печати Республики Татарстан. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.